# ШУРА

№ 19
2017




Дини альманах
1908 нче елдан бирле нәшер ителә

## ЭЧТӘЛЕК


ВӘГАЗЬЛӘР

Яшәү максаты . . . . . . . 7
Үрнәк яшәү рәвеше . . . . . . . 13
Хикмәт белән дәгъвәт кыл . . . . . . . 17
Аллаһы Тәгалә һәм Аның сыйфатлары . . . . . . . 23
Аллаһка тәвәккәл итеп яшик . . . . . . . 30
Дәҗҗал фетнәсе . . . . . . . 37
Ризык Аллаһы Тәгаләнеке . . . . . . . 41
Аллаһы Тәгаләнең колларына карата булган рәхмәте . . . . . . . 47
Гомер буе хөрмәтлик! . . . . . . . 52
Раҗәб ае һәм аның фазыйләтләре . . . . . . . 58
Могҗизалар . . . . . . . 63
Иң зур байлык – иман . . . . . . . 75
Онытылып, тыныч яшәмә! . . . . . . . 84

СОРАУ-ҖАВАП

Дини мәҗлесләрдә, ашларда катнашкан өчен кеше әҗер-савап алачакмы? . . . . . . . 92
Агачларны кисештерү рөхсәт ителәме? . . . . . . . 92
Чәчне күчереп утырту рөхсәт ителәме? . . . . . . . 92
«Әт-тәхият» һәм башка догаларны тәҗвид белән укырга кирәкме? . . . . . . . 93
Ирем белән аерылганнан соң, ул миңа алиментлар түләп бара. Әмма мин моны тыелган дип ишеттем. . . . . . . . 94

ҮРНӘК ЗАТЛАР

Беренче тугры хәлиф – Әбү Бәкер ﷺ . . . . . . . 96
Әсма бинт Әбү Бәкер ﷺ . . . . . . . 107

ФӘН

Коръән турында гыйлем . . . . . . . 113
Хәнәфи мәзһәбенең төп китаплары . . . . . . . 124

МИРАС

Милли матбугатыбыз . . . . . . . 130
Пәйгамбәрләр тарихы . . . . . . . 139

ТАРИХ
Беренче мөфти – Мөхәммәдҗан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
Икенче мөфти – Габдессәлам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Мөселман руханиларына каршы репрессияләр . . . . . . . . . . . . . . . 150
Мөкри Әбүбәкер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
Дүрт ягым кыйбла: Арчаның тарихи халкына бер сәяхәт. . . . . . 170

НӘСЫЙХӘТ
Юмартлар җәннәткә беренче керерләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 179

«ШУРА»ГА – 110
Журналны өйрәнү тарихы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 189
Журналның нәширләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 197
Журналның мөхәррире . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 201

ӘДӘБИ СӘХИФӘ
Күңел күзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 210
Җиде могҗиза. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 217
«Шура» №1, 1908 ел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 221

**«ШУРА» дини альманах, №19**

гыйнвар – март 2017
рабигыль-ахыр – раҗәб 1439

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021 Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
12+

**БАШ РЕДАКТОР:**
Камил Искәндәр улы Сәмигуллин
Телефон: +7 (843) 237-94-53 (кабул итү бүлмәсе)

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Нияз Сабиров
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП:**
Рәмзилә Шафикова
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**ДИЗАЙНЕРЛАР:**
Рөстәм Даутов
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Раушан Сәйфетдияров

**ӘДӘБИ РЕДАКТОРЛАР:**
Рәмзилә Шафикова
Гөлназ Ситдикова

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нчы йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: shura@huzur.ru
Сайт: www. huzur.ru

Типографиянең адресы:
«Комбинат программных средств» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.
420044, Казан ш., Ямашев проспекты, 36 Б
Тел./факс: +7 (843) 519-91-10
Сайт: http://kpkps.ru/

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 22.12.2017
График буенча: 22.12.2017

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание на татарском языке

**Мөхтәрәм дин кардәшләр!**

**Хөрмәтле укучылар!**

Сезнең кулда «Шура» милли басмасының юбилей саны. Милләт яшәеше, дин үсеше, телебезне саклау, әдәбиятыбызны яктырту сагында торган әлеге тарихи журналга 110 ел тула! Татар халкының күренекле уллары, атаклы меценатлары бертуган Мөхәммәдшакир һәм Мөхәммәдзакир Рәмиевләр шушы басмага нигез салып, бер яктан, безнең милләткә элек-электән хас булган күркәм зыялылык үрнәген күрсәтсә, икенче яктан, татар дөньясы алдында торган җитди мәсьәләләрне уртага салып фикер алышу өчен басма мәйданчык булдыра. Мәгълүм ки, Октябрь инкыйлабына кадәр әлеге журнал татар иҗтимагый тормышында зур урын тоткан. Моңа ачык дәлил шул – Россиянең татар-мөселманнар яшәгән төбәкләрнең барысында диярлек музей-китапханәләрендә «Шура»ның нөсхәләрен очратып була, һәм аның төпләмәләрен анда бүген дә күз карасыдай саклыйлар.

Шунысы әһәмиятле: журнал үзенең битләрендә әдәбият, тарих, сәнгать, мәгариф, татар милләтен борчыган дини-иҗтимагый мәсьәләләр турында бай эчтәлекле мирас калдырган. Басма белән мөфти Ризаэддин Фәхреддиннең мөхәррирлек итүе үзе генә ни тора! Шуларны искә алып, 2013 елда милли-дини традицияләребезне торгызу эшенә керешкәч, Татарстан мөфтияте аңа сулыш өреп, альманахны яңадан дөньяга чыгара башлый. Бүген ул республикабыз мәчетләрендә һәм чит төбәк мөфтиятләрендә иң күп укыла торган басмалар рәтенә керә. Вәгазьләрне, хәнәфи мәзһәбенә, матуриди гакыйдәсенә караган авыр мәсьәләләрне җиңел һәм үтемле итеп аңлатып, «Шура» матбугаты бөтен Россия татар-мөселман өммәтенә хезмәт итә дисәк, һич арттыру булмас.

Аллаһы Тәгалә барыбызга да аңлашып, иминлектә, тыныч тормышта яшәүләрне насыйп итеп, Пәйгамбәребезнең ﷺ мөбарәк сөннәтенә ияреп яшәргә насыйп вә мияссәр әйләсә иде.

*Татарстан Республикасы мөфтие*

*Камил хәзрәт Сәмигуллин*

# Вәгазьләр

*12 гыйнвар вәгазе,*

*Рабигыль-ахыр аеның 25 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Яшәү максаты

Галәмнәрне юктан бар итеп, безне төрле нигъмәтләр белән нигъмәтләндереп торган Аллаһ Раббыбызга дан-мактауларыбыз булса иде. Бу дөньялыкка җибәрелгән соңгы расүл Мөхәммәдкә ﷺ күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде. Аллаһы Тәгалә илләребезгә, көннәребезгә, йортларыбызга, мәчетләребезгә хәерле иминлекләр, тынычлыклар бирсә иде. Имансызлыкта, тәүфыйксызлыкта йөргән бәндәләргә Аллаһы Тәгалә туры юлны табарга ярдәм итсә иде, аларны иманга китереп, тәүфыйк, истикамәтләр насыйп әйләсә иде. Авыруларга шифа бирсә иде. Мөхтәрәм газиз дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ. Аллаһы Тәгалә һәрбер кылган изге гамәлләребезне кабул итсә иде һәм Үзенең рәхмәтенә ирешергә насыйп әйләсә иде.

Кадерле җәмәгать! Һәрберебез дә бу дөньяда кая барганын, нинди гамәлләр кылганын белеп яшәргә, һәм үзенә бу сорауларны көн саен бирергә тиеш.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

أَلَمْ تَرَ أَنَّ اللَّهَ سَخَّرَ لَكُم مَّا فِي الْأَرْضِ وَالْفُلْكَ تَجْرِي فِي الْبَحْرِ بِأَمْرِهِ وَيُمْسِكُ السَّمَاءَ أَن تَقَعَ عَلَى الْأَرْضِ إِلَّا بِإِذْنِهِ ۗ إِنَّ اللَّهَ بِالنَّاسِ لَرَءُوفٌ رَّحِيمٌ ﴿٦٥﴾

**«Күрәсеңме, дөреслектә, Аллаһ җир йөзендәге барча нәрсәне файдалану өчен сезгә тапшырды вә корабларны сезгә буйсындырды, Аллаһ ярдәме белән диңгезләрдә йөрерләр, вә Ул**

**күкне җиргә төшүдән тотадыр, мәгәр Кыямәт көнне Аның теләге белән җиргә төшәр, әлбәттә Аллаһ кешеләргә йомшак вә рәхимледер».**

«Хаж», 22:65

Ягъни һәр нәрсәне: күкләрне, җирләрне, агачларны, кош-кортларны, елгаларны һәм тауларны, төрле җиләк-җимешләрне, чишмәләрне, шулай ук нинди зур океаннарда хәрәкәт итү өчен корабларны безгә буйсындырган. Аллаһы Тәгалә боларның барысын да безгә әманәт итеп тапшырган. Кешене бу дөньяга хәлиф иткән. Ә безнең бердәнбер вазифа – Аллаһы Тәгалә әйткән сүз белән, Аллаһ төзегән низам белән яшәү. Һәм белегез – Аллаһы Тәгалә безне уен-көлке өчен яратмаган.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

ثُمَّ إِنَّكُم بَعْدَ ذَٰلِكَ لَمَيِّتُونَ ﴿١٥﴾

**«Әллә Без сезне хикмәтсез рәвештә, буш вә батыл итеп халык кылдык, дип уйлаган идегезме, һәм Безгә кайтарылмабыз, дип уйлаган идегезме?»**

ثُمَّ إِنَّكُم بَعْدَ ذَٰلِكَ لَمَيِّتُونَ ﴿١٥﴾

Юк бит. Югарыда әйтеп үтелгәнчә, Аллаһы Тәгалә кешене хәлиф итеп кылды.

وَإِذْ قَالَ رَبُّكَ لِلْمَلَائِكَةِ إِنِّي جَاعِلٌ فِي الْأَرْضِ خَلِيفَةً ۖ ﴿٣٠﴾

**«Һәм синең Раббың фәрештәләргә: «Мин, әлбәттә, җир өстендә хәлиф итеп Адәмне кылмакчымын», – дип әйтте.**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:30

Хәлиф сүзе рус теленә «наместник» дип тәрҗемә кылына. Хәлиф – Аллаһ нәрсә кушса, шуны үти, Аның һәр әйткән сүзенә буйсына.

Бүгенге көндә без бу вазифабызны онытып барабыз бугай. Уенкөлкегә бирелеп, үлем турында да онытып яшибез. Әлбәттә, монда шайтанның йогынтысы бар. Җәмәгать, Иблиснең максаты – кешелек дөньясын көферлеккә чыгару, шунда батыру, түбәнчелеккә төшерү һәм үзе белән җәһәннәмгә алып бару. Пәйгамбәребез ﷺ: «Сез иман китергәч, шайтан кайгыга чумды. Әмма кайбер гамәлләрегез аркасында сез дә түбәнгә төшәрсез һәм шайтан шуңа бик риза булыр. Ул тик утырмый! Һәрвакыт вәсвәсә кылып йөри һәм кайбер кешеләрне түбәнчелеккә төшерә», – дип әйтте. Шайтан: «Мин имансызлардан, мөшрикләрдән риза, ләкин мөэмин кешедән риза түгелмен. Аларны вәсвәсә кылу юлы белән генә хак юлдан, туры юлдан аздырып була», – дип әйтә икән. Шайтан колакка, йөрәккә вә акылга пышылдап, һәрберебезне хак юлдан аздырырга тырыша.

Бераз гына җәмгыятебезгә күз салыйк әле: узган ел гына 76 ана үз баласыннан баш тарткан. Алар балаларын тукталышларда, чүп савытлары янында, бала тудыру йортларында калдырганнар. Ни өчен шулай соң? Бу аналар үзләренең төп вазифаларын онытканнар. Рәсәй дөньяда спиртлы эчемлекләр куллану буенча беренче урында тора. Ни өчен? Максат булмаганга күрә ул, җәмәгать! Төпле тормыш позициясе булмаганга күрә! Ягъни яшәү мәгънәсе юк. Кайбер кешеләр гомер буе зина кылуда, хәмер эчүдә. Картаеп, авырый башлагач: «Хәзрәт, өшкер әле», – дип мәчеткә килә башлыйлар.

Нигә Аллаһка авырлык килгәч кенә киләбез соң? Коръән өшкерү өчен генә, йә мәҗлескә барып укыр өчен генә, йә шкафка куеп, тузанга батыру өчен генә, елга бер Коръән уку конкурслары оештырыр өчен генә иңдерелмәгән.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

كِتَابٌ أَنزَلْنَاهُ إِلَيْكَ مُبَارَكٌ لِّيَدَّبَّرُوا آيَاتِهِ وَلِيَتَذَكَّرَ أُولُو الْأَلْبَابِ ﴿٢٩﴾

**«Без сиңа иңдергән китап бик файдалы вә бәрәкәтледер, аятьләрен уйлап-фикерләп аңласыннар өчен һәм гакыл ияләре вәгазьләнсеннәр өчен иңдердек».**

«Сад», 38:29

Ягъни кешеләр уйлансыннар, фикерләсеннәр, хакыйкатьне аңласыннар өчен һәм акыл ияләренә бер инструкция буларак, үгет-нәсыйхәт буларак иңдердек, ди Аллаһы Тәгалә.

Кайбер кешеләр яныма килеп: «Хәзрәт, бу дөньяда агач утыртсам, өй салсам, ул үстерсәм, минем бурычым үтәлә? Бу дөньядан тыныч күңел белән китсәң дә була бит инде?» – дип сорыйлар. Адәм баласы үзенең карашлары белән генә яши. Йорт салып, агач утыртып, баласын тәрбияләсә, муллага сәдака бирсә, теләсә нинди гөнаһ кичерелә, дип уйлый.

Минем сезгә бер хикәя сөйлисем килә:

Бер миллиардер үзенә 16 тапкыр кул салырга тели. Тәрәзәдән сикерәм дигәндә, аны тотып калалар һәм сәбәбе нидә икәнен сорагач: «Яшәвемнең максатын күрмим. Бар да бар, максат юк», – дип җавап кайтара. Ягъни, байлыгы, машиналары, күп-күп офислары, фатирлары бар. Әмма мәгънә юк.

Беркөнне үзенең бер офисына килгәч, кул юарга, дип бәдрәфкә кергән. Шунда бер гарәп кешесенең тәһарәт алганын күрә. «Мин бу раковинада битемне юам, ә син шунда аягыңны юасыңмы?» – дип сорау биргән. Бу мөселман кешесе: «Мин аягымны көненә биш тапкыр юам, ул чиста», – дип җавап кайтара. «Моның кадәр чисталык таләп иткән дин – нинди дин соң ул?» – дип сорагач, бу мөселман кешесе аңа Ислам турында вәгазь сөйли башлый. Бу динне ничек кабул итеп булганын сорагач, гарәп: «Ләә иләһә илләл-лааһ, Мүхәммәд-расүлүллаһ», ягъни: «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк һәм Мөхәммәд Аның хак хәбибе вә илчесе»дип шәһадәт бирергә кирәк», – дип җавап кайтара. Бу миллиардер иҗекләп шәһадәт әйтә һәм, әйтеп бетерүгә, күзеннән яшьләр чыга.

Миллиардер: «Бу гыйбарәгә нинди сер салдыгыз сез? Нинди бөек сере бар моның?» – дип сорый. Бу мөселман: «Бу – Исламның бүләге», – дип җавап кайтара.

Әй мөселман кардәшләрем! Бәхетне төрле кеше төрлечә аңласа да, бары тик Ислам динендә генә, Аллаһ кушканча яшәүдә генә чын бәхетне татып була.

Без бу дөньяда гыйбадәт кылу максаты белән яшибез. Хәләл мал табып, хәләл ризыклар белән тукланырга, вакытында йокларга, аек акылда булырга тиешбез. Мөэмин кеше ризыкны ашаганда: «Йә, Аллаһ, шушы ризыкны ашагач, гыйбадәт кылырлык көч бир», – дип сорарга тиеш. Хайван кебек, күбенгәнче ашарга кирәк түгел, хәтта хайван да туклангач: «Булды, җитте», – дип туктый бит. Ә күп кенә адәм баласы чамасын белми.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә Үзеннән курыккан кешегә башка берни дә куркыныч булмаячагы турында әйтә. Бу кешенең йөрәге Аллаһы Тәгалә белән бәйле булганга, аңа калган әйберләр куркыныч булмый. Ә Аллаһтан курыкмаган кешенең йөрәген бу дөнья мәшәкатьләре, бу дөнья куркуы биләп ала. Ул: «Акчаларым кая китәр, урламасlinks, таламасларымы, машинамны бәрдермәсләрме?» – дип борчылып, куркып яши. Тәнебез җирдән ясалганга күрә, тәнгә ризыкны да җирдә үскәннәрдән алабыз. Җаныбызны Аллаһ иңдерде, шуңа ризыкны да аңа Аллаһтан эзләргә кирәк. Кешенең барлык кылган гамәлләре: эше, өйләнүе, балалар табуы, аларга яхшы тәрбия бирүе – барысы да Аллаһ ризалыгы өчен булырга тиеш.

Бер кечкенә генә кыйсса сөйләп китәсем килә. Бу кыйсса бөек галим һәм аның шәкертләре турында. Зиннун Әл-Мисри дигән галим булган һәм ул үз шәкертләренә көн саен яңадан-яңа дәресләр бирә торган булган. Сөйләгән сүзләрен, укыткан дәресләрен беркайчан да кабатламаган. Шәкертләре Зиннун хәзрәтнең култык астына бер китап кыстырып йөргәннәрен күреп: «Бөтен гыйлемне дә шуннан аладыр», – дип уйла-

ганнар. Алар хәзрәттән бу китапны сорарга булгач, хәзрәт: «Китабымны мин үлгәч укырсыз», – дип җавап биргән. Һәрбер кешенең әҗәле үз вакытында киләчәк. Менә хәзрәт тә вафат булган. 20 шәкерт берьюлы теге китапка ябышкан. Араларыннан берсе: «Әйдәгез, берегез укыгыз, калганнар тыңларбыз», – дип тәкъдим ясаган. Ачып карасалар, китапта берни дә язылмаган. Битләре чиста. «Хәзрәтебез буш китап күтәреп йөрдеме икән?» – дип аптырашта калганнар. Эзли торгач, китап уртасында бер язу күреп алалар. Анда: «Әй, кеше, үткәнеңнән гыйбрәт ал, бүгенге көнеңнең кадерен бел, киләчәккә (үлемгә, Кыямәт көненә) әзерлән һәм дөньядагы асыл максатыңны онытма», – дип язылган була. Дөреслектә, ике төрле максат бар: беренче һәм икенче. Беренчесенә, ягъни асыл максатка Аллаһка гыйбадәт кылу керсә, икенчесенә йорт салу, бала тәрбияләү һәм башка төрле әйберләр керә. Бу кәгазьдә язылган сүзләр шәкертләргә бик нык тәэсир иткән. Кечкенә генә бер биткә күпме вәгазь, күпме нәсыйхәт сыйган. Шәкертләр һәрберсе дә монда язылганнар турында уйланып, куркышып, елый башлаганнар.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем, үзебезнең асыл максатыбызны онытмасак иде. Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә дә камил акыл, иман байлыгы, саулык-сәламәтлек насыйп әйләсен. Ошбу күркәм мәчетләребезгә җыелган кебек, Үзенең җәннәтләрендә дә җыелышырга насыйп әйләсә иде. Әмин!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*
*Галиев мәчете имам-хатыйбы*

*19 гыйнвар вәгазе,*

*Җөмәдәл-әүвәл аеның 2 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Үрнәк яшәү рәвеше

Галәмнәрне юктан бар кылучы, һәрдаим безгә нигъмәтләрен җибәреп торучы Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгаләгә дан вә мактауларыбыз булсын. Һәм галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелеп, безгә туры юлны, бәхет юлын күрсәткән Расүл Әкрамга ﷺ күңелебезнең иң түреннән чыккан салават һәм сәламнәребез булса иде.

Кешелек дөньясы үзен ничек кенә камилләштерергә тырышса да, дөнья һәм кешелекне төрле дөньяви гыйлем белән аңлатырга тырышса да, барыбер юктан бар кылучы Аллаһ Раббысына әйләнеп кайта. Аллаһы Тәгалә Үз китабында кешелеккә бик күп төрле дәлилләр белән мөрәҗәгать итә. Аллаһ кешелеккә халык кылынганнан бирле, Үзенең туры юлына күндереп, изге гамәл кылучы кешеләрне сөендерүче, гөнаһ кылучыларны куркытучы илче-пәйгамбәрләрен җибәреп торды, чөнки Аллаһка иман китерми торып, кешелек күркәм һәм мәгънәле җәмгыять, тормыш төзи алмый. Аллаһ Раббыбыз һәр пәйгамбәрне җиргә җибәргәндә иманга, яхшылыкка өндәргә, дип җибәрә.

Бу хакта Аллаһ Раббыбыз Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

وَمَا أَرْسَلْنَا مِن قَبْلِكَ مِن رَّسُولٍ إِلَّا نُوحِي إِلَيْهِ أَنَّهُ لَا إِلَٰهَ إِلَّا أَنَا فَاعْبُدُونِ ﴿٢٥﴾

**«Сиңа кадәр Без һәр пәйгамбәрнең дә күңелләренә: «Миннән башка илаһ юк. Миңа гына гыйбадәт кылыгыз», – дип иңдермичә җибәрмәдек».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:25

Дөреслектә, һәр җәмгыять шушы дөньяны бар Итүченең инструкциясенә бик мохтаҗ. Әгәр үткән гасырны гына алсак та, кешелекнең диннән ераклашып, бүтән юлларга кереп китүен, адашып югалуын күрәбез. Мәчетләр җимерелеп, ябылып, имамнар төрмәләргә утыртылганнан соң, кешеләр күңеленә бушлык урнаша башлаган, әхлаксызлык һәм әдәпсезлек таралган. Төрле-төрле бозыклыклар пәйда булган. Әлбәттә, без яшь буын мөселманнары, бу хәлләрне күрмәсәк тә, боларны өлкән буын сөйләүләреннән беләбез. Безгә, Аллаһның биргәненә шөкер, дингә яхшы караш уянган, дин ирекеге бирелгән вакытлар туры килде, шул сәбәпле без, яшь хәзрәтләр буыны, яшь мөселманнар буыны барлыкка килде, дип әйтсәк тә була.

Бүген исә моннан 40-50 ел элек иркен сулап мәчеткә намазга йөрү, яулык бәйләү, ифтар ашлары үткәрү, мәдрәсәләрдә уку мөмкин булмаганлыгын күз алдыбызга китерә дә алмыйбыз. Дин юлын сайлау үзеңнең тормышыңа һәм эш-карьераңа зур нокта кую дигән сүз булган. Кешеләр диндә булучыларны фанатик дип йөрткәннәр. Яшь буын мөселманнары бер мизгелгә дә күз алдына китерә алмый: бер бәйрәм дә хәмерсез узмаган. Ә бүген? Ә бүген, Аллаһка мең шөкер, мәҗлесләрнең күбесе хәләл рәвештә уза. Коръән укып башлап, дога кылына.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

وَقَالَ رَبُّكُمُ ادْعُونِي أَسْتَجِبْ لَكُمْ ۚ إِنَّ الَّذِينَ يَسْتَكْبِرُونَ عَنْ عِبَادَتِي سَيَدْخُلُونَ جَهَنَّمَ دَاخِرِينَ ﴿٦٠﴾

**«Сезнең Раббыгыз: «Миннән сорагыз, Мин сезгә җавап бирермен, ягъни кылган догагызга җавап итеп, сораганыгызны бирермен. Хакыйкатьтә, кемнәр Миңа гыйбадәт кылуда тәкәбберләнә, аларны Мин җәһәннәмгә кертермен», – дип әйтте».**

«Мөэмин», 40:60

Берсүзсез, аятьтәгечә дога кылынган мәҗлеснең бәрәкәтле һәм дәвамлы булуында шик юктыр. Андый җыеннарда фәрештәләр бардыр, ә хәмер эчелеп, бәхетне стакан күтәреп сораган җирдә шайтан һәм бәхетсезлектер. Хәзер инде Сабантуй кебек бәйрәмнәрдә дә, урамда да исереп, аунап яткан кешене күрү бик сирәк хәл. Дин кешедән «кеше» ясый, чөнки Расүлебездән ﷺ: «Йә Аллаһның илчесе! Сине Аллаһы Тәгалә ни өчен җибәрде?» – дип сорадылар. Пәйгамбәребез ﷺ: «Әхлакны камилләштерер өчен», – дип җавап кайтара.

Кешенең яшәеше һәрчак Аллаһы Тәгалә куйган кануннарга бәйле. Шуңа күрә иман белән яшәгән, әдәп-әхлак югары булган җәмгыятьтә генә тынычлык, татулык һәм хөрмәт була ала. Безнең әби-бабайлар заманында халыкның әхлагы һәм әдәбе югары булган, чөнки алар Аллаһы Тәгалә кушкан һәр әмерне ихластан эшләп, куйган тыюларын чын күңелдән куркып, тыелганнар. Һәрберебез дә ихластан укылган намаз кешене фәхеш эштән тыйганын беләбез. Бу хакта Аллаһы Тәгалә Үзе әйтә:

إِنَّ الصَّلَاةَ تَنْهَىٰ عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنكَرِ ۗ ﴿٤٥﴾

**«Намаз кешене фәхеш эштән саклый».**

«Ганкәбут / Үрмәкүч», 29:45

Җәмгыять сау-сәламәт булсын өчен, һәр кеше үзеннән башларга тиеш: үзенең эчке халәтен карарга, гөнаһларына тәүбә итәргә һәм, иң мөһиме, кичерә белергә тиеш, һич югы тырышырга тиеш. Без, мөселманнар, җәмгыять белән дус-тату яшәп, мөселманнарның өстенә тагылган начар ярлыкларның дөрес түгеллеген күрсәтергә тиешбез. Без яхшырсак, тирә-юнебез яхшырыр.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّ اللَّهَ لَا يُغَيِّرُ مَا بِقَوْمٍ حَتَّىٰ يُغَيِّرُوا مَا بِأَنفُسِهِمْ ﴿١١﴾

**«Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә кешеләрнең хәлләрен, алар үзләре үзгәрмичә, үзгәртми».**

«Рәгыд / Күк Күкрәү», 13:11

Бу сүзләрдән түбәндәгене аңларга була: кешелек никадәр генә тырышмасын, үзе үзгәрмәсә, башкалардан нидер таләп итеп кенә берни үзгәрмәячәк. Һәрбер пәйгамбәр үзеннән башлаган, аннан соң үзенең гаиләсен туры юлга өндәгән. Кешелек дөньясы тулы иман, күркәм әхлакка омтылса гына, җирдә тынычлык, идеаль җәмгыять була ала. Аллаһы Тәгалә һәрбарчабызга дөрес ният, күркәм сыйфатлар биреп, иман белән бүләкләп, ике дөнья бәхетенә ирешергә насыйп итсә иде. Һәм һәр гамәлебездән риза булса иде. Әмин!

*Алмаз Галимҗанов,*
*Саба районы имам-мөхтәсибенең*
*яшьләр эше буенча урынбасары*

*26 гыйнвар вәгазе,*

*Җөмәдәл-әүвәл аеның 9 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Хикмәт белән дәгъвәт кыл

Мөхтәрәм газиз кардәшләр! Аллаһның әмерен үтәп шушы җомга намазына килгәнегез өчен Аллаһы Тәгалә сезне олыласын, дәрәҗәләрегезне арттырсын! Сез бүгенге көндә диннең терәге, өммәтебезнең киләчәген кайгыртучылар. Безнең үз-үзебезне ничек тотуыбызга карап, кемдер: «Минем дә шулар кебек буласым килә», – дип әйтер һәм мөселман булып китәр, кемдер исә, Аллаһ сакласын, киресенчә, Исламнан ераграк булырга кирәк, дип тагын да туры юлдан читкә китәр. Шуңа күрә әлеге вәгазебезне үгетләү, дингә өндәү темасына багышларга булдык.

Әлхәмдүлилләһ, монда җыелгансыз икән, димәк, Аллаһы Тәгалә сезгә туры юлга басуны җиңеләйткән, сез мөселман булдыгыз. Әмма ләкин еш кына шундый хәлне күрергә туры килә: без намаз укыйбыз, шәригать кушканча яшәргә тырышабыз, тик якыннарыбыз моны аңламый, Ислам кушканча яшәргә теләми. Нишлик икән, аларны ничек дәгъвәт кылыйк, ничек итеп намазга бастырыйк, дип баш вата башлыйбыз шулвакыт. Күбесе мәчеткә шундый киңәш сорап килә: «Хәзрәт, нәрсә эшлим? Хатыным яисә ирем намаз укымый, әти-әнием диндә түгел, балам гыйбадәтләрен үтәми. Мин дога кылам, аларны дингә чакырам, ләкин бернинди нәтиҗәсе юк. Киңәш бир: гаилә әһелемне, туганнарымны, дус-иптәшләремне ничек итеп дингә чакырыйм?» – диләр. Әлбәттә, бу бик четерекле сорау. Монда универсаль бер рецепт биреп булмый. Бүген кайтыгыз да, шуны эшләгез, алар иртәгә үк намазга басачак, дип әйтерлек чара юк. Ләкин бу мәсьәләдә төшенкелеккә бирелергә ярамый, кулларыбызны төшермәскә кирәк. Аллаһ Сөбханә вә Тәгалә безгә тормы-

шыбызда күрсәтмә буларак изге Коръән китабын биргән. Шушы соравыбызга җавапны да без иң элек Коръәннән эзләргә тиешбез. Дәгъвәт кылу хакында Аллаһы Тәгалә «Нәхел» сүрәсенең 125 нче аятендә әйтә:

ادْعُ إِلَى سَبِيلِ رَبِّكَ بِالْحِكْمَةِ

**«Хикмәт белән Раббыңның юлына дәгъвәт ит...»**

«Нәхел / Умарта Кортлары», 16: 125

Монда иң мөһим сүз – «билхикмә», ягъни «хикмәт белән». Бу Аллаһның боерыгы – дингә хикмәт белән чакыру. Хикмәт белән чакырмасак, без кире нәтиҗә алачакбыз, шуны аңларга кирәк. Әгәр безнең сүзләрдә хикмәт юк икән, без кешене, киресенчә, диннән ерагайтабыз гына. Мәсәлән, атасын Исламга чакырырга теләгән улы килеп әтисенә турыдан туры: «Син дөрес эшләмисең, болай яшәргә кирәк», – дип әйтсә, бу хикмәтле дәгъвәт булырмы? Юк. Монда башка юлларны сайларга кирәк. Бер дә булмаса, инде үзе кырыкка җиткән кеше булса да, әтисен үгетләргә теләгән кеше иң элек әнисе белән яисә башка олырак бер туганы белән киңәшләшсен иде.

Дәгъвәт ул – чакыру дигән сүз, һәм аның асылында дуслык хисе ята. Ягъни ачуыбыз килгән вакытта без кешене чакыра алабызмы? Мәсәлән, сез кемнедер кунакка чакырырга телисез ди. Ачу һәм нәфрәт белән: «Әй, бүген миңа кил!» – дип чакырсагыз, кунагыгыз килерме? Юк, әлбәттә. Йөз чөереп: «Сез – кәферләр, мин сезнең тормыш алып бару рәвешегездән җирәнәм», – дип дәгъвәт кылып булмый. Ислам дине ул матур дин. Димәк, без якыннарыбызны йомшаклык белән, яратып нәсыйхәт кылырга тиешбез.

Алга таба аятьтә килә:

وَالْمَوْعِظَةِ الْحَسَنَةِ

Бу сүзләр нәрсәне аңлата? **«Күркәм рәвештә вәгазьлә»**, ягъни иң гүзәл шәкелдә мөрәҗәгать ит. «Әл-хәсәнә» биредә «яхшы, гүзәл» дигәнне аңлата. «Гүзәл нәсыйхәт» нинди була соң ул? Ул йөрәкләргә үтеп керә алырлык матур сүзләр эзләп таба алу. Әгәр сез чыннан да кешене дингә өндәргә телисез икән, аның күңелен төшерә алырлык сүзләр сөйләмәгез, ачуын чыгармагыз, сездән сакланырга мәҗбүр итмәгез. Кешене: «Син намазга басмасаң, җәһәннәм утында яначаксың», – дип дәгъвәт кылып булмый. Газап белән куркытмагыз, югыйсә, ул кеше дингә каршы бер адым да атламаячак. Әй, булмый инде бу кешедән, күпме аңлатам инде, ул барыбер үзенекен тукый, дип кул да селтәмәгез. Бәлки әле вакыты җитмәгәндер. Кеше бер мизгелдә генә үзгәрми бит.

Шул ук аятьтә дәвам итеп Аллаһ әйтә:

وَجَادِلْهُم بِالَّتِي هِيَ أَحْسَنُ

**«...Китап әһелләре белән яхшы сүзләрне кулланып, акыллы итеп бәхәс алып бар. Синең алар белән бәхәсләшүең аларны инандыру һәм үзеңнең динеңә китерү өчен яхшылык белән, җәберләүсез булсын».**

Ягъни дин өчен бәхәс алып барырга туры килсә дә, бу бәхәсне иң гүзәл шәкелдә, хикмәт белән алып барырга кирәк. Димәк, без нәрсә эшләргә тиеш? Без кемне дә булса хөкем итәргә тиешме? Бездән таләп ителгәне: күркәм рәвештә Ислам divenенә өндәү, динебезнең матурлыгын күрсәтү. Калганын без Раббыбызга калдырырга тиешбез. Ул гына кешенең күңелендә барлыкка килгән үзгәрешләрне күрә ала. Кеше, гомумән, бер генә көн эчендә үзгәрми. Сәхабәләр дә бер көн эчендә генә үзгәрмәгәннәр. Коръән Кәрим китабы 23 ел дәвамында иңә – шуны онытмасак иде. Пәйгамбәребез ﷺ Мәккәдә ничә ел дәвамында кешеләрне Ислам divenенә чакырган, еллар буе тәрбияләгән. Без вәгазьләүдән туктамаска тиеш. Нәтиҗә Аллаһтан. Бәлки ул кеше бүген синең сүзләреңә колак

салмас, ләкин берничә көннән, атнадан яки елдан ул бу дәгъвәтеңне искә алыр, уйланыр, фикер йөртер һәм, ин шә Аллаһ, Исламга килер. Шуңа күрә әлеге аятьтә алга таба болай диелә:

إِنَّ رَبَّكَ هُوَ أَعْلَمُ بِمَن ضَلَّ عَن سَبِيلِهِ وَهُوَ أَعْلَمُ بِالْمُهْتَدِينَ

**«Раббың адашучы, котылу юлыннан тайпылучыларны һәм иман китереп, тәкъва, тугрылыклы булучыларны яхшырак белә».**

«Нәхел / Умарта Кортлары», 16: 125

Монда һәркемгә уйланырлык җирлек бар. Шушы аятьтә әйтелгәннәрне төшенергә тырышырга кирәк. Ләкин безнең проблема шунда: без үзебезне алардан яхшырак, дип уйлыйбыз. Ул тайпылган, мин юк, мин дөрес юлда, дибез. Ә чынбарлыкта кемнең адашкан булуы бары Аллаһка гына мәгълүм. Шуңа күрә дә дәгъвәт кылырга хикмәтебез җитми.

«Нәхел» сүрәсенең башка бер аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

هُوَ الَّذِي أَنزَلَ مِنَ السَّمَاءِ مَاءً لَّكُم مِّنْهُ شَرَابٌ وَمِنْهُ شَجَرٌ فِيهِ تُسِيمُونَ

**«Ул сезгә күктән суны индерде. Ул суны сез эчәрсез һәм ул су агачларны, сез сөтеннән, итеннән, йонынннан һәм тиресеннән файдалана торган хайваннарның көтүлекләрен сугарды».**

«Нәхел / Умарта Кортлары», 16: 10

Күктән су индерде диелә... Уйлап карагыз: су булмаган җирдә тереклек бармы? Әгәр яңгырлар яумаса, җир үле булыр иде, анда берни үсмәс иде. Ләкин Аллаһы Тәгалә су индерә һәм җир йөзендә төрледән-төрле үсемлекләр үсеп чыга. Алдагы аятьтә шул хакта әйтелә:

يُنبِتُ لَكُم بِهِ الزَّرْعَ وَالزَّيْتُونَ وَالنَّخِيلَ وَالْأَعْنَابَ وَمِن كُلِّ الثَّمَرَاتِ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَةً لِّقَوْمٍ يَتَفَكَّرُونَ

**«Ул сезгә күктән җибәрелгән су белән ашлыкларны, зәйтүннәрне, хөрмәләрне, йөзем чукларын һәм башка сез күргән җимешләрне бирә торган үсентеләрне үстерә. Бу нәрсәләрдә фикерләүчеләргә һәм җимешләрне яратуда Аллаһның кодрәте турында уйлаучыларга галәмәт бар».**

«Нәхел / Умарта Кортлары», 16: 11

Димәк, яңгырлар яугач нәрсәләр үсеп чыга? Ашлыклар, зәйтүн, хөрмә, виноград һәм башка барлык төр җимешләр, ди Аллаһы Тәгалә. Ләкин шуңа игътибар итегез: үсемлекләрнең бер төре, кеше катнашы булмыйча, үзләре үсеп чыга, үзләре җимеш бирә. Мәсәлән, җәй көне болыннарда, урманнарда үскән җиләкләрне генә алыйк. Аларны Аллаһы Тәгалә үстерә. Теләгән һәркем барып җыя ала. Икенче төр үсемлекләр исә кешегә мохтаҗ. Аларның орлыгын җиргә күмеп кую гына җитми: су сибәргә, чүпләрен утарга, бөҗәкләрдән сакларга һәм башка эшләрне башкарырга кирәк була. Әйтик, виноград куагы җимеш бирсен өчен кеше башта күпмедер мәшәкать күрергә, аны карап үстерергә тиеш, шулай бит? Инде менә озакламый, февраль ае ахырында, март башларында тәрәзә төбендә күп кеше үсентеләр утырта башлый. Әгәр кешеләр тырышлык куеп үстермәсәләр, кайбер культураларны урманга барып кына җыеп кайтып булмый. Безнең көн дә ашый торган ризыгыбыз икмәк белән бәрәңге дә, карап үстермәсәң, өстәлебездә булмаячак.

Дәгъвәт белән дә шулай ук. Аллаһы Тәгалә җирне терелтү өчен су индерсә, кешеләрнең җаннарын терелтү өчен Коръән аятьләрен индерә. Йөрәкләренә Аллаһ сүзе үтеп кермәгән кешеләр үле җир кебек. Әйе, яңгыр явып кына үзеннән үзе үскән җимешләр булган кебек, бернинди дәгъвәтка мохтаҗ булмыйча, Ислам динендә булган кешеләр бар. Ләкин кайберәүләрне сабырлык белән дингә өндәргә кирәк. Безнең өммәтебезне терелтә ала торган су ул – Коръән. Без кешеләрне Аллаһ сүзе белән Исламга чакырырга тиешбез. Ләкин кешеләр һәркайсы төрле

тизлек белән хәрәкәт итә. Әгәр без кешенең күңелендә иман орлыклары шытып чыгуын телибез икән, без нәрсә эшләргә тиеш? Бакчачы зур бер алмагач үстерергә теләсә нишли? Ул иң әүвәл җиргә орлыкларны чәчә, аның өстенә су сибә, аннан сабыр итә, көтә. Җир астында орлык нинди үзгәрешләр кичергәнен күрми бакчачы. Иман белән дә шулай ук. Без кешегә хакыйкатьне күрсәтәбез, Аллаһ хакында булган гыйлемебез белән аның күңелен сугарабыз. Алга таба ни буласы безнең ихтыярда түгел. Бакчачы бер айдан ук алмагачның җимеш бирүен көтә аламы? Ул бит җирдән әле генә шытып чыккан үсентене: «Әйдә, тартыл, тизрәк үс», – дип куллары белән йолкымый. Кешенең иманга килүе белән дә шулай ук. Дәгъвәт кылганда кешегә юнәлеш бирергә кирәк. Калганын ул үзе эшли. Алдагы аятькә кире кайтыйк:

ادْعُ إِلَى سَبِيلِ رَبِّكَ بِالْحِكْمَةِ

Биредә: «Удгу илә сәбиили раббикә», ягъни «Раббыңның юлына чакыр» диелә. Без, гадәттә, кешене берәр кая чакырганда барасы бер урынны әйтәбез, шулай бит? Ягъни, мәсәлән: «Әйдә, авылга кайтабыз», – дибез, «авылга кайта торган юлга» чакырмыйбыз. Әгәр фикер йөртеп карасак, монда да «җәннәткә» чакырырга тиеш булыр идек, ләкин Аллаһ безгә моны йөкләмәгән. Дәгъвәт кылганда без бары тик кешеләрне Раббыбызның юлына өндәргә тиешбез. Аятьнең нәкъ менә шундый шәкелдә килүендә дә хикмәт бар, чөнки нәтиҗә бездән түгел. Бара торган юлыбызның ахыр ноктасы бер – ул җәннәт. Ләкин Аллаһка илтә торган юллар күп төрле булырга мөмкин. Ул юлларның кеше кайсын тели, шунсын сайлый.

Вәгазебезне тәмамлап, шунысын әйтәсе килә: Исламда катылык, тупаслык юк, ул – гафу итү, кичерү, хәерхаһлык дине. Якыннарыбызны Ислам диненә чакырганда да, шуны онытмасак иде.

*«Хозур» редакциясе*

*2 февраль вәгазе,*

*Җөмәдәл-әүвәл аеның 16 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Аллаһы Тәгаләһәм Аның сыйфатлары

Безгә ике дөньяда да бәхет чыганагы булган шәригатьне бүләк иткән Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләгә биниһая хәмед-сәнә, шөкраналарыбыз булса иде. Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафага ﷺ, аның хөрмәтле әһленә, сәхабәләренә, күңел түрләребездән чыккан сәламнәребез, салаватларыбыз һәм һәртөрле изге догаларыбыз булса иде.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләәмү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәракәәтүһ. Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә ышану, Аның сыйфатларын белү, аңлау һәр мөселманның төп вазифасы булып тора. Аллаһы Тәгаләгә ышанган, Аның сыйфатларын дөрес итеп кабул иткән кешенең гамәл-гыйбадәтләре кабул була, ә Аллаһка ышанмаган, йә Аллаһтан башка затларны илаһилаштырган, йә Аллаһы Тәгаләнең сыйфатларын дөрес итеп кабул итмәгән кешенең гамәл-гыйбадәтләре кабул булмый. Шуңа күрә, Ислам галимнәре әйтүенчә, дини фәннәрнең иң мөһиме булып гакыйдә яки тәүхид фәне санала. Әлеге фән Аллаһы Тәгаләнең сыйфатларын һәм башка иман мәсьәләләрен өйрәнә. Һәрбер пәйгамбәр халыкка динне җиткергәндә, башта гакыйдәне, аннары шәригатьне аңлаткан. Барлык пәйгамбәрләрнең гакыйдәсе бер, ә шәригатьләре исә төрле булган. Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ әйткән: «Миңа кадәр булган бөтен пәйгамбәрләрнең һәм минем иң яраткан сүзләрем – ул «ләә иләәһә илләллаһу», – дигән.

Гакыйдә – динебезнең нигезе. Ул дөрес, нык булса, гамәлләребезнең дә уңай нәтиҗәсе булачак. Үзебезнең Раббыбызны, Аның сыйфатларын яхшы белергә тиешбез.

Аллаһы Тәгаләнең заты бер, ләкин Аның сыйфатлары чиксез, Ул сан белән чикләнмәгән. Бу сыйфатларның кайберләре турында мәгълүматлар фәкать пәйгамбәрләргә генә иреште, ә кайбер сыйфатлар турында бөтен кешеләргә дә хәбәр бирелде. Без Аллаһы Тәгаләнең 99 исемен, ягъни сыйфатын беләбез. Бу исемнәр турында Коръәндә болай дип әйтелгән:

وَلِلّهِ الأَسْمَاءُ الْحُسْنَى

**«Иң матур исемнәр Аллаһка хас».**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:180

Ислам галимнәре әйтүенчә, балигълык яшенә җиткән һәрбер мөселман Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләнең 14 сыйфатын белергә тиеш, аларны белү Аллаһы Тәгалә һәм Аның сыйфатлары турындагы ялгыш фикерләрдән, дөрес булмаган карашлардан саклый. Галимнәребез бу 14 сыйфатны икегә бүлгәннәр. Беренче 6сы «затый» сыйфатлар дип атала, ягъни бу сыйфатлар бары Аллаһы Тәгаләгә генә хастыр. Калган 8е «сөбүти» сыйфатлар дип атала, ягъни әлеге сыйфатлар дөнья яратылышы белән бәйләнгән.

«Затый» сыйфатлар:

1. Вөҗүд би Нәфсиһи – Аллаһ бардыр. Бу барлыкны Аллаһы Тәгаләгә беркем дә бирмәгән.

2. Вәхдәният – Аллаһ бердер, Аның тиңдәше юк.

3. Кадәм – Аллаһның әүвәле юк. Аллаһтан башка бөтен барлыкларның әүвәле бар. Хәдис-шәрифтә әйтелән: «Аллаһы Тәгалә мәңге булды. Аннан башка бернәрсә дә булмады»[1].

4. Бәка – Аллаһның ахыры юк, Ул мәңге булачак.

---

[1] Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан

5. Мөхалифәт лил-Хәвәдис – Аллаһы Раббыбыз беркемгә һәм бернәрсәгә дә охшамас. Аллаһы Тәгалә барлык мәхлуклардан өстен. Коръән Кәримдә «Шура» сүрәсенең 11 нче аятендә болай дип әйтелгән:

لَيْسَ كَمِثْلِهِ شَيْءٌ

**«Аллаһка охшаган һичнәрсә юктыр».**

«Ихлас» сүрәсенең 4 нче аятендә:

وَلَمْ يَكُن لَّهُ كُفُوًا أَحَدٌ

**«Вә һичкем Аңа тиң булмады»,** – диелә.

Кайберәүләр Аллаһы Тәгалә – ул нур, изге рух, бөек акыл (высший разум) дип әйтәләр. Бу фикерләр дөреслеккә туры килми, чөнки Аллаһы Тәгаләнең затын берничек тә танып булмый. Икенче төр галимнәр болай дигән: «Аллаһы Тәгаләнең затын Аллаһтан башка беркем дә белмәс». Расүл Әкрам ﷺ үзенең бер хәдисендә әйткән: «Аллаһның мәхлуклары турында уйлагыз, фикер йөртегез. Аның заты турында уйламагыз, чөнки сез Аның бөеклеген беркайчан да танып бетерә алмассыз», – дигән[1].

6. Кыям би Нәфсиһи – Аллаһның барлыгы Үзеннәндер. Аның бу сыйфатын белү – Аллаһы Раббыбыз турында мөһим белем ул. Әгәр кеше Аллаһы Тәгалә күктә, йә җирдә яки бөтен җирдә дип уйласа, ул имансыз калырга мөмкин.

Мөхтәрәм җәмәгать! Белергә кирәк: Аллаһы Тәгаләнең урыны һәм сурәте, ягъни образы юк. Ул урынны да, сурәтне дә Үзе яратты һәм Үзе барлыкка китергән нәрсәләргә мохтаҗ түгел.

Имам Бәйһәкый үзенең «Әл-әсма вәс-сыйфат» дип исемләнгән китабында түбәндәге сүзләрне китерә: «Кайбер галимнәр Аллаһы Тәгалә урынга мохтаҗ түгел икәнлеген дәлилләр өчен Пәйгамбәребезнең ﷺ бер хәдисен китерәләр: «Йә, Аллаһ, Син Заһир, Синең өстеңдә дә бернәрсә

---

1 Дәйләми, Муснад

юк, Син Бәтыйн, Синең астында да бернәрсә юк»[1]. Бу сүзләргә өстәп, галимнәр шуны әйттеләр: «Аллаһка өстендә, астында кебек сүзләр хас булмагач, димәк, Аллаһның урыны юк».

Кайберәүләр Коръәндәге аятьләрне һәм сөекле Пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрен үзләренчә аңлатып, Аллаһы Раббыбызны мәхлукларга хас булган сыйфатлар белән сыйфатлыйлар. Мәсәлән, имам Мөслим хәзрәтләренең хәдисләр җыентыгында шундый бер хәдис бар. «Бер көнне Пәйгамбәребезгә ﷺ бер кеше килеп әйтте: «Йә, Расүлүллаһ, Минем бер җариям, ягъни кол хатын бар, ул минем малымны карый. Көннәрнең берсендә бүре минем сарык бәрәнемне урлады. Мин ачуланып, җариягә суктым һәм бу гамәлем өчен үкенәм. Бәлки миңа аны азат итәргәдер», – диде. Расүл Әкрам ﷺ шул җарияне чакырып китерергә кушты. Җария килгәч, Пәйгамбәребез аңа сорау бирде: «Аллаһ кайда?» Җария: «Аллаһ күктә», – диде. Пәйгамбәребез ﷺ янә сорау бирде: «Мин кем?» Җария: «Син – Аллаһның расүле», – дип җавап кайтарды. Шуннан соң Пәйгамбәребез ﷺ : «Аны азат ит, ул иманлы», – дип әйтте.

Бу хәдисне аңлар өчен галимнәрнең шәрехләрен карарга кирәк. Мәшһүр остаз, имамӘн-Нәвәви «Аллаһ кайда?» дигән сорауга болай диде: «Бу сорау Аллаһның урыны турында түгел, ә Аның бөеклеге турында бирелде һәм «Аллаһ күктә» дигән сүзләр Аның бик кодрәтле зат икәнлеген аңлата». Шулай итеп, без Аллаһы Тәгалә бөтен кимчелекләрдән пакь булганын белергә тиеш. Аллаһның Гареше турында имам Гали ؓ әйтте: «Аллаһы Тәгалә Гарешне Үзенең кодрәтен күрсәтер өчен яратты».

«Сөбүти» сыйфатлар:

1. Хәя – Аллаһ тередер, әмма тереклеге безнеке кебек түгел, без тән һәм рух белән яшибез, Аллаһ исә боларга мохтаҗ түгел.

2. Гыйлем – Аллаһ белүчедер, белеменең чиге юк. Кирәк, яшерен эшләгән эш булсын, кирәк, күрсәтеп эшләгән эш булсын, әллә кайчан

---

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

эшләгән эш булсын, ерак киләчәктә эшләнәчәк эш булсын – барысын белүче.

3. Сәмигъ – Аллаһ бар нәрсәне ишетүчедер. Ишетүе мәхлукатныкы кебек түгел, колакка мохтаҗ булмас.

4. Басыйр – Аллаһ бар нәрсәне күрүчедер. Күрүе дә мәхлукатныкына охшамас, күзгә мохтаҗ булмас.

5. Ирадәт – Аллаһ теләгәнен эшләр.

6. Кодрәт – Аллаһ чиксез көч һәм куәткә ия.

7. Кәләм – Аллаһ Үзе теләгәнне сөйләшер һәм сөйләшүе дә мәхлукатныкына охшамас, телгә, тавышка һәм хәрефләргә мохтаҗ булмас.

8. Тәквин – Аллаһы Тәгалә бердәнбер яратучы, һәр нәрсәне юктан бар итүче, шуңа күрә бер генә затны да Аллаһка тиңдәш кылырга хакыбыз юк.

Хөрмәтле мөселманнар! Аллаһы Тәгаләнең шушы сыйфатларын белик, Аның мәрхәмәтле, шәфкатьле, сабыр һәм башка күп гүзәл сыйфатларга ия булуын онытмыйк, күбрәк Аның кодрәте, рәхмәте турында фикер йөртик. Бу дөньяда һәрбер мәхлук Аллаһы Раббыбызның бар булуына дәлил булып тора. Әгәр без тирә-юньгә игътибар белән карасак, Аллаһның бөеклеген, кодрәтле зат икәнлеген күрәчәкбез һәм Аллаһка карата мәхәббәтебез артачак, Аның ризалыгына, рәхмәтенә омтылырга тырышачакбыз.

Көннәрдән бер көнне мәшһүр әүлияләрнең берсе Җүнәйд Багдади күп кешеләрнең каядыр ашыгып барганнарын күрде. Ул алардан: «Кая ашыгасыз, сезне нәрсә дулкынландырды?» – дип сорады. Алар: «Меңнәрчә мисаллар ярдәмендә Аллаһның барлыгын исбатлаучы данлыклы галим килде. Без аннан дәрес алырга ашыгабыз. Әгәр теләсәң, син дә безнең белән бара аласың!» – дип җавап бирделәр. Шәех Җүнәйд аларга елмаеп карап: «Күрә торган күзләр, ишетә торган колаклар, тоя белә торган

калебләр өчен дөньяда Аллаһның барлыгына күп дәлилләр бардыр. Әгәр сездә шуңа карамастан шикләр кала икән, барыгыз һәм тыңлагыз ул галимне! Безнең калебтә бернинди шик юк», – дип әйтте.

Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы Раббыбыз безне кайда гына булсак та, һәрвакыт күреп торганын истә тотсак иде. Шул ук Җүнәйд Багдади хәзрәтләренең бик тырыш егерме шәкерте бар иде. Ул аларны бик хөрмәт итә торган булса да, араларыннан берсен Габдулланы артыграк сөя һәм ихтирам итә иде.

Көннәрнең бер көнендә дәрес беткәннән соң, унтугыз шәкерт бергә җыелып, Җүнәйд хәзрәт янына килделәр һәм әйттеләр: «Хөрмәтле хәзрәтебез, бер нәрсәне һичничек аңлый һәм тыныч кына кабул итә алмыйбыз. Нигә син Габдулланы барыбыздан да артыграк сөясең һәм аңа күбрәк хөрмәт күрсәтәсең? Ул да синең шәкертең булган кебек, без дә синеке бит. Ул да яхшы укый, без дә артта калмаска тырышабыз. Бәлки арабыздан аннан да яхшырак укучыларыбыз бардыр?» Җүнәйд хәзрәт аларның сорауларына: «Әй, шәкертләрем, сабыр булыгыз, әлеге сорауга җавапны тиздән үзегез дә ишетерсез», – дип җавап бирде. Хәзрәтнең бу сүзләре, әлбәттә, шәкертләрне канәгатьләндермәде. Һәммәсе дә, таралышып, өйләренә кайтып киттеләр.

Шулай итеп берничә атна үтеп тә китте. Шәкертләрнең күбесе хәзрәтләренә биргән сорауларын онытканнар иде инде.

Бер көнне, дәрес тәмамланганнан соң, хәзрәт шәкертләренә шундый сүзләр белән эндәште: «Әй, хөрмәтле, нурлы йөзле шәкертләрем! Сезгә бер өй эше бирәм. Бүген барыгыз да өегезгә кайтып киткән вакытыгызда мәдрәсә сараеннан берәр тавык алыгыз, аннан шуларны, беркем дә күрмәгән җирдә суеп, чистартып миңа китерегез», – диде.

Шәкертләр бик сөенеп, җиңел булып күренгән һәм кызык кебек тоелган өй эшен алып кайтып киттеләр.

Икенче көнне иртәнге дәрескә шәкертләр өй эшләрен хәзерләп килделәр: тавыклары суелган, чистартылган иде. Араларыннан берсе – Габдулланың гына тавыгы кулында кыткылдап тора. Һәммәсе дә аңа карап сәерсенделәр: «Ничек инде хәзрәтебез кушканны эшләп килмәгән», – дип уйлап торганда, Җүнәйд хәзрәт аңардан: «Әй, Габдулла, нигә син өй эшен үтәмәдең? Беркем дә күрмәгән җирдә тавыкны суеп, чистартып килмәдең?» – дип сорап куйгач, ул: «Гафу ит, сөекле остазым, мин Аллаһы Тәгалә күрмәгән җирне таба алмадым», – дип җавап кайтарды. Моны ишеткән Җүнәйд хәзрәт шатланып елмайды һәм Габдулланы кочаклап алды да: «Ни өчен Габдулланы безгә караганда күбрәк сөясең?» – дип әйткән шәкертләренә: «Әй, шәкертләрем, минем аны ни өчен артыграк сөйгәнемне белдегезме инде? Ул Коръәнне һәм хәдисләрне генә ятлап чикләнми, гыйлемен арттыру белән бергә, ихласлылыгын һәм Аллаһка мәхәббәтен дә арттыра. Чын шәкерт, чын Аллаһ бәндәсе белеме һәм гамәле белән бергә ихласлылыгын да арттырырга тиеш», – дип әйтте.

Хөрмәтле мөселманнар! Без дә Җүнәйд хәзрәтнең шәкерте кебек булырга тырышыйк. Кая гына булсак та, нәрсә генә эшләсәк тә, нинди генә хәлдә булсак та, безне күреп торучы, һәрбер хәрәкәтебезне күзәтеп торучы Аллаһы Тәгаләне күңелебездән чыгара күрмик.

*ТЖ МДНнең дәгъвәт бүлеге*

*9 февраль вәгазе,*

*Җөмәдәл-әүвәл аеның 23 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Аллаһка тәвәккәл итеп яшик

Әгүүзү билләәһи мин әш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Җирләрнең, күкләрнең Раббысы булган, ошбу дөняга саннары да билгесез булган пәйгамбәрләрен җибәреп, шушы пәйгамбәрләре аша безгә тугры юлны – бәхет юлын, сәгадәт юлын өйрәткән, аңлаткан, җиткергән Аллаһы Тәгаләгә күңел түрләребездән чыккан сәламнәребез ирешсә иде. Шушы дөньяга соңгы пәйгамбәр булып җибәрелмеш сөекле Пәйгамбәребез, хәбибебез, остазыбыз Мөхәммәд Мостафага да ﷺ салаватларыбыз, сәламнәребез һәм изге догаларыбыз ирешсен. Шушы изге җомга көннәрендә, бәлки бик әһәмиятле эшләргә дә: «Тукта, торсын. Аллаһның йортына килим, вәгазьләним, бурычымны үтим», – дип килгән мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ. Аллаһы Тәгалә барчаларыбызга да теләгән теләкләребез, ниятләребез бәрабәренә әҗер-савапларын, Үзенең ризалыгын насыйп итсен. Әмин.

Шушы кыска гына вәгазебездә дә Аллаһы Тәгаләнең Коръән аятьләре аркылы, Пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләре, тормышында булган вакыйгалар, хәлләр аркылы, Аллаһка тәвәккәл итү, һәр нәрсәдә, һәр эштә Аллаһка таяну кебек сүзләр ишетербез. Кеше, адәм баласы Аллаһы Тәгаләнең барлыгына, берлегенә ышанганнан соң, Аңа таяна да, тапшыра да белергә тиеш. Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә изге Коръән Кәримендә «Әл-Әнфәл»сүрәсендә болай дип әйтә:

إِنَّمَا الْمُؤْمِنُونَ الَّذِينَ إِذَا ذُكِرَ اللَّهُ وَجِلَتْ قُلُوبُهُمْ وَإِذَا تُلِيَتْ عَلَيْهِمْ آيَاتُهُ
زَادَتْهُمْ إِيمَانًا وَعَلَىٰ رَبِّهِمْ يَتَوَكَّلُونَ ﴿٢﴾

**«Хакыйкый мөэминнәргә вәгазь сөйләнгәндә, Коръән аятьләрен ишеткәндә, Коръән аятьләренең мәгънәләрен ишеткәндә, аларның иманнары ныгый һәм алар Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл итәләр».**

«Әнфәл / Табыш», 8:2

Безгә шушы Аллаһка таяну – тәвәккәл итү, тапшыруны сүзгә генә кайтарып калмыйча, Аллаһка таянуны гамәлләребез белән, эшләгән эшләребез белән дә исбатларга кирәк. Гыйбадәтнең бер өлеше – ул Аллаһка таяну, тәвәккәл итү, тапшыру. Таяну дигән сүзне барыгыз да аңлыйсыз: аягы авырткан кеше таякка таяна, күзе күрмәгән кеше күзлек кия, җәяү барырга авыр, йә ерак булган вакытта, адәм баласы машина, техника белән хәрәкәт итә. Ир кеше хатынына таяна, хатын иренә таяна,балалар әти-әниләренә таяна, ягъни таяну, тәвәккәл итү, тапшыру – кемнәндер йә нәрсәдәндер ярдәм өмет итү. Әмма бөтен тәвәккәлләүне, таянуларны эченә алган иман бар һәм Аллаһы Тәгалә бар. Аллаһы Тәгалә без бәндәләренә, кешеләренә, туры мәгънәсендә болай дип әйтә:

وَتَوَكَّلْ عَلَى الْحَيِّ الَّذِي لَا يَمُوتُ

**«Һич үлмәгән, мәңге тере булган Аллаһка тәвәккәл ит».**

«Фуркан / Аеручы», 25:58

Кулыңа алган таяк та чери, күзеңә кигән күзлек тә җимерелә, техника да ватыла. Бер үлмәгән, мәңге тере булган зат бар – ул Аллаһ. Аллаһка таян һәм тәвәккәл кылып яшә. Башка бер аятьтә Аллаһы Тәгалә әйтә:

فَإِذَا عَزَمْتَ فَتَوَكَّلْ عَلَى اللَّهِ ۚ إِنَّ اللَّهَ يُحِبُّ الْمُتَوَكِّلِينَ ﴿١٥٩﴾

**«Бер эшне эшләргә ниятләсәң, фикерләсәң, соңыннан Аллаһка тәвәккәл ит».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:159

Ягъни күңелеңдә бер эшне башкарырга ниятләдең икән, шушы эшең белән бергә Аллаһка тәвәккәл ит. «Аллаһым, шушы эшемне хәерле ит», – дип күңелең белән уйлан, фикерлә.

Гайсә пәйгамбәрне ﵇ беләсез – олы пәйгамбәрләрнең берсе. Гайсәгә ﵇ Аллаһы Тәгалә могҗиза биргән иде: үләләрне дә терелтә, авыруларны шифаландыра, сукырларның күзләрен ача, ишетмәүчеләрне, чукракларны да ишетә торган итә иде, хәтта урамнан барганда, өй эчендәге өстәлдә ни торуын да, нинди ризык булуын да әйтә иде. Балчыктан бер кош ясап, аңа өреп, аны очыра иде. Бу булган әйберләр, болар тарихи расланган.

Шундый бер вакыйга була. Озак еллар авырган бер хатын шифа табар өчен Гайсә ﵇ янына килә. Бу хатын Гайсә атлап барганда, аның чапанына кагыла һәм: «Әй, Гайсә, син мине шифаландырдың, син мине шифаландырдың», – дип кычкырып җибәрә. Гайсә борыла да: «Мин түгел. Сине синең иманың дәвалады», – дип әйтә.

Ягъни чын мәгънәсендә инануың, ышануыңның нәтиҗәсен күрә белүең сиңа шифа бирде. Әй, кардәшләр, кешенең эчендә чын күңелдән инанып, ышанып, шөбһәсез тәвәккәл итү генә нәтиҗәле була ала. Шуңа күрә, бигрәк тә мөселманнар, һәр эшләренең башларында да, азагында да, уртасында да Аллаһка тәвәккәл итәргә тиешләр, чөнки һәрнәрсә Аның кулында, бөтен нәрсә Аның кодрәте белән, Аның рөхсәте белән эшләнелә.

وَمَن يَتَوَكَّلْ عَلَى ٱللَّهِ فَهُوَ حَسْبُهُۥٓ ۚ ﴿٣﴾

**«Кем дә кем бер эшенең башында Аллаһка тәвәккәл иткән икән, ин шә Аллаһ, ул эшнең нәтиҗәсе хәерле булыр».**

«Талак», 65:3

«Мин Аллаһка тапшырган идем», – дип әйтергә, сүздә генә тәвәккәлләргә мөмкин. Шулай ук күңелең белән ышанып тапшырырга мөмкин. Болар һәрберсе дә аерым нәрсәләр. Никадәр чын мәгънәсендә

ышанып тапшырасың икән, шулкадәр нәтиҗәле була, эшеңне никадәр шөбһәле башлыйсың икән, нәтиҗәсе дә шулкадәр үк шөбһәле була.

Шуның өчен, мөхтәрәм газиз кардәшләрем, Пәйгамбәребезнең ﷺ бер мөбарәк хәдисендә болай дип әйтелә: «Иң беренче зур гыйлем – Аллаһы Тәгаләне тану. Гыйлемнең иң ахыры – һәрбер эшебезне Аллаһка тапшыру».

Ибраһим пәйгамбәр عليه السلام белән булган вакыйганы һәрберегез дә беләдер. Шул вакытта, шул заманда яшәгән имансыз, иман китерергә дә теләмәгән бер патша Ибраһимны عليه السلام үтерергә боера һәм бик зур учак ягарга куша. Вә шушы учакка ыргытып, Ибраһим пәйгамбәрне яндырырга тели. Китапларда: «Бик кечкенә кешене яндырыр өчен, бик зур учак ягыла», – дип әйтелә. Ул учакның янына да килә алмаслак була, шуңа күрә Ибраһимны катапультага куеп, ягъни ядрәләр ата торган җайланмага куеп, шушы утка ыргыталар. Ибраһим عليه السلام очып барганда, янына Җәбраил фәрештә килеп җитә һәм: «Әй, Ибраһим, телисеңме, мин сине коткарам?» – дип әйтә. Уйлап карагыз әле: Ибраһимны утка ыргыттылар. Ул утка атылды, утта яначак. Шулвакыт фәрештә килеп: «Ярдәм итимме? Таян миңа!» – дип әйтә. Ибраһим عليه السلام: «Син үзең килдеңме, әллә сине Аллаһ җибәрдеме?» – дип сорый. «Үзем килдем», – ди фәрештә. «Үзең килгән булсаң, кит! Мин Аллаһы Тәгаләгә тапшырдым инде. Бөтен ут та, ут хөкеме дә Аның кулында», – дип әйтә Ибраһим عليه السلام.

Һәм риваятьләрдә: «Утка ыргытылган кеше бер бакчага төшә», – дип әйтелә. Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтте:

قُلْنَا يَا نَارُ كُونِي بَرْدًا وَسَلَامًا عَلَىٰ إِبْرَاهِيمَ ﴿٦٩﴾

**«Ибраһимны тау хәтле утка ыргыттылар, Ибраһим дөнья утыннан курыкмады, күңеле тыныч булды. «Ий, ут, Ибраһимга салкын бул һәм салкынлык белән дә зарар тидермә», – дип әйттек».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:69

Ягъни утка ыргытылган вакытта да: «Инде үләм, беттем, беркем ярдәм итә алмый», – дигәндә дә, чын күңелдән Аллаһка тәвәккәл иткән кеше, ин шә Аллаһ, нәтиҗәсез калмый. Аллаһы Тәгалә Үз ярдәмен күрсәтә. Күрегез! Менә бу иман камил булуның нәтиҗәсе.

Пәйгамбәребезнең ﷺ якын шәкерте Җәбил болай дип сөйләгән: «Көннәрнең берендә без Мөхәммәд ﷺ белән бер җиргә чыккан идек. Нәжд дигән җиргә озак кына баргач, бик арыдык. Бер агач янына ял итәргә туктадык. Бер генә агач. «Шушы агач астында Пәйгамбәребез ятсын, шушы ышык аңа булсын», – дип аны калдырдык. Үзебез бер читкә киттек. Пәйгамбәребез үзенең кылычын агачка элеп куйды да, күзләрен йомып, ял итә башлады. Ләкин шушы тирәдә йөргән бер имансыз бәндә килеп, Пәйгамбәребезнең ﷺ кылычын алды да, Пәйгамбәребезнең башы янында күтәрде: «Йә, Мөхәммәд, сине минем кулдан кем коткарыр», – дип әйтте». Кадерле җәмәгать! Без нәрсә әйткән булыр идек, белмим. Син, мин нәрсә әйткән булыр идек, белмим! Башыңны бер пычак яки берәр нәрсә белән: «Синең хәзер башыңны кисәм», – дигәндә, без әллә нәрсәләр уйлаган булыр идек. Ләкин: «Расүлүллаһ ﷺ һич тетрәнмичә: «Аллаһ!» – диде. «Аллаһ! Аллаһ!» – диде. Өч мәртәбә «Аллаһ!» диде. Теге имансыз бәндәнең кулыннан кылыч төшеп китте һәм Пәйгамбәр ﷺ кылычны күтәреп, бу юлы аның башына куйды. «Әй, мөшрик, ә сине минем кулымнан кем коткарыр? Кемгә таянасың син?» – дип сорады. Мөшрик тә акыллы мөшрик булып чыкты. Ул: «Йә, Мөхәммәд, монда ике кеше бар: берсе яхшы кеше, берсе начар кеше.Син начар кешеләр арасында булма инде», – дип әйтте. «Яхшысы бул», – дип әйтте. Пәйгамбәр ﷺ: «Иман китер! «Ләә иләһә илләллаһ вә Мөхәммәдү расүлүллаһ. Минем пәйгамбәрлегемне кабул итеп, иман китер. Китерәсеңме?» – дип сорады. Теге кеше: «Юк, китермим. Ләкин мин сиңа каршы чыкмаячакмын, сиңа каршы чыгучыларга да кушылмаячакмын, дип вәгъдә итәм», – дип әйтте. Пәйгамбәр ﷺ аңа: «Синнән бер вәгъдә алам. Шушы булган вакыйганы

имансыз дусларыңа сөйлә», – диде һәм теге мөшрикне җибәрде», – дип сөйли.

Күрәсезме, бу хәдистән шуны да аңларга кирәк: кайбер кешеләр иман китермим дигән кешенең башын кисәргә кирәк, диләр. Кайбер мөселманнар да: «Бөтен дөнья иман китерергә тиеш, әгәр иман китермәсә, башын кисегез», – диләр. Бу хәдистән ул фикернең дөрес түгеллеге аңлашыла. Пәйгамбәребез ﷺ мөшрикнең башын кисми, үтерми дә, кан да түкми: «Бар, булган вакыйганы сөйлә», – дип әйтә. Бу – Пәйгамбәребезнең әхлагы иде. Көчләп, кыйнап, куркытып беркемне дә иманга китереп булмый. Димәк, бик авыр вакытларда да: «Инде беттем! Үлдем, үлем минем якамнан тотты», – дигәндә дә, чын мәгънәсендә «Аллаһ» дигән кеше, чын мәгънәсендә иман китереп, тәвәккәл итә белсә, ин шә Аллаһ, һич тә зарар күрмәс.

Башка бер хәдистә Пәйгамбәребез ﷺ: «Әгәр сез чын мәгънәсендә Аллаһка тәвәккәл итә белсәгез, Аллаһы Тәгалә сезне кошлар кебек ризыкландырыр иде, ягъни иртән буш карын белән чыгып китеп, кичен тулы карын белән кайтыр идегез», – дип әйтте.

Иртән алар чыгып китәләр, кич җиткәч тукланып үзләренең йортларында төннәрен уздыралар. Күрүебезчә, бик аз хайваннар гына ризыкны җыеп куялар. Аларның банк карталары да юк, кибеткә кереп тә ашарга алмыйлар, акчалары да юк. Күбесе чыгып китә дә, көндәлек ризыгын алып кайталар. Мәсәлән, диңгез хайваннарына карасак, бер генә хайван да бер көн өчен дә, өч көн өчен дә, бер ел өчен дә ризык җыеп куймый һәм ябыгып, ачлыктан үлүче балыклар да юк. Агачлар да беркая йөрмиләр, бер урында, коры җирдә басып торалар. Аларны Аллаһы Тәгалә тукландыра! Ягъни хайваннар дөньясында бик күп хайваннар көндәлек чыгып китәләр дә, тырышалар, ризыгын табалар, тук булалар, дип бер хәдисендә Пәйгамбәребез дә аңлаткан иде.

Ләкин шуны да әйтергә кирәк: «Алма пеш – авызга төш» дигәндәй, Аллаһка тәвәккәл итү – утырып тор, бернәрсә дә эшләмә дигән сүз түгел. Башында да, азагында да Аллаһы Тәгаләгә тапшыр һәм хәрәкәт тә ит. Хәрәкәт иткәндә шулай ук бер әйберне онытма: «Мин китереп чыгарам, мин булдырам», – дип уйлама, – «Аллаһка тапшырдым, Аллаһы Тәгаләнең көче белән хәрәкәт итәм; Аллаһы Тәгаләнең биргән акылы белән эш итәм; бөтен нәрсә Синең кулыңда, Раббым, Сиңа тәвәккәл иттем», – дигән фикерләр белән хәрәкәт ит. Вә, ин шә Аллаһ, тәвәккәл итүеңнең нәтиҗәсен күрерсең.

Пәйгамбәребез ﷺ безгә бер дога өйрәтте: «Һәр эшнең башында «Бисмилләһ», дип әйтегез. «Бисмилләһ»сез башланган эш никадәр уңышлы башланып китсә дә, аның азагы хәерле булмас», – дип әйтә. Өйдән чыгып киткәндә дә, өеңә кайтып кергәндә дә «Бисмилләһ» дигән доганы укый күр.

Пәйгамбәребез ﷺ: «Бисмилләһи тәвәккәлтү галә-Ллаһ», ягъни «Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл иттем». «Вә ләә хәүлә вә ләә куvәтә илләбилләһ», ягъни «Бөтен көч-куәт Аның кулындадыр» дип әйткән кеше һәртөрле яманлыктан, бозыклыктан, шайтанның кагылуыннан да имин булыр, ерак булыр», – дип әйткән иде.

Аллаһы Тәгалә барыбызга да хакыйкый, дөрес иман насыйп итсен. Һәр эшебезнең башында да, уртасында да, азагында да бөтен әйбер Аллаһның кулында икәнлекне исебездән чыгармасак иде. Һәм мөмкин кадәр бөтен эшләрне хәләл юл белән башкарып, Аллаһы Тәгалә рөхсәт иткән эшләрдә хәрәкәт итәргә Үзе насыйп итсен. Аллаһтан ерак булып йөргән бәндәләргә дә Аллаһы Тәгалә иман юлына басарга, тәүфыйкланырга насыйп итсен, ин шә Аллаһ. Әмин!

*Мансур (Әнсар) хәзрәт Мифтяхов,*
*Мәрҗани мәчете имам-хатыйбы*

*16 февраль вәгазе,*

*Җөмәдәл-әүвәл аеның 30 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Дәҗҗал фетнәсе

Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә Коръәни Кәримдә әйтә:

أَحَسِبَ النَّاسُ أَن يُتْرَكُوا أَن يَقُولُوا آمَنَّا وَهُمْ لَا يُفْتَنُونَ ﴿٢﴾ وَلَقَدْ فَتَنَّا الَّذِينَ مِن قَبْلِهِمْ ۖ فَلَيَعْلَمَنَّ اللَّهُ الَّذِينَ صَدَقُوا وَلَيَعْلَمَنَّ الْكَاذِبِينَ ﴿٣﴾

**«Әллә кешеләр: «Без иман китереп инандык!» – дип әйткәч, алар калдырылырлар һәм сыналмаслар дип исәплиләрме? Без аларга кадәр булганнарны сынадык инде, һәм Аллаһ кемнең дөрес сөйләвен, һәм кемнең ялганлавын белә бит!»**

«Ганкәбут / Үрмәкүч», 29:2-3

Җир йөзе булганнан алып бу кавемгә иң зур фетнә – Дәҗҗал фетнәсе булачак. Мөхәммәд ﷺ: «Дәҗҗал фетнәсеннән дә зур фетнә булмас», – диде. Кыямәт көне алдыннан Мөхәммәднең ﷺ өммәте бүлгәләнеп бетәчәк. Төрле фиркаларга, мәзһәбләргә бүлгәләнеп беткәннән соң, һәрберсе үзен туры дип, дөрес дип саный башлаганда – Аллаһы Тәгалә имтихан өчен җир йөзенә Дәҗҗалны җибәрәчәк. Бу өммәткә бик зур сынау булыр!

Кем ул Дәҗҗал? Ничек тәрҗемә ителә? Мәшрикъта, Хорасан җирендә ике яһүдинең 30 ел балалары булмый. Балага узгач, анасы баласын карынында 12 ай йөртә. Бу бала дөньяга тугач, бер ай тавышын чыгармый, бер айдан соң гына тавышын чыгарачак. Сул күзе ябылган, уң күзе янында ит кисәге булыр. Аның башындагы чәче агачтагы ботаклар кебек күп, ләкин көдрә калын булыр. Күзе ачык яшел пыяла кебек мәгънәсез булыр,

диелгән. Кыска буйлы, үзе таза, кызыл битле. Ике күзе арасында «кәфер» диеп язылган булыр. Иманы булган кеше, галим дә һәм җаһил дә, гарәпчә белмәсә дә, моны укый алыр. Шушындый адәм баласы киләчәк дип, Расүлүллаһ ﷺ дистәләгән хәдистә әйтеп китте. Мәсих Әд-Дәҗҗал килер алдыннан халыкка зур авырлыклар килер. Җир йөзендә 3 ел ачлык булыр. Беренче елда Аллаһы Тәгалә күккә яңгыр төшермә, диеп әмер кыла. Икенче елда җиргә үсемлегеңне чыгарма, диеп әмер кыла. Өченче елда күккә – бер тамчы яңгыр тамдырма дип, җиргә бер үсемлегеңне чыгарма, дип әмер кыла. 365 көн җир йөзенә яңгыр таммый һәм җирдән бер үлән чыкмый. Җир йөзендә ачлык була, адәм баласы теләсә нәрсә ашарга, эчәргә, кимерергә риза була. Шушы ачлыктан соң бер күзле Дәҗҗал чыга. Аның тау-тау ризыклары, акчалары, елгалары, сулары булыр. Күз алдына китерегез, өч ел ачлык кичергән халык, шушы кешенең барлыгын белгәч, аңа иман китерергә дип, авылларын, шәһәрләрен ташлап китәләр (Аллаһ Тәгалә безне бу көферлектән Үзе сакласын!) Бигрәк тә надан халык байлык өчен, акчалы булыр өчен Дәҗҗалга иман китерерләр. Шушы хәдисне әйткәч, бер сәхабә: «Йә, Расүлүллаһ, без нәрсә ашарбыз?» – дип сорый. «Кем дөньяга бирелмәсә, көчле иманлы булса һәм ихластан: «Әлхәмдүлилләһ, Аллаһу әкбәр, ләә иләһә иллә Аллаһ», – дип әйтсә, карыны буш булмас», – диде. Пәйгамбәребез ﷺ : «Аллаһы Тәгалә халыкның явызлыгы, аларның гайбәтенә ачуыннан ошбу Дәҗҗалны чыгарыр», – дип әйтә. Бу иң зур фетнә була! Сәхабәләр: «Без шул вакыт хәдисләрдән Дәҗҗалны ачыктан-ачык күргән шикелле булдык», – дигәннәр. Ни өчен Дәҗҗал шуның кадәр олуг фетнә булгач, Коръәндә бер сүз дә юк диләр? Олуг мөфәссирләр әйтәләр: «Аллаһ шуның кадәр гөнаһ әһеленең, явызның исемен Коръәнгә кертмәгән. Әмма бу бәндәгә, Дәҗҗалга, Коръәндә «Әл-Әнгам» сүрәсенең 158 нче аятендә ишарәт бар:

هَلْ يَنظُرُونَ إِلَّا أَن تَأْتِيَهُمُ الْمَلَائِكَةُ أَوْ يَأْتِيَ رَبُّكَ أَوْ يَأْتِيَ بَعْضُ آيَاتِ رَبِّكَ ۗ يَوْمَ يَأْتِي بَعْضُ آيَاتِ رَبِّكَ لَا يَنفَعُ نَفْسًا إِيمَانُهَا لَمْ تَكُنْ آمَنَتْ مِن قَبْلُ أَوْ كَسَبَتْ فِي إِيمَانِهَا خَيْرًا ۗ قُلِ انتَظِرُوا إِنَّا مُنتَظِرُونَ ﴿١٥٨﴾

**«Аллаһның вәгъдә иткән аятьләре килгән көнне, кешегә аның җаны да, иманы да ярдәм итә алмас».**

«Әнгәм / Терлек», 6:158

Ничек иманы ярдәм итә алмый? Мөхәммәд ﷺ хәдистә аңлата: «Кыямәт көненең галәмәте килеп, дөньяга өч төрле нәрсә чыкса, һәм әгәр кеше шул көнгә кадәр иманга килмәгән булса, кешенең иманы аңа ярдәм итмәс, ди: 1) Дәҗҗалның чыгуы, 2) Дәббәтүл-әрд исемле хайванның чыгуы, 3) Кояш мәгърибтән, ягъни баеган җирдән чыкса, күк капуслары ябылган булыр, ягъни тәүбәләр кабул булмас».

Дәҗҗал 40 көн яшәячәк. 1 нче көне – 1 ел, 2 нче көне – 1 ай, 3 нче көне 1 атна кебек булыр. Калган 37 көне гади көннәр кебек булыр. Сорыйлар: «Бер көне бер ел булганда, 5 вакыт намаз уку җитәме?» Мөхәммәд ﷺ: «Кояшка карап түгел, сәгатьләрегезне санап, бер намаздан икенчесенә күпме булды дип, бәлки фаразлап укырсыз», – диде. Мөхәммәд ﷺ: «40 көндә бөтен җир йөзен әйләнер, сез ул көнчыгышта булса, көнбатышка качыгыз», – диде. Бүгенге көнне Дәҗҗалның тизлеген самолет белән чагыштырып була. 14 гасыр элек уртача тизлек – яхшы атның чабуы белән хисап кылынган. Әмма ләкин Пәйгамбәребез ﷺ: «Аның тизлеге күктә йөзгән болыт кебек булыр», – дип әйтә. Дәҗҗал дүрт җиргә генә керә алмас: Мәккәгә, Мәдинәгә, Әль-Әксага һәм Мисырда Тур тавына менә алмас. Мәдинә шәһәреннән 70 мең монафикъ аның янына чыгар, күпчелеге хатыннар булыр, Мәдинә шәһәренә чисталык килер, дигән. Бүгенге көндә Мәдинәдә 400 мең кеше яши. Дәҗҗалның ике елгасы булыр – салкын су һәм утлы су. Бу елгаларны ул җәннәт вә җәһәннәм итеп күрсәтер. Бер ха-

лыкны ышандырса, җир уңышлы булыр, ышандырмаса, корылык башланыр. Яшерелгән хәзинәләрне бал кортлары шикелле чыгарыр, дигән. Дәҗҗал кешеләргә үзен Аллаһы Тәгалә дип ышандырыр өчен бер яшь егетне кылыч белән урталай чабар һәм киредән Аллаһның әмере белән терелтер. Бу яшь егет: «Мин тагын бер тапкыр синең Дәҗҗал икәнлегеңә ышандым», – дияр. Шул вакыт егетне үтермәкче булыр, әмма Аллаһы Тәгалә аңа ирек бирмәс.

Кайчан чыга ул Дәҗҗал? Аның кайчан чыгасы мәгълум түгел. Әмма хәдис шәрифтә: «Дәҗҗал чыгар алдыннан 30 ялганчы кеше барлыкка килер һәм 30-ы да «мин пәйгамбәр» дип әйтерләр», – диелгән. Икенче бер риваятьтә килә: «Константинопольдәге фетнәдән соң 7 ай үткәч чыгачак», – дип. Төркиядә Истанбул шәһәрендә ниндидер бер вакыйга булырга тиеш, шул вакытта чыгар, дигән фикер бар. Имамнар Дәҗҗалны минбарлардан сөйләми башлагач, халык аны онытkач чыгар.

Дәҗҗалдан ничек сакланырга? Расүлебез ﷺ ничек саклануны безгә 1400 ел элек әйтеп калдырган: «Кем дә кем җомга көнендә «Кәһф» сүрәсенең башын яки ахырын камил рәвештә укып чыкса, Аллаһы Тәгалә аны Дәҗҗал фетнәсеннән саклар». Вә икенче бер хәдистә болай диелә: «Салаваттан соң, соңгы тәшәһһүдтә, сәлам бирер алдыннан дога кылырга: «Әллаһуммә инни әгузү бикә мин газәбил кабри, вә әгузү бикә мин газәбиннәри, вә әгузү бикә мин фитнәти мәхьяи вә мәмәти, вә әгузү бикә мин фитнәтил мәсихид-дәҗҗали».[1]

Йә, Раббыбыз, безне кабер газабыннан сакла вә җәһәннәм утыннан сакла, яшәеш вә үлем фетнәсеннән Сиңа сыгынабыз, вә Дәҗҗал фетнәсеннән безне сакласаң иде.

*Рөстәм хәзрәт Хәйбуллин,*
*Буа районы «Мәлик» мәчете имам-хатыйбы*

[1] Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан

*23 февраль вәгазе,*

*Җөмәдәл-ахыр аеның 7 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Ризык Аллаһы Тәгаләнеке

Бар галәмнәрне, барча мәхлукларны бар кылган Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгаләгә хәмед-сәнәләребез булса иде. Без Аңа иман китердек вә Аңа өметләнәбез. Бары тик Аллаһы Тәгаләдән ярдәм, мәгъфирәт, һидаяткә һәм туры юлга бастыруны сорыйбыз. Без, гөнаһлы уй-фикерләр, гамәлләрдән ерагаеп, Аңа мөрәҗәгать итәбез.

Дөреслектә, Бер булган Аллаһтан кала бүтән илаһ юк! Аның камиллегенә беркем дә һичкайчан ирешә алмас. Бары тик Ул гына бар нәрсәгә дә кодрәтле.

Шулай ук Мөхәммәд ﷺ Аллаһның илчесе вә Аның колы, дип шәһадәт китерәбез. Йә Раббым, Мөхәммәдкә ﷺ Үзеңнең рәхимлегеңне ирештерсәң иде. Аның туганнарына, сәхабәләренә вә алардан соң килгән мөэминнәргә дә Үзеңнең юмартлыгыңны күрсәтсәң иде.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

قُلِ اللَّهُمَّ مَالِكَ الْمُلْكِ تُؤْتِي الْمُلْكَ مَن تَشَاءُ وَتَنزِعُ الْمُلْكَ مِمَّن تَشَاءُ وَتُعِزُّ
مَن تَشَاءُ وَتُذِلُّ مَن تَشَاءُ ۖ بِيَدِكَ الْخَيْرُ ۖ إِنَّكَ عَلَىٰ كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ ﴿٢٦﴾

**«Ий Аллаһ, Син барча байлыкка патшасың, Үзең теләгән кешегә байлыкны бирәсең һәм Үзең теләгән кешедән байлыкны аласың, теләгән бәндәңне Коръән белән гамәл кылдырып, хөрмәтле итәсең һәм теләгән бәндәңне Коръәннән гафил кылып, хур итәсең. Барча хәйрият Синең кулыңдадыр, шиксез, Синең һәр нәрсәгә көчең җитә», – дип әйт».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:26

Шулай ук:

إِنَّ اللَّهَ يَرْزُقُ مَن يَشَاءُ بِغَيْرِ حِسَابٍ

**«Аллаһ, әлбәттә, Үзе теләгән бәндәсен хисапсыз ризыкландыра».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:37

Ягъни Аллаһы Тәгалә шушы рәвештә дога кылырга куша һәм Үзе теләгән колына көтмәгән җирдән ризык та бирүе турында әйтеп китә.

Хәзрәти Галинең оныгы Җәгъфәр Әс-Садыйк: «Әгәр дә кеше үзенең ризыгын артуын, гөнаһларының кичерелүен, юкка чыгуын теләсә, ул һәрвакытта да Аллаһы Тәгаләгә шөкрана кылырга, һәрвакытта да Аңа хәмед-сәнәләр, мактаулар әйтергә, гел тәүбәдә булырга тиеш», – дип әйтә.

Аллаһы Тәгалә дә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

وَإِذْ تَأَذَّنَ رَبُّكُمْ لَئِن شَكَرْتُمْ لَأَزِيدَنَّكُمْ ﴿٧﴾

**«Дәхи Раббыгыз сезгә белдерде: «Әгәр нигъмәтләремә шөкер итсәгез, нигъмәтемне сезгә арттырырмын».**

«Ибраһим», 14:7

Шулай ук:

فَقُلْتُ اسْتَغْفِرُوا رَبَّكُمْ إِنَّهُ كَانَ غَفَّارًا ﴿١٠﴾ وَيُمْدِدْكُم بِأَمْوَالٍ وَبَنِينَ
وَيَجْعَل لَّكُمْ جَنَّاتٍ وَيَجْعَل لَّكُمْ أَنْهَارًا ﴿١٢﴾

**«Һәм әйттем аларга: «Тәүбә итеп Раббыгызга истигъфар кылыгыз, гафу сорагыз, шиксез, Ул гөнаһларны ярлыкаучы. Вә сезгә күктән яңгырны коеп яудырыр. Вә сезгә мал белән ярдәм итәр һәм балалар биреп куәтләр, дәхи җимеш үстерә торган бакчалар һәм елгалар бирер».**

«Нух», 71:10-12

Сөләйман пәйгамбәр һәм кырмыска турындагы хикәяне күбегезнең ишеткәне бардыр, шулай да искә төшерү зарар итмәс. Сөләйман пәйгамбәр ﷺ диңгез яры буенда утырып торганда, Аллаһның Үз мәхлукларын ничек итеп туендыруы турында уйлап куя. Шулвакыт авызына яшел яфрак капкан бер кырмысканы күреп ала. Кырмыска акрын гына диңгез ярына кадәр килде. Диңгездән бер бака чыгып, кырмыскадагы яфракны алды да, кире су төбенә төшеп китте.

Сөләйман пәйгамбәр аптырап, кырмыскадан бу хәл турында сорарга булды. Кырмыска:

– Аллаһы Тәгалә бу диңгезнең уртасында бер таш, ә шул таш уртасында бер бөҗәкне барлыкка китерде. Мине исә Аллаһы Тәгалә бу бөҗәкнең туклануына сәбәп итеп кылды. Шуңа күрә көн саен шушы диңгезнең яр кырыена үзем күтәрә алырлык һәм бу бөҗәккә җитәрлек ризык алып киләм. Бака бу ризыкны миннән алып, шул таш уртасында яшәгән бөҗәккә бирә. Бу бөҗәк ризыкны алгач: «Мине диңгез уртасындагы таш эченә урнаштырган һәм минем турында онытмаган Аллаһы Тәгаләгә дан вә мактау булсын», – дип дога кыла», – дип җавап бирә.

Кешеләрнең дә бит төрлесе бар: кемдер йөри, эшли ала, кемдер өендә генә утырып тора, кемнеңдер күзе күрми, кемнеңдер колагы ишетми. Ә Аллаһы Тәгалә һәрберсенә ризыгын биреп тора.

Гомумән, шушы кырмыска мисалын гына алсак та, безнең тормышта да шулай бит. Без кайдадыр хезмәт итәбез, шунда безгә хезмәт хакы түлиләр, без шуңа яшибез. Без ризыкны шушы фәлән кешедән килә, я фәлән җирдән килә, дип уйлыйбыз. Юк! Ризыкны Аллаһы Тәгалә бирә. Ләкин ул бит аны турыдан-туры, күктән иңдерми, кемдер аша бирә.

Хуҗа Нәсреддин белән булган вакыйганы да искә төшереп үтик:

Бервакыт Хуҗа Нәсреддиннең хатыны төне буе: «Синең бит өйгә 20 дирһәм булса да алып кайтканың юк», – дип әйтеп, аның теңкәсенә тиеп чыккан. Хуҗа түзеп тора алмагач, ишегалдына чыккан да, кулларын

күтәреп: «Йә Раббым, Синдә 20 дирһәм генә бар бит инде, бир инде миңа шуны, хатыным иза чиктерә бит», – дип дога кыла башлый. Күршедә яшәүче бер байның үзенең өй түбәсенә чыгып, күккә карап утырган вакыты була. Хуҗаның бу сүзләрен ишеткәч, аннан көлеп алырга уйлый. Янчыкка нәкъ 20 дирһәм сала да, Хуҗаның учына ата. Хуҗа исә шатланып: Раббым, Син болай да ирештерәсеңмени?» – дип дога кылып, өенә кереп китә. Иртә белән теге бай күршесе кереп: «Йә Хуҗа, бер көлеп алдым, минем 20 дирһәмемне кайтар. Мин бу янчыкны синнән көлеп алыр өчен генә тотып аттым», – дип әйтә. Хуҗа Нәсреддин: «Ризыкны Аллаһы Тәгалә бирә бит. Кемдер аркылымы, юкмы, ләкин Ризыкны Аллаһ бирә. Менә миңа ярдәм итәргә дипме, әллә инде көлеп алырга дигән уй беләнме, Аллаһ миңа акча бирүне синең күңелеңә керткән. Ә күңелгә килгән һәрбер яхшы фикер Аллаһтан бит», – дип җавап кайтара.

Кайчакларда бик авыр һәлакәткә дучар булган кеше дә исән кала ала. Ник? Димәк, Аллаһы Тәгалә тарафыннан билгеләнгән ризыгы бетмәгән әле. Ә кайчакларда кешенең утырып торган җиреннән дә вафат булуы бар. Димәк, сулар һавасы, эчәчәк суы, ашаячак ризыгы беткән.

Аллаһы Тәгалә кайбер кешеләрне ник бай яраткан да, кайберләрен ник ярлы кылган? Бу сорауга Ислам динендә бик гади карыйлар. Аллаһы Тәгалә һәр кешене үз тәкъдире белән яраткан бит: кемгәдер ризыкны күп итеп язган, кемгәдер аз итеп. Әгәр дә шуны кабул итә алсак, бу безнең шөкрана кылуыбыз була. Ә шөкрана кылучы кешегә Аллаһы Тәгалә ризыкны арттырып бирә.

Пәйгамбәребез ﷺ: «Әгәр дә бу дөнья Аллаһ каршында чебен канатыннан кадерлерәк булса, Ул имансыз кешегә бер тамчы су да бирмәс иде»[1], – дип әйтә.

---

1 Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан

Ләкин Аллаһы Тәгалә һәр кешегә ризыгын биреп тора, жәлләми. Безгә дә Аллаһ биргәннәргә разый булып, шөкрана кылып яшәргә кирәк иде. Авызыбыздан: «Әлхәмдүлилләһ», – дигән сүзләр төшмәсен иде.

Пәйгамбәребезнең бер хәдисендә: «Аллаһы Тәгаләнең иң яраткан ризыгы – бер ризыкка күп куллар сузылганы», – дип әйтелә.

Ягъни Аллаһы Тәгалә күп кешеләрнең бер өстәл артында җыелып ашауларын хуп күрә, дип әйтәсе килә. Әзерләнгән ризыкны калган мөэмин мөселманнар белән бүлешергә кирәк дигәнне аңлата бу.

Ибраһим пәйгамбәр عليه السلام беркайчан да берүзе, ялгызы гына утырып ашамаган. Моның кыйссасын беләсез:

Бервакыт Ибраһимның ишеген бер кеше шакый: «Әй, Ибраһим, миңа бераз гына ризык бир», – дип әйтә ул. Ибраһим аннан: «Син мөселманмы соң? Аллаһны таныйсыңмы? Аңа итагать итәсеңме?» – дип сорый. Ул исә: «Мин әлегә аннан ерак шул», – дип җавап кайтара. «Алайса кит, мин сиңа ризык бирмим», – дип, Ибраһим теге кешене чыгарып җибәрә. Шулвакыт Аллаһтан Ибраһим пәйгамбәргә вәхи иңә: «Ий, Ибраһим, мин бу кешене, аның Миңа итагать итмәвенә карамастан, бу дөнья йөзендә инде ничә еллар ризыкландырып торам. Бу җир йөзендә ничә мәхлук бар: мөселманнар, кәферләр, хайваннар, бөҗәкләр – барысына да ризык биреп торам. Алар күпме тели – шуның кадәр тукландырам. Ә син Минем бер мәхлугыма ризык бирмәдең». Ибраһим бу кешене эзләп таба, аны алып кайтып, гафу үтенә. Ризык бирә. Бу кеше, Аллаһның рәхмәтен күреп, иман китерә, ягъни мөселман була. Менә шуннан бирле Ибраһим عليه السلام беркайчан да үзе генә ашамаган. Берәр кунак килгәнен көткән, йә урамнан берәрсен чакырып, шуның белән уртаклашып ашый торган булган.

Фәрештәләр Лут пәйгамбәрнең عليه السلام кавемен юк итәргә дип килгән вакытта да, Лут аларның фәрештә икәнлекләрен белмәде. Кунакларына соңгы бозавын чалып, аларга шуны китерә. Соңгы ризык! Кунакларга хөрмәт күрсәтү – Пәйгамбәребезнең ﷺ сөннәте.

Беркайчан да кәфер булган кешегә кәфер дип әйтмәгез, чөнки берәр көнне ул иманга килә ала. Мөселман да бер көнне, Аллаһ сакласын, кәфер була ала.

Шуңа күрә, кабаттан хәдисне исегезгә төшерәсе килә: «Аллаһы Тәгаләнең иң яраткан ризыгы – бер ризыкка күп куллар сузылганы».

Шулай ук икенче бер хәдистә: «Һәрбер ризык өчен җавап тотасыгыз бар. Әмма бергә җыелып, Коръән укылган мәҗлестәге ризык өчен генә җавап тотмаячаксыз», – дип әйтелә. Без, татарларда, бу бик таралган күренеш: ашлар үткәрәбез, Коръән укыйбыз. Аллаһ бу гамәлләребезне кабул итсен.

Хәдисләрдә ураза турында да килә. Әгәр берәр кеше ураза тоткан кешене бер йотым су белән генә булса да авыз ачтырса, шул ураза тотучы алган савап кадәр савап алыр, ди. Аз гына ризык, йә бер йотарлык су – күпме генә тәгам күпме савап бирә. Ә бит ураза тотучының әҗер савабы зур, аны Аллаһы Тәгалә Үзе белгели.

Шуңа күрә кунакларны хөрмәтлик. Мосафир булып йөргән кешеләрне дә хөрмәтлик, аларны алып кереп, сыйландырыйк. «Аллаһы Тәгаләнең иң яраткан ризыгы – бер ризыкка күп куллар сузылганы». Онытмыйк шуны!

Аллаһы Тәгалә һәрберезгә дә малларыбызны күп итеп бирсен. Аларны хәләл кылсын.Үзебезгә дә, балаларыбызга да бәхет, бәрәкәт насыйп әйләсен. Әмин!

*Илдус хәзрәт Фәиз,*

*«Болгар» мәчете имам-хатыйбы*

*2 март вәгазе,*

*Җөмәдәл-ахыр аеның 14 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Аллаһы Тәгаләнең колларына карата булган рәхмәте

Барча галәмнәрне юктан бар кылучы, Бөек кодрәт иясе Раббыбыз Аллаһка мактауларыбыз, хәмед-сәнәләребез, Аллаһы Тәгалә биргән чиксез нигъмәтләренә сансыз шөкранәләребез, рәхмәтләребез булса иде. Ике гаеткә караганда да бөегрәк булган җомга көннәрен зурлап, Аллаһ Раббыбызның чакыруларын кабул итеп, ерак араларны якын кылып, Аның мөбарәк йортларына җыелышып, Раббыбызның кадерле кунаклары булып утырганда, шушы сәгатьләрдә һәрберебезнең ихлас күңелләребездән чыккан сәламнәребезне, салаватларыбызны бездән кабул итеп, шушы галәмгә рәхмәт итеп җибәрелелгән, барчаларыбызга да күркәм үрнәк күрсәтүче булган, Аллаһ Раббыбызның әмер-таләпләрен безләргә 23 ел буе ирештереп, илчелек, расүллек вазифасын үтәп, ахыйрәт тормышына күчкән, расүлебез Мөхәммәд Мостафа ﷺ хәзрәтләренә, аның әһле бәйтенә, сәхабәләренә, тәбигыйннарга, янә аларга иярүчеләргә Аллаһ Раббыбыз ирештерсә иде. Ике җомга арасында фани дөньядан Ахирәт тормышына күчкән якыннарыбызның, дин кардәшләребезнең Аллаһ Раббүл Гыйззә рухларын шат кылып, авыр туфракларын җиңеләйтсә иде. Калган көннәребездә дә безгә, Ислам дөньясына Аллаһ Раббүл Гыйззә күркәм сабырлык бирсен, Ватаныбызны сугыш афәтеннән, табигать гарасатларыннан, өммәтебезне фетнәләрдән Үзе сакласын. Күңел тынычлыкларыбыздан аермыйча, һәрбер көнебез өчен Үзенә шөкер кылып яшәргә насыйп әйләсен.

Гомәр Әл-Хаттаб мондый хәдис тапшыра:

«Бервакыт Пәйгамбәребез ﷺ янына тоткынга эләккән хатыннарны һәм балаларны алып килделәр. Алар арасында тырыша-тырыша үз баласын эзләүче бер хатын да бар иде. Ул аны табып, бик каты итеп кочаклап алды. Ашата башлады. Пәйгамбәребез ﷺ бездән: «Бу хатын үз баласын утка ташлый алыр идеме?» – дип сорады. Без исә: «Юк, Аллаһы Тәгалә белән ант итәбез, бу хатын мондый эшне эшли алмас иде», – дип әйттек. Шуннан соң Пәйгамбәребез ﷺ: «Әй Аллаһы Тәгалә үз колларын бу хатын үз баласын җәлләгәнгә караганда ныграк җәлли»[1], – дип әйтә.

Әй, мөселманнар, дөньяда яшибез. «Аллаһның рәхмәте», – дип һәрберебез дә әйтәбез, йә әйткәнебез бар. Ләкин бер сорау бирәсем килә: без хакыйкый Аллаһның рәхмәте ни икәнен аңлыйбызмы? Күрә алабызмы? Аны кабул итә беләбезме? Кабул итәбезме һәм Аллаһның рәхмәте илә куллана алабызмы бу дөньяда? Әй мөселманнар! Аллаһның йөз рәхмәте бар, шуның берсе генә бу дөньяга иңдерелгән.

Әбү Һөрайра мондый хәдис тапшыра: «Пәйгамбәребез ﷺ: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгаләнең 100 рәхмәте бар. Аллаһы Тәгалә шул 100нең 1сен генә кешеләргә, җеннәргә, хайваннарга вә бөҗәкләргә иңдергән. Шушы рәхмәт аркасында кешеләр бер-берләренә мәрхәмәтлек күрсәтәләр, хәтта кыргый хайван үз баласына карата ярату тоя. Калган 99 рәхмәтне исә Аллаһы Тәгалә Кыямәт көненә кадәр калдырып торды», – дип әйтте»[2].

Әй, кардәшләрем, уйланыйк. Аллаһы Тәгаләнең биргән рәхмәтләре чиксез. Кызганыч, күбебез аны күрә алмый. Шәригатькә карагыз әле, илаһи кануннарга игътибар итегез әле. Берәүләр Аллаһның кануннарын катлаулы, авыр, дип карыйлар. Тик каннуннарны да Аллаһ безгә рәхмәт йөзеннән җиңеләйтеп бирде. Муса عليه السلام кавеменә 50 вакыт намаз фарыз кылынган иде, безнең өммәттә 5 вакыт намаз фарыз кылынды. Аллаһның рәхмәте белән 5кә генә калды, ләкин савабы 50 вакыт намаз кылган ке-

[1] Имам Бохари һәм имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

[2] Имам Бохари һәм имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

бек. Сәфәргә чыкканда да, намазларны кыскартып укырга кушылды. «Аллаһның бүләге ул, кабул итегез», – дип әйтелде. Сырхауларга, мосафирларга ураза фарыз түгел. Бу да зур рәхмәт, ягъни Аллаһы Тәгалә Үз кануннарын безгә җиңеләйтеп бирде.

Әй, мөселман кардәшләрем, Аллаһы Тәгалә безгә, мөселманнарга, кечкенә генә эшләр белән җәннәткә керергә вәгъдә итте. Расүлүллаһ ﷺ: «Зина кылучы хатын-кыз сусаган эткә су бирүе аркасында җәннәткә керде», – дип әйтте. Янә дә: «Кем дә кем юлда комачаулаган бер әйберне (таш, агач ботагын) алып куйса, юлны чистартса, аңа да Аллаһның рәхмәте булыр», – дип әйтте. Изге гамәлләребез Ахирәттәге мизанда авыррак килсеннәр өчен, Аллаһ зикер-тәсбихләр бүләк итте. Гөнаһлардан арыныр өчен тәүбә бүләк итте. Бу Аллаһның рәхмәте түгелме? Эшебездән арып кайтканда, кочакларыбызга ашкынып торган, безне елмаеп каршы алган нарасый-сабыйларыбыз Аллаһның рәхмәте түгелме? Без хезмәт итә торган эшләребез Аллаһның рәхмәте түгелме?

Без сорамасак та, безгә бирелгән нигъмәтләр бар. Аларга күз салыгыз: колак нигъмәтенә, күз нигъмәтенә, аяк нигъмәтенә, акыл нигъмәтенә. Бу Аллаһның нигъмәте түгелме? Аллаһның чиксез рәхмәте бу, газиз дин кардәшләрем. Күрә белүче кешеләр зарланганчы, уйлап-фикерләп карарга тиеш: һаман да нидәндер зарланып, Аллаһның рәхмәтеннән баш тартырга теләмибезме? Ләкин инсан онытылучан. Ул Аллаһның биргән нигъмәтләрен күрми, оныта – оятсызлык күрсәтеп, гөнаһ кыла, Аллаһка каршылык күрсәтә.

Аллаһы Тәгаләнең бик мөбарәк сүзләре бар. Пәйгамбәребез ﷺ кодси хәдистә Аллаһы Тәгаләнең түбәндәге сүзләрен җиткерә: « Ий колларым! Минем каршымда зур гөнаһларны ачыктан-ачык кыласыз. Ә Мин бит аларны йоклый торган урыннарында саклыйм. Мин җеннәргә һәм кешеләргә зур хәбәр җиткердем: юктан бар кылдым, ә алар Миңа түгел, ә башкага гыйбадәт кылалар. Мин аларны ризыкландырам, ә алар башкага

шөкер кылалар. Яхшылыгым колларыма иңә, ә алардан Миңа начарлык кына күтәрелә. Аларда ихтыярым булмаса да, аларның мәхәббәтләренә ирешер өчен төрле нигъмәтләр бирәм, ләкин алар Миңа мохтаҗ булуга кармастан, Мине оныталар, гөнаһ кылып, Мине нәфрәтләндерәләр. Әгәр Миңа берәү кире кайтса, Мин аны ерактан кабул итәрмен, берәү ваз кичсә, якыннан чакырырмын. Әгәр берәү Минем өчен берәр нәрсәне калдырса, аңа арттырып бирермен. Әгәр берәү Минем ризалыгыма ирешергә теләсә, Мин ул бәндәгә теләгәнен бирермен. Әгәр берәү Минем көчемә өметләнсә, ярдәм сораса, Мин аңа тимерне дә йомшак кылырмын. Зикер кылучыларны Үземнең мәҗлесләремдә утыртырмын. Миңа карарга гөнаһ кылучыларны Миңа карата өметләрен өздермим: Миңа тәүбә кылсалар, Мин аларны сөярмен. Дөреслектә, Мин тәүбә кылучыларны һәм пакьлеккә омтылучыларны сөямен. Әгәр алар Миңа тәүбә кылмасалар, Мин аларның табибы булырмын һәм Мин аларга төрле бәлалар китереп, гөнаһларын дәвалармын. Әгәр берәү Мине бөекләсә, Мин дә аны башкалардан өстен күрермен. Дөреслектә, Минем каршымда изгелекнең савабы 10 мәртәбә артыграк язылыр вә 70кә кадәр арттырылыр. Вә изгелегенә карата, сансыз-хисапсыз мәртәбә әҗер-савабын арттырып язармын. Ләкин бер гөнаһ кылса, 1 гөнаһ язармын, арттырмамын. Вә әгәр гафу үтенсә, Мин аны гафу итәм. Мин күпчелек гөнахларны гафу итәм. Минем рәхмәтем ачуыма карганда әүвәлрәк булыр, йомшаклыгым катылыгыма карганда әүвәлрәк булыр вә гафу итүем дә газап бирүгә караганда алданрак килер. Минем колларыма карата мәрхәмәтлегем, ананың баласына булган мәрхәмәтлегеннән күпкә артыграк».

Әй, кардәшләр, Аллаһ, безнең онытылучан булуга карамастан, Аны онытуга карамастан, Үзенең рәхмәтен безгә ирештерә. Онытылуга, гөнаһ кылуга, явызлык кылуга карамастан, Аллаһ безгә вәгъдә итә. Аллаһның рәхмәте ачуына караганда беренчерәк.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

قُلْ يَا عِبَادِيَ الَّذِينَ أَسْرَفُوا عَلَىٰ أَنفُسِهِمْ لَا تَقْنَطُوا مِن رَّحْمَةِ اللَّهِ ۚ إِنَّ اللَّهَ يَغْفِرُ الذُّنُوبَ جَمِيعًا ۚ إِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ ﴿٥٣﴾

**«Минем мөэмин бәндәләремә әйт: «Ий, бәндәләрем, гөнаһ кылып, үзегезгә зарар иткән булсагыз, Аллаһның рәхмәтеннән өметегезне өзмәгез, чөнки тәүбә итеп төзәлгәндә, Аллаһ гөнаһларны ярлыкаучыдыр, Ул – Аллаһ ярлыкаучы вә рәхимледер».**

«Зүмәра / Халык Төркеме», 39:53

Без Адәм балалары, хаталанабыз, ялгышабыз. Ләкин Аллаһка гыйбадәт кылып яшәргә насыйп булсын. Бу дөньяда Аллаһ рәхмәтләрен безгә бирде, Ахирәттә дә җәннәт әзерләде. Әй, кардәшләрем, Аллаһка рәхмәтләребезне гыйбадәт аша, намаз аша бирсәк иде. Ризалыгыбызны күрсәтеп яшәсәк иде. Аллаһтан разый булыйк, Ул да бездән разый булыр.

Кечкенә генә гамәлләр өчен дә чиксез әҗерләр әзерләнгән. «Кардәшеңә елмаю – сәдака». Ә сәдака нәрсә соң ул? Ул – савап. Аллаһның хайваннарына карата мәрхәмәтле булсак, аның өчен дә Аллаһ әҗер бирә бит.

Аллаһы Тәгалә ахыргы көнебезгә кадәр Аңа шөкрана кылып яшәргә насыйп итсен. Шушы дөньяның вә Ахирәтнең бәхетенә ирешергә барыбызга да насыйп булсын. Әмин!

*Илфар хәзрәт Хәсәнов,*

*Кол Шәриф мәчете имам-хатыйбы*

*9 март вәгазе,*

*Җөмәдәл-ахыр аеның 21 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Гомер буе хөрмәтлик!

Бөтен галәмне юктан бар итеп, тәрбия кылучы Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләгә чиксез рәхмәтләребез, шөкраналарыбыз булса иде. Аллаһ Раббыбыз тарафыннан галәмнәргә рәхмәт булarak җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафага ﷺ, аның хөрмәтле гаилә-сенә, барлык сәхабәләренә күңел түрләребездән чыккан сәламнәребез, салаватларыбыз һәм һәртөрле изге догаларыбыз булса иде.

Пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ хатын-кызларга кагылышлы бер хәдисе бар. Шушы хәдистә Пәйгамбәребез: «Аллаһы Тәгалә безгә, ягъни мөселманнарга, түбәндәге васыятьне әйтте: «Сез хатын-кызлар белән матур, йомшак, күркәм мөгамәләдә булыгыз, бу – ирләр өчен вәҗиб, ягъни тиеш булды, чөнки алар – сезнең аналарыгыз, сезнең кыз туганнарыгыз, сезнең кызларыгыз һәм сезнең аналарыгызның туганнары. Берәрегез никахлашып, бер мөселман кызын үзенә хатынлыкка алган икән, аның кимчелекләре булса да, кулыннан эш килмәсә дә, шуңа сабыр итеп, шушы хатынга риза булып, шуның белән матур итеп тормыш корсын», – дип әйткән.

Хатын-кызлар ирләргә караганда көчсезрәк булганга күрә, Аллаһы Тәгалә аларны яклауны ирләргә бурыч итеп куйган һәм без шушы вазифаны үтәргә тиеш тә. Күп кешеләр: «Ислам дине хатын-кызны кимсетә, мыскыллый, анда хатын-кызның бернинди хокукы да юк», – дип әйтәләр. Бу – ялгыш фикер. Әгәр Коръән тәфсирен укып карасак, анда нинди генә эш боерылган булса да, нинди генә эшкә әҗер куелган булса да, ирләр белән хатын-кызлар бертигез җаваплылыкта, дип әйтелгән.

Яхшы ирләр, яхшы хатыннар, тәкъва ирләр, тәкъва хатыннар җәннәтле булырлар.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّ الْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ وَالْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْقَانِتِينَ وَالْقَانِتَاتِ
وَالصَّادِقِينَ وَالصَّادِقَاتِ وَالصَّابِرِينَ وَالصَّابِرَاتِ وَالْخَاشِعِينَ وَالْخَاشِعَاتِ
وَالْمُتَصَدِّقِينَ وَالْمُتَصَدِّقَاتِ وَالصَّائِمِينَ وَالصَّائِمَاتِ وَالْحَافِظِينَ فُرُوجَهُمْ
وَالْحَافِظَاتِ وَالذَّاكِرِينَ اللَّهَ كَثِيرًا وَالذَّاكِرَاتِ أَعَدَّ اللَّهُ لَهُم مَّغْفِرَةً وَأَجْرًا
عَظِيمًا ﴿٣٥﴾

**«Ислам динен риза булып тотучы ирләр вә хатыннарга, вә ышану лазем булган нәрсәләрнең һәммәсенә дә ышанучы ирләр һәм хатыннарга, вә Аллаһка итагать итүче ирләр һәм хатыннарга, вә сүздә һәм гамәлдә туры булган ирләр һәм хатыннарга, сабыр ирләр һәм сабыр хатыннарга, вә күңелләре белән Аллаһка түбәнчелекле булып дин эшләренә мәхәббәт итүче ирләр һәм хатыннарга, вә Аллаһ күрсәткән урыннарга зәкәт вә башка сәдакаларын бирүче ирләр һәм хатыннарга, вә ураза тотучы ирләр һәм хатыннарга, вә зинадан сакланучы ирләр һәм хатыннарга, вә Аллаһны күп зикер итүче ирләр һәм хатыннарга Аллаһ вак гөнаһларына ярлыкауны вә изге гамәлләренә олуг әҗерләр әзерләде».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:35

Һәм гөнаһлы ирләр, гөнаһлы хатыннар җәһәннәмгә керерләр, ягъни һәрнәрсәдә ирләр белән хатын-кыз тигез. Фәкать шаһитлек бирүдә генә хатын-кызлар ирләр белән тигез каралмаган, чөнки хатын-кыз хискә бирелүчән була, аның вакыйгаларга дөрес бәя бирмәве ихтимал. Хатын-

кызның хисләре алданрак йөри. Шуңа күрә ике хатын-кызның шаһитлеге бер ир шаһитлегенә тора. Менә шушы мәсьәләдә генә хатын-кызлар белән ирләр тигез түгел.

Бүтән мәсьәләдә хатын-кызлар белән ирләр тигез, әмма хөрмәтләү, хөрмәт күрсәтү мәсьәләсендә хатын-кызлар, бик күп очракта, ирләрдән өстен дә торалар. Бер сәхабә пәйгамбәребез Мөхәммәдтән ﷺ : «Аллаһтан һәм аның Пәйгамбәреннән соң итагать итәсе кеше кем, мин кемне хөрмәтлим?» – дип сорагач, Пәйгамбәребез: «Әниең», – диде. 3 мәртәбә: «Әниең», – дип, аннан соң гына: «Әтиең»,– дип әйтте. Димәк, Аллаһы Тәгаләгә һәм аның Расүленә итагать иткәннән соң, без иң элек әниләребезгә итагать итәргә тиешбез. Әгәр без әти-әниләребезне рәнҗетеп, аларны тиешенчә тәрбияләмичә, аларга ризасызлык белдереп яшәсәк, намазларыбызны, фарыз гамәлләребезне һич кимчелексез үтәсәк тә, кабул булмаслар. Сират күперен кичкәндә: «намаз укыдыңмы – укыдым», «Аллаһны таныдыңмы – таныдым», «ураза тотыңмы – тоттым», дигән чикләрне үткәндә, «әти-әниеңнең ризалыгын алдыңмы?» – дип сорарлар. Фарызларны үтәп, әти-әнисенең ризалыгын ала алмаган кешеләр шушы киртәне чыга алмаслар, ди, Аллаһ сакласын! Шуңа күрә әни хакы күбрәк. Кыз туганның хакы, ир туганнның хакына караганда, зуррак.

Пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ ирләргә әйткән бер хәдисе бар: «Аллаһы Тәгалә болай дип әйтер: Мин хатын-кызны кәкре кабыргадан яраттым, сез, аны турайтабыз, дип азапланмагыз, сындырырсыз гына, ләкин турайта алмассыз. Шуңа күрә алар белән йомшак мөгамәләдә булыгыз. Аларның кимчелекләренә риза булып яшәгез».

Әмма хатын-кызларга, бигрәк тә никахланган хатын-кызларга таләп тә зур. Алар ирләренең рөхсәтләреннән башка өйдән чыгарга тиеш түгел: кая гына барса да, иренә әйтеп китәргә тиеш. Ир кеше хатыныннан рөхсәт сорамыйча, өеннән чыга ала, хатын-кыз – юк. Кыз карендәшнең хакы да, ир карендәшнекенә караганда зуррак, чөнки кыз кардәш әти-әни йорты-

на барырга, туганының хәлен белергә рөхсәт сорарга тиеш. Бу турыда да хөкем бар. Ирләр хатыннарын әниләренең хәлен белергә озак җибәрмичә торсалар, шулай ук гөнаһлы булырлар. Ир кеше әнисенең хәлен белергә теләгән кыз балага һәрвакыт рөхсәт бирергә тиеш. Рөхсәт бирми икән, гөнаһлы була.

Хатын-кызларның безнең алдыбызда хакы бик зур. Ир кешеләргә гаиләне матди яктан тәэмин итү бурычы йөкләтелгән. Җитмәү булса, моның өчен Аллаһы Тәгалә каршысында ир кеше җавап бирә. Әмма бу хәл хатын-кызларга: «Безнең шул нәрсә юк, бу нәрсә юк», – дип, урамга чыгып, зарланып йөрергә хокук бирми. Пәйгамбәребез ﷺ : «Фарызларын үтәүче ирләреннән зарланмаган хатын-кызлар җәннәтле булырлар, – дип әйтә. Никахланып, риза булып яшәгәндә, ир кешегә хатын-кыз булдыксызрак тоелса да, сабыр итәргә тиеш. Хатын-кыз да, ире тиешенчә мал табып бетерә алмаса, моңа шөкранә кылып, риза булып торырга бурычлы. Аларның риза булып, бер-берсенә сабыр булып гомер итүләре – үзе бер гыйбадәт.

Ислам дине буенча да хатын-кызларга таләп бик зур. Алар – нәселне дәвам итүчеләр, алар – безнең киләчәгебезне дәвам итүчеләр, хәл итүчеләр. Шуңа күрә аларга кием мәсьәләсендә дә таләпләр катгыйрак куела. Риза булып кияүгә чыккан, гаилә булып яшәргә килешкән икән, никахлы ир хатынының бизәнеп-төзәнеп, чәчен тузгытып, изүен, аякларын ачып, урамда кемнедер кызыктырып йөрүе кемгә кирәк? Моннан гаилә ныгыймы, үзенә, балаларына, киләсе буынга әйбәт буламы?

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ : «Тиешсез киемнәр белән тиешсез рәвештә урамда йөрсәгез, зәгыйфь иманлы бәндәләрнең сезгә зыян салулары бар. Шуңа күрә сез, хатын-кызлар, урамга артык бизәнеп чыкмагыз. Бизәнеп, матурланып, ирләрегезнең өегезгә кайтканын көтеп торыгыз», – дип әйтә. Ә бүгенге көндә ничек? Хатын-кыз нинди матур кииеме бар, нинди бизәнү әйберләре бар, шуларны киеп, урамга чыга. Ә ертылып-бу-

ялып беткән сәләмәсен киеп, ирен каршылый. Бу – безнең дөрес тәрбия бирмәвебезне күрсәтә. Кайбер очракларда зәгыйфь, авыру, җитлекмәгән балалар туугa да хатын-кызларның үзләрен тиешенчә тотмаулары сәбәп булырга мөмкин. Алар мөселманнарга хас киенеп, мөселманнарча яшәсәләр, акылга зәгыйфь, авыру балаларның тууы бик күпкә ким булыр иде.

Без хатын-кызга ирек куябыз, дип, аларны пычрак булган фермаларга керттек, чүкеч тоттырып тимер юлларга чыгардык, агулы җитештерү хуҗалыкларына керттек. Алар бала тәрбияләүдән читләштерелделәр. Бөтен эштә алга китеп, кайберсендә ирләрдән дә уздырып җибәрәләр, акчаны да ирләрдән күбрәк алалар. Әмма Аллаһы Тәгалә тарафыннан аларга куелган вазифа – балалар тәрбияләү. Аларга ана булу вазифасы йөкләнгән. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә аларга кием мәсьәләсендә дә, әхлак мәсьәләсендә дә катгый таләпләр куйган. Бозык агачта яхшы җимеш үсми. Аллаһы Тәгаләнең шушы таләпне куюның максаты – нәсел агачын, нәселне дәвам итә торган агачны сәламәт килеш тоту. Аны хатын-кызлар ниндидер кимсетү, ирекне чикләү, дип кабул итте. Хөррияткә чыгып, уңышка ирешәбез дип, бозылдылар. Җимешләр дә бозык. «Исламга кайтабыз, әхлакны төзәтәбез», – дип әйтәбез икән, хатын-кызларыбыз, иң беренче чиратта, милләтнең аналары булырга тиеш. Яхшы балалар үстерүче, үзләреннән соң яхшы буын калдыручы ана булырга тиеш. Ә ирләр гаиләне, тормышны алып баручы көчкә әйләнергә тиеш.

Үзебезне мөселманга саныйбыз икән, «Ләә иләһә илләллаһ, Мүхәммәдүр-Расүлүллаһ», дип әйткәнбез икән, кызларыбызга да яхшы караш булырга тиеш. Аларга без тиешле тәрбияне бирергә тиешбез. Пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ шундый бер сөенечле хәбәре дә бар: «Кем шәригатькә муафыйк итеп, өч кыз бала тәрбияләп үстерә, бу кешегә җәннәт вәҗиб булыр», – дип әйтә. Һәм сәхабәләрнең берсе: «Ике кыз үстерсә?» – дип сорагач: «Ике кызны да шәригатькә муафыйк итеп үстерсә,

ул кешегә дә җәннәт вәҗиб булыр, – дип әйтә. Ни өчен, чөнки ул милләтне дәвам итүче, динебезне дәвам итүче буын калдыра, ике ана үстергән була ул. Ягъни, әгәр ике кыз баланы шәригатебез кушканча тәрбияләп үстерсә, әҗере җәннәт булыр. Бу бит зур сөенеч.

Без хатын-кызларыбызга булган хөрмәтнең әҗере турында сөйләштек. Инде бөтенебезгә билгеле булган, язның беренче бәйрәме булган 8 нче март бәйрәмнәре үтеп китте. Бу көннәрдә хатын-кызларыбызны тагын да зурлыйк, бүләкләр бирик, матур сүзләрне әйтеп, аларны сөендерик! Үзебезнең әниләребезгә, балаларыбызга алып кайткан бүләк – сәдаканың иң зурысы. Ләкин әниләребезне, балаларыбызны хөрмәтләү шушы 8 нче март көнне генә түгел, ә ел буе, гомер дәвамында булырга тиеш. Пәйгамбәребез безне өйрәтеп, хәдисләрен әйтеп калдыруы боларга дәлил булып тора.

Аллаһы Тәгалә барча мөэмин хатын-кызларга иман байлыгы, хатын-кыз бәхете бирсә иде. Ә иманга килә алмаганнарга күңелләрен ачып, һидаять нуры салса иде. Барыбызны да монда җыйган кебек, Үзенең җәннәтләрендә җыйса иде. Әмин!

*Җәлил хәзрәт Фазлыев,*
*Татарстанның баш казые*

*16 март вәгазе,*

*Җөмәдәл-ахыр аеның 28 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Раҗәб ае һәм аның фазыйләтләре

Әгүүзү билләәһи мин әш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир рахииим

Бөтен галәмнәрнең Раббысы булган, безне мөбарәк кичәләр белән бүләкләгән Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләгә биниһая хәмед-сәнә, шөкраналарыбыз булса иде. Безнең өчен һәр хәлебездә иң күркәм үрнәк булган нурлы Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ хәзрәтләренә, аның хөрмәтле әһеленә, сәхабәләренә күңел түрләребездән чыккан сәламнәребез, салаватларыбыз һәм һәртөрле изге догаларыбыз булса иде.

Газиз дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәракәтүһ! Раҗәб һәм шәгъбан – Рамазан ае турында алдан хәбәр бирә торган айлар булып тора. Бу ике мөбарәк ай аша без изге Рамазанга күчәбез. Бу айларда без Рамазанга әзерләнәбез. Бүгенге вәгазебез, ин шә Аллаһ, Раҗәб ае һәм аның фазыйләтләре турында булачак.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ хәзрәтләре бер хәдистә: «Раҗәб – Аллаһның ае, шәгъбан — минем аем, ә Рамазан — өммәтемнең ае», – дип әйткән. Берәү Пәйгамбәребездән ﷺ: «Йә, Расүлүллаһ, ни өчен Раҗәб — Аллаһ ае соң ул?» — дип сораган. Расүл әкрам ﷺ: «Бу айда чын күңелдән тәүбә итүчеләргә Аллаһы Тәгаләнең мәгъфирәте иңә, бу айда кан түгү, сугышлар тыелган, бу айда Аллаһы Тәгалә бөтен пәйгамбәрләрнең догаларын кабул кылган һәм күп кенә әүлияләрне (изгеләрне) дошман кулларыннан коткарган», – дип аңлаткан.

Раҗәб аенда кылган изге гамәл-гыйбадәтләр өчен Аллаһ Раббыбыз савапларны арттырып бирә. Бу айда сәдакалар бирү, фәкыйрьләрне аша-

ту, мескеннәрне шатландыру, вакытында укылмаган намазларны каза кылу, «Ихлас» сүрәсен ешрак уку күркәм гадәт булып тора.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ хәзрәтләре раҗәб аеның беренче җомгасына каршы булган кичтә уяу булырга киңәш иткән. Фәрештәләр аны Рәгаиб кичәсе дип атаганнар. Күп гасырлар дәвамында мөселманнар бу кичәгә зур әһәмият бирәләр. Бу вакытта догалар кабул була. Сөекле Пәйгамбәребез ﷺ: «Биш кичәдә Аллаһы Тәгалә уз колларының үтенечләрен кабул кылыр: Рәгаиб, Бәраәт, Җомга киче, Рамазан һәм Корбан гаетенә каршы кичәләр»[1], – дип әйткән.

Бу кичәләрдә мөселманнар Раббылары һәм тормышлары турында уйланалар, фикер йөртәләр, Коръәнне күп итеп укыйлар, догалар кылалар. Аллаһы Тәгалә безгә бу кичәләрдә гөнаһлардан пакьләнергә, үзебезнең изге ниятләргә, максатларга ирешергә зур мөмкинлекләр бирә. Без бу кичәләргә игътибарлырак булырга, аларны шатланып, сөенеп каршы алырга тиешбез.

Нинди көн соң ул Рәгаиб кичәсе? Бу — сөекле Пәйгамбәребезнең ﷺ әтисе Габдуллаһ белән әнисе Вәһб кызы Әминәнең никахлашкан көннәре. раҗәб ае тагын бер мөбарәк кичә белән бизәкләнгән. Ул — Мигъраҗ кичәсе, раҗәб аеның 26 нчы көненнән 27сенә каршы кичтә була. Мигъраҗ — күккә ашу дигән мәгънәне аңлата һәм бу кичә пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ хәзрәтләренең тормышында олуг могҗиза булып санала.

Раҗәб аеның 27 нче төнендә Расүлебез ﷺ Аллаһның кодрәте белән гадәти булмаган сәфәр кыла. Бу хакта Аллаһ Раббыбыз «Исра» сүрәсенең 1 нче аятендә болай дип әйтә:

سُبْحَانَ الَّذِي أَسْرَىٰ بِعَبْدِهِ لَيْلًا مِّنَ الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ إِلَى الْمَسْجِدِ الْأَقْصَى
الَّذِي بَارَكْنَا حَوْلَهُ لِنُرِيَهُ مِنْ آيَاتِنَا ۚ إِنَّهُ هُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ ﴿١﴾

1 Имам Дәйләми хәдисләр җыентыгыннан

**«Үз колын бер төндә Хәрам мәчеттән аятьләребезне күрсәтү өчен тирә-ягын бәрәкәтле иткән Ерак мәчеткә күчергән Затка дан! Ул, чынлап та, һәрнәрсәне Ишетүче, Күрүче».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:1

Риваятьләр буенча, Расүлебез Мөхәммәд ﷺ Мәккә Мөкәррамә шәһәрендәге Хәрам мәчетендә («Изге мәчет»), ягъни Кәгъбәтуллаһ янында йоклап яткан вакытында, Җәбраил фәрештә «Борак» (мәгънәсе — «яшен тизлегендә оча торган») дип аталган хайванга атланып килә. Пәйгамбәребез ﷺ Борак белән яшен тизлегендә Хәрам мәчетеннән Кодыс шәһәрендәге (Иерусалим) Әл-Әкъса мәчетенә («Ерак мәчет») күчә. Шунда Аллаһның расүле Мөхәммәд ﷺ башка пәйгамбәрләргә имам булып, алгы сафта намаз укый. Шулай итеп Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребезнең ﷺ башка пәйгамбәрләрдән өстен булуын күрсәтә. Соңрак Мөхәммәдкә ﷺ өч савыт китереп куялар: аларның берсендә су, икенчесендә сөт һәм өченчесендә шәраб (хәмер) була. Аллаһның Расүле ﷺ сөт салынган савытны сайлый. Җәбраил фәрештә Пәйгамбәребезнең ﷺ сайлавын күргәч: «Әй, Мөхәммәд, син һәм синең өммәтең дөрес юлда. Исерткеч эчү — хәрам!»—дип әйтеп җибәрә. Сөтнең ак төсе хакыйкатьнең, дөреслекнең, иминлекнең билгесе булып тора. Шуннан соң Аллаһы Тәгаләнең әмере килә: Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ Җәбраил фәрештә белән күккә менәләр. Мөхәммәд ﷺ җиде кат күк аша үткәндә, аның һәр капусында үзенә кадәр Җир йөзенә килеп киткән пәйгамбәрләр: Адәм, Идрис, Муса, Гайсә һәм Ибраһим белән очраша. Җәбраил фәрештә махсус бер чиккә – Сидрә мәкамгә кадәр генә бара ала. Шунда җиткәч, Җәбраил фәрештә: «Миңа куелган чик шушында бетте, алга таба барырга рөхсәт юк», — дип әйтә. Пәйгамбәребез ﷺ сәфәрне үзе генә дәвам итә. Расүлебез ﷺ җәннәт белән җәһәннәм галәмәтләрен күрә, Аллаһы Тәгалә белән сөйләшү бәхетенә ирешә. Аллаһ хозурына баргач:

«اَلتَّحِيَّاتُ لِلّٰهِ وَالصَّلَوَاتُ وَالطَّيِّبَاتُ», — дип сәламли, ягъни «Тел һәм тән гыйбадәтләребез барысы да фәкать Аллаһ өчен генә». Аллаһы Тәгалә:

«اَلسَّلاَمُ عَلَيْكَ اَيُّهَا النَّبِيُّ وَرَحْمَةُ اللهِ وَ بَرَكَاتُهُ», — дип җавап бирә, ягъни «Әй, Пәйгамбәр, сиңа Раббыңның сәламе, рәхмәте вә бәрәкәте булсын». Моңа каршы Пәйгамбәребез ﷺ :

«اَلسَّلاَمُ عَلَيْنَا وَ عَلٰى عِبَادِاللهِ الصَّالِحِينَ» , — дип әйтә, ягъни «Безгә һәм Аллаһы Тәгаләнең һәрбер изге бәндәләренә дә сәлам булсын». Шуннан соң фәрештәләр:

«اَشْهَدُ اَنْ لآ اِلَهَ اِلاَّ اللهُ اَشْهَدُ اَنَّ مُحَمَّدًاعَبْدُهُ وَرَسُولُهُ», — диделәр, ягъни «Чын күңелдән бер Аллаһтан башка һичбер илаһ юк, Мөхәммәд — Аның колы һәм илчеседер, дип шәһадәт бирәбез», – дип, «Шәһадәт кәлимәсе»н әйтәләр.

Хөрмәтле мөселманнар! Бу сүзләрне без барыбыз да намазда, ягъни кагъдәдә, «Әттәхият»кә утыргач әйтәбез. Без өч затның: Аллаһы Тәгаләнең, Пәйгамбәребезнең һәм фәрештәләрнең әйткән сүзләрен кабатлыйбыз, шуңа күрә хәдис-шәрифтә: «Намаз – мөэминнең мигъраҗы», — дип әйтелгән. Димәк, намазда без Аллаһы Тәгалә белән сөйләшәбез, Аңа мөрәҗәгать итәбез, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аңа якын булабыз. Шундый олуг бәхеткә көн саен биш тапкыр ирешеп торабыз. Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә шушы кичәдә Пәйгамбәре Мөхәммәдкә ﷺ өч бүләк тапшыра:

– биш вакыт намаз фарыз кылына;

– «Бәкара» сүрәсенең ахыргы аятьләре бирелә (285-286 нчы аятьләр);

– Пәйгамбәребезгә ﷺ Кыямәт көнендә өммәтен яклау хокукы бирелә, ягъни Пәйгамбәребез ﷺ Кыямәт көнендә гөнаһлы мөселманнарга ярдәм биреп (шәфәгать кылып), аларны газаплардан коткара алачак.

Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә намазларыбызны вакытында, дөрес һәм ихлас күңел белән укып, бу дөньяда һәм Ахирәттә бәхеткә ирешергә насыйп итсә иде.

*Нияз хәзрәт Сабиров,*

*Апанай мәчете имам-хатыйбы,*

*ТЖ МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе*

*23 март вәгазе,*

*Раҗәб аеның 5 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Могҗизалар

Барча галәмнәрне барлыкка китергән, тәрбияләп торучы Аллаһы Тәгаләгә хәмед-сәнәләребез булса иде. Иң яраткан пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафага да ﷺ күңелләребезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

وَقَالُوا لَوْلَا أُنزِلَ عَلَيْهِ آيَاتٌ مِّن رَّبِّهِ ۖ قُلْ إِنَّمَا الْآيَاتُ عِندَ اللَّهِ وَإِنَّمَا أَنَا نَذِيرٌ مُّبِينٌ ﴿٥٠﴾

**«Мөшрикләр әйттеләр: «Әгәр Мөхәммәдкә Раббысыннан аның пәйгамбәрлегенә могҗизалар иңдерелгән булса, ни булыр иде». Син аларга: «Могҗизалар Аллаһ хозурындадыр, мин фәкать ышанмаган һәм итагать итмәгән кешеләрне җәһәннәм газабы белән куркытучымын», – дип әйт».**

«Ганкәбут / Үрмәкүч», 29:50

Һәр пәйгамбәр могҗиза белән килә. Могҗиза – ул гадәттән тыш, кеше аңы белән аңлатып булмый торган хәл, пәйгамбәрлекне дәгъва кылучының дәгъвасына муафыйкъ булып күренә торган эш. Могҗиза пәйгамбәрлеккә дәлил һәм ялганчы пәйгамбәрләр белән пәйгамбәрләр арасын аеру өчен бер билге булып тора.

Нишлисең, кеше нәфес белән, тыелганга кызыгучан булып яратылган. Ул бүген дә диннән ниндидер могҗиза көтә. Аның өчен «бул», дип әйт һәм син теләгән әйбер булсын. Әмма бу Аллаһы Тәгаләнең сыйфат-

ларыннан бер сыйфат һәм фәкать Аллаһы Тәгалә «бул», дип әйтеп кенә нәрсәдер булырга мөмкин.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّمَا أَمْرُهُ إِذَا أَرَادَ شَيْئًا أَن يَقُولَ لَهُ كُن فَيَكُونُ ﴿٨٢﴾

**«Аллаһ бер нәрсәнең бар булуын теләсә, ул нәрсәгә фәкать «Бул!», дип әйтер һәм ул нәрсә булыр».**

«Йәсин», 36:82

Ә бит Аллаһы Тәгалә теләсә кем әйткәнне булдырмый, бәлки Үзенең теләге белән генә, алда әйтеп кителгәнчә, пәйгамбәрләре теләгән нәрсәләрне генә, аларның пәйгамбәрлекләрен дәлилләү өчен генә булдырырга мөмкин һәм анысы да әле һәрвакыт түгел. Мәсәлән, Пәйгамбәребезгә ﷺ кәферләр Кәһеф егетләре кыйссасы турында сорау белән киләләр, ул: «Иртәгә килегез, җавап бирермен», – ди, һәм вәхи вакытлыча өзелә, чөнки ул «ин шә Аллаһ», ягъни «Аллаһ теләсә», дип әйтмәгән була. Шуннан соң 15 көн вәхи килмәгән. Корәеш мөшрикләре аның турында начар сүзләр сөйли башлаганнар. Бу вакыйгадан соң Аллаһы Тәгалә түбәндәге аятьләрне иңдерә:

وَلَا تَقُولَنَّ لِشَيْءٍ إِنِّي فَاعِلٌ ذَٰلِكَ غَدًا ﴿٢٣﴾ إِلَّا أَن يَشَاءَ اللَّهُ ۚ وَاذْكُر رَّبَّكَ إِذَا نَسِيتَ وَقُلْ عَسَىٰ أَن يَهْدِيَنِ رَبِّي لِأَقْرَبَ مِنْ هَٰذَا رَشَدًا ﴿٢٤﴾

**«Әгәр бер эшне эшләргә теләсәң: «Мин бу эшне иртәгә эшләрмен», – дип әйтмә. «Мәгәр Аллаһ теләсә эшләрмен», – дип әйт! «Әгәр Аллаһы Тәгалә теләсә», дип әйтергә онытсаң, хәтереңә килгәч тә: «Аллаһ теләсә», – дип әйт! Янә: «Бу егетләрнең барча хәлләрен Раббымның миңа белдерәчәге өметледер», – дип әйт».**

«Кәһф / Тау Тишеге», 18:23-24

Аллаһы Тәгалә яраткан бу дөнья үзе бер олугъ могҗиза булып тора. Кеше материаль тормышта яши, аны яшьтән үк бер әйбер дә юктан барлыкка килми, бар әйбер юкка чыкмый, дип өйрәтәләр. Моның шулай икәнлегенә күпләр ышана, әмма ни өчендер шушы фикергә нигез салучы галимнәр үзләре үк энә очы кадәр бер ноктадан көчле шартлау нәтиҗәсендә миллиардлар белән исәпләнә торган галактикаларны үз эченә алган Галәм барлыкка килгән, дип саныйлар. Бу Галәм дә бит үзе генә түгел, җеннәр яши торган галәм дә бар. Бәлкем безгә хәбәр ителмәгән башка галәмнәр дә бардыр әле. Әгәр дә бу галәмнәрнең хуҗасы булмаса, әлбәттә, бу фикер белән килешеп булыр иде. Әмма бу галәмнәрнең бер хуҗасы бар һәм ул галәмнәр белән идарә итә, ягъни бар нәрсә дә Аның теләге белән барлыкка килә һәм Аның теләге белән юкка чыга.

Коръән дә «Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Тәгаләгә барча мактау-догалар булса иде», – дигән сүзләр белән башлана.

Аллаһы Тәгалә галәмнәрне халык кылуы турында Коръән Кәримдә әйтә:

وَلَقَدْ خَلَقْنَا السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ وَمَا بَيْنَهُمَا فِي سِتَّةِ أَيَّامٍ وَمَا مَسَّنَا مِن لُّغُوبٍ ﴿٣٨﴾

**«Тәхкыйк, Без җирне, вә күкләрне, вә аларның араларында булган нәрсәләрне алты көн эчендә төзедек, аларны төзегәндә безгә авырлык вә мәшәкать булмады».**

«Каф», 50:38

Аллаһы Тәгалә шулай ук үзенең халык кылган нәрсәләренең кимчелексез икәнлеген күрсәтеп Коръән Кәримдә әйтә:

الَّذِي خَلَقَ سَبْعَ سَمَاوَاتٍ طِبَاقًا ۖ مَّا تَرَىٰ فِي خَلْقِ الرَّحْمَٰنِ مِن تَفَاوُتٍ ۖ فَارْجِعِ الْبَصَرَ هَلْ تَرَىٰ مِن فُطُورٍ ﴿٣﴾

**«Ул – Аллаһ, кат-кат итеп җиде кат күкне халык кылды. Аллаһ халык кылган нәрсәләрдә бер-берсенә туры килмәүләрне күрмәссең. Күзеңне кайтарып күккә кара, анда берәр ярыкны, кимчелекне күрерсеңме?»**

«Мүлек / Патшалык», 67:3

Уйлап карыйк: Кояш, Галактика, Галәм, ә аннары нәрсә? Моңа кешенең акылы җитми. Кешенең акылы җирдәге могҗизаларны фикерләргә дә җитми. Аллаһы Тәгалә кешене балчыктан халык кыла һәм җан өрә. Динсезләр дөньядагы тормыш очраклы рәвештә бер-берсе белән кушылган молекулалардан барлыкка килгән, ди. Миллион еллар очраклы рәвештә барган процессларны лаборатория шартларында аз вакытта да ясарга буладыр, әгәр дә булырлык булса. Ә бит җан иясе молекуладан гына тормый. Молекуладан гына торса ул, бәлки, үлми дә торган булыр иде. Әмма ул үлә. Димәк, үзеннән үзе генә барлыкка килмәгән: аның барлыкка китерүчесе һәм үтерүчесе бар.

Адәм баласы Аллаһы Тәгаләнең мәхлукларыннан бер мәхлук. Аллаһы Тәгалә аңа акыл, фикерләү сәләте бирә. Үзенә булган ышанычын арттыру өчен Раббысы аңа вакыт-вакыт пәйгамбәрләре аркылы могҗизалар күрсәтеп тора.

Пәйгамбәр Ибраһим ﵇ мәҗүсиләрнең потларын җимергәч, Нәмруд патша аны утта яндырырга хөкем итә. Зур итеп учак ягалар һәм Ибраһимны ﵇ шул утка аталар, әмма ул янмый.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

قَالُوا حَرِّقُوهُ وَانصُرُوا آلِهَتَكُمْ إِن كُنتُمْ فَاعِلِينَ ﴿٦٨﴾

**«Ул кавем бер-берсенә: «Ибраһимны утта яндырыгыз. Ут – газапның иң көчлесе. Потларыгызга ярдәм итүче булсагыз, Ибраһимнан үчен алыгыз, аны газаплагыз», – дигәннәр».**

Ибраhимга күпме генә ут ягып та, аны ут яндырмый. Аллаhы Тәгалә болай дип әйтә:

قُلْنَا يَا نَارُ كُونِي بَرْدًا وَسَلَامًا عَلَىٰ إِبْرَاهِيمَ ﴿٦٩﴾

**«Без утка: «Ибраhим өчен салкын һәм сәламәтлек иясе бул, аны көйдермә, сәламәт сакла!» – дип боердык».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:69

Ибн Габбастан болай дип риваять ителә, әгәр Аллаh утка: «Салкынлык иясе бул!» – дип әйтеп, «Сәламәтлек иясе бул!» – димәгән булса, Ибраhим утның салкынлыгыннан туңып үләр иде», – ди.

Аллаhы Тәгалә Салих пәйгамбәргә дөя бирә. Кешеләр Салихтан ﷺ кыядан сирәк очрый торган токымнан булган кызыл ана дөяне һәм аның баласын чыгаруын сорап мөрәҗәгать иткәннәр. Ул Аллаhы Тәгаләгә дога кыла һәм шуннан соң таудан кызыл дөя белән баласы чыга.

Аллаhы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّا مُرْسِلُو النَّاقَةِ فِتْنَةً لَّهُمْ فَارْتَقِبْهُمْ وَاصْطَبِرْ ﴿٢٧﴾

**«Тәхкыйк, Без Сәмуд кавеменә дөяне таштан аларны сынау өчен чыгарабыз, көт син, ий, Салих. Сабыр бул һәм сиңа золым итүләренә чыда».**

«Камәр / Ай», 54:27

Аллаhы Тәгаләнең Мусага ﷺ биргән могҗизасы – Мусаның таягы – ташлагач, чын еланга әйләнә.

Аллаhы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

قَالَ أَلْقِهَا يَا مُوسَىٰ ﴿١٩﴾ فَأَلْقَاهَا فَإِذَا هِيَ حَيَّةٌ تَسْعَىٰ ﴿٢٠﴾ قَالَ خُذْهَا وَلَا تَخَفْ ۖ سَنُعِيدُهَا سِيرَتَهَا الْأُولَىٰ ﴿٢١﴾

**«Аллаһ әйтте: «Ий, Муса, таягыңны җиргә ташла». Муса таягын җиргә ыргытты. Ул таяк җиргә төшү белән корсагында шуышып йөри торган зур елан булды. Аллаһ: «Ий, Муса, бу еланны тотып ал, курыкма, Без аны әүвәлге халәтенә кайтарырбыз», – дип әйтте».**

«Та Һа», 20:19-21

Ягъни елан Муса кулында янә таяк булды.

Корәеш мөшрикләре Пәйгамбәребездән ﷺ могҗиза таләп иттеләр. Мөхәммәд ﷺ дога кылды һәм ай икегә ярылды, Хира тавы айның ике кисәгенең уртасында калды. Шуннан соң «Камәр» сүрәсе иңә.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

اقْتَرَبَتِ السَّاعَةُ وَانشَقَّ الْقَمَرُ ﴿١﴾

**«Кыямәт якынлашты һәм ай ярылды».**

«Камәр / Ай», 54:1

Әмма Мәккә кәферләре барыбер иман китермәделәр. Алар бу эшне сихергә санадылар.

وَإِن يَرَوْا آيَةً يُعْرِضُوا وَيَقُولُوا سِحْرٌ مُّسْتَمِرٌّ ﴿٢﴾

**«Әгәр ул мөшрикләр Безнең кодрәтебез әсәре булган бер галәмәтне, Пәйгамбәребезнең хаклыгына дәлил булган бер могҗизаны күрсәләр, йөз чөерерләр, аңа иман китермәсләр һәм: «Бу эш – башка сихерчеләрнең эше кебек кыска гына вакытка күзгә күренеп китә торган сихер түгел, ә карар кыла торган, кала торган бер сихер», – дип әйтерләр.**

«Камәр / Ай», 54:2

Ягъни айның ярылганын күреп, алар шулай диделәр.

Пәйгамбәребезнең ﷺ кулыннан су чыга, сөт бирми торган сарык бөтен кешегә дә җитәрлек сөт бирә. Бу могҗизалар күп мәртәбәләр кабатланалар.

Ә иң зур могҗиза булып Коръән тора. Мөселман булмаганнар Коръән Кәримгә гади бер әдәби әсәр итеп кенә карыйлар. Әмма Коръәннең могҗиза булуын күрсәтә торган кайбер билгеләр бар:

1. Коръән, кайсы заманда, кайсы урында булуына карамастан, бөтен кеше өчен дә аңлашыла.

2. Коръән кеше һәр көнне куллана торган сүзләрдән тора (ягъни тормыш рәвешен аңлата). Мәсәлән, «Халык Коръәннән аерылды һәм ул бетү алдында».

3. Билгесез нәрсәләрдән хәбәр биреп, шуларның тормышка ашуы.

4. Ничә тапкыр гына кабатланса да, аны тыңлау ялыктырмый.

5. Гарәпләрдә һәм башка халыкларда булмаган гыйлемнәрнең Коръәндә булуы.

6. Үткән хәлләр, үткән кавемнәр турында белдерүе. Коръән иңдерелгән кеше – Пәйгамбәребез ﷺ укый-яза белмәгән. Бу – вәхи иңү белән бәйле булмавы аркасында, хәтта могҗиза тизрәк кабул ителсен өчен.

Адәм баласы пәйгамбәрләргә килгән могҗиза белән генә канәгать түгел. Аның өчен һәр мөселман могҗиза күрсәтергә тиеш. Мөселман кеше бай, кайгы-хәсрәтсез яшәргә тиеш. Ул Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен дөнья байлыгында, дөнья ләззәтендә күрә. Мондый фикер кешедә иманның зәгыйфь булуын күрсәтә. Иманы көчле кеше могҗиза таләп итми, бу дөньяга таянмый. Ул Ахирәткә ышана, Ахирәтне өмет итә. Ул элек булган халыклардан гыйбрәт ала, аларның хаталарын кабатламаска тырыша. Ул үткән халыкларның тарихына карап могҗизаның гади генә күренеш түгел, иманлы кешеләрнең иманнарын ныгыта, ә имансыз кешеләргә һәлакәт алып киләчәген белә. Әгәр дә без кешелек тарихына күз салсак,

күпме халыкларның могҗизаларны кабул итмәүләре сәбәпле һәлакәткә дучар булуларын күрербез.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

وَأَرَادُوا بِهِ كَيْدًا فَجَعَلْنَاهُمُ الْأَخْسَرِينَ ﴿٧٠﴾

**«Нәмруд кавеме Ибраһимга мәкерлек теләде, ягъни аны утка яндырып, һәлак итмәкче булдылар. Без аларны хәсрәт һәм зыян күрүчеләр иттек».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:70

Ягъни Ибраһимга зыян салырга теләүче Нәмруд патша үзенең кавеме белән зыян күрә.

Сәмуд кавеме таудан чыгарылган дөяне чалды һәм ашады. Салих ﷵ бу хәлгә бик кайгырып, кавемен кисәтте. Бу вакыйга турында Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

فَعَقَرُوهَا فَقَالَ تَمَتَّعُوا فِي دَارِكُمْ ثَلَاثَةَ أَيَّامٍ ۖ ذَٰلِكَ وَعْدٌ غَيْرُ مَكْذُوبٍ ﴿٦٥﴾

**«Ләкин Салихны тыңламадылар, дөяне үтерделәр, Салих: «Өч көн торып урыныгызда файдаланыгыз, соңра сезгә газап ирешер: бу вәгъдә ялган вәгъдә түгел», – дип әйтте».**

«Һуд», 11:65

Риваять ителә: ит ашаганнан соңгы көннең иртәсендә Сәмуд кавеменең йөзләре кызыл булды, икенче көнне йөзләре саргайды, өченче көнне йөзләре каралды – аларга газап иңде.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтте:

وَأَخَذَ الَّذِينَ ظَلَمُوا الصَّيْحَةُ فَأَصْبَحُوا فِي دِيَارِهِمْ جَاثِمِينَ ﴿٦٧﴾

**«Дөяне үтерүче залимнәрне бер каты тавыш тотты, шул тавыш белән барчалары урыннарында һәлак булдылар».**

«Һуд», 11:67

Мусаны ﷺ ялганга чыгарырга тиеш булган сихерчеләр җиңеләләр, сихерчеләр иман китерәләр, әмма халык Мусаны ﷺ якламый, иман китерми. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә бу халыкка җәза җибәрә.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтте:

فَأَرْسَلْنَا عَلَيْهِمُ الطُّوفَانَ وَالْجَرَادَ وَالْقُمَّلَ وَالضَّفَادِعَ وَالدَّمَ آيَاتٍ مُّفَصَّلَاتٍ فَاسْتَكْبَرُوا وَكَانُوا قَوْمًا مُّجْرِمِينَ ﴿١٣٣﴾

**«Аларга су басу, саранча, бет, бакалар һәм кан җибәрдек, боларны аерым-аерым ачык галәмәтләр итеп җибәрдек. Бу галәмәтләрне күргәннән соң да тәкәбберләнеп, азган кәфер кавеме булдылар».**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:133

Фиргавен халкы бу бәла-казаларга түзә алмыйча: «Бу бәла-каза бездән алынса, без инде иман китерер идек», – дип яңадан Муса янына киләләр. Муса дога кыла, алардан бәла-казалар алына, әмма алар сүзләрендә тормыйлар, Мусага дошманлык кылудан туктамыйлар. Аллаһы Тәгалә аларны суда батырып үтерә.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтте:

فَانتَقَمْنَا مِنْهُمْ فَأَغْرَقْنَاهُمْ فِي الْيَمِّ بِأَنَّهُمْ كَذَّبُوا بِآيَاتِنَا وَكَانُوا عَنْهَا غَافِلِينَ ﴿١٣٦﴾

**«Аларны суга батырып, алардан үчебезне алдык, аятьләребезне ялган диеп аннан гафил булганнары өчен».**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:136

Пәйгамбәребезнең могҗизаларына килгәндә, алар Кыямәт көненә кадәр мөселманнарның иманнарын куәтләр өчен, мөшрикләрне мөселманнардан аерыр өчен бер мисал булып барырга тиешләр. Ә инде иң зур могҗиза булган китап – Коръән Кәрим, бүгенгә кадәр бер хәрефе дә үзгәрмичә сакланган. Ислам дине бөтен дөньяга тарала, Коръәннән аерылган халыклар һәлакәткә дучар булалар. Мәсәлән, бүгенге Европадагы күп кенә цивилизацияләр әхлаксызлык упкынына батып, үзенең һәлакәтенә якынлаша.

Шулай ук могҗизалар кебек кайбер аңлатып булмый торган хәлләр булырга мөмкин. Андый хәлләр күп изгелек кылучы тәкъва мөэминнәргә ирешергә мөмкиннәр һәм алар карәмәтләр дип аталалар. Могҗизалар пәйгамбәрлекне исбатлау өчен килсәләр, карәмәтләр, могҗизалардан аермалы буларак, изгелекне исбатлау өчен түгел, бәлки изгелек сәбәпле булалар. Мәсәлән, Мәрьям анабызның гыйбадәтханәдә аерым бүлмәсе була. Кайчан гына аның янына керсәләр дә, анда төрле җимешләр күрәләр.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтте:

كُلَّمَا دَخَلَ عَلَيْهَا زَكَرِيَّا الْمِحْرَابَ وَجَدَ عِندَهَا رِزْقًا ۖ قَالَ يَا مَرْيَمُ أَنَّىٰ لَكِ
هَٰذَا ۖ قَالَتْ هُوَ مِنْ عِندِ اللَّهِ ۖ إِنَّ اللَّهَ يَرْزُقُ مَن يَشَاءُ بِغَيْرِ حِسَابٍ ﴿٣٧﴾

**«Зәкәрия Мәрьям янына кайчан гына керсә дә, алдында төрле җимешләр һәм башка ризыкларны күрер иде. Бер кергәнендә: «Ий, Мәрьям, бу ризыклар сиңа каян килә?» – дип сорады. Мәрьям: «Бу ризыклар Аллаһ хозурыннан килә, Аллаһ, әлбәттә, Үзе теләгән бәндәсен хисапсыз ризыкландыра», – дип әйтте».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:37

Пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ вафаты алдыннан һәм вафатыннан соң ялган пәйгамбәрләр барлыкка киләләр. Шуларның берсе Әл-Әсвад Әл-Әнси Йәмәндә үзен пәйгамбәр дип игълан итә. Ул үзенә Әбү Мөслим Әл-

Хәүләнине чакырта һәм аннан: «Син минем Аллаһның илчесе икәнлегемә шәһадәт бирәсеңме?» – дип сорый. Әбү Мөслим: «Мин ишетмим», – ди. Аннары Әл-Әсвәд: «Син Мөхәммәднең Аллаһның илчесе икәнлегенә шәһадәт бирәсеңме?» – дип сорый. Ул: «Әйе», – дип җавап бирә. Әл-Әсвәд бу сорауларны кат-кат бирә һәм бер үк җаваплар ишетә. Шуннан соң ул зур гына учак яктыра һәм Әбү Мөслимне шул утка ыргыттыра. Әмма ут Әбү Мөслимгә зыян салмый. Әл-Әсвадка: «Сиңа иярүчеләрне кире бормасын өчен аны үзеңнән ку», – дип әйтәләр һәм Әл-Әсвад аны куа. Әбү Мөслим Мәдинәгә китә һәм анда Пәйгамбәребезнең вафатыннан соң гына килеп җитә, дөясеннән төшеп мәчеткә намазга керә. Бераздан аны Гомәр ﵁ күреп ала. Ул аның Әбү Мөслим икәнен белгәч, аны кочаклап елый, аннары үзе белән алып китеп, Әбү Бәкер белән урталарына утырта һәм: «Әлхәмдүлилләһ, Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд өммәтендә Ибраһимга эшләгәнне эшләгән кешене күрергә насыйп итте», – дип әйтә. Ягъни икесе дә утка ыргытылып, анда янмыйлар. Әмма берсе могҗиза, икенчесе кәрамәт.

Без бүген могҗизалар һәм кәрамәтләр турында карап киттек. Алда әйтеп кителгәнчә, могҗиза фәкать пәйгамбәрләргә генә килә, ә кәрамәт исә бик изге кешеләргә генә килә. Соңгы пәйгамбәр килеп-китү сәбәпле инде бүтән могҗиза булмаячак. Ә кәрамәткә килгәндә исә, ул бөтен изге кешегә дә килми һәм изгелекне күрсәтә торган билге булып та тормый. Кәрамәте булмаган кеше изгелектә кәрамәте булган кешедән өстенрәк булырга мөмкин. Дин кәрамәт өмет итеп түгел, ә Аллаһ ризалыгы өчен булырга тиеш. Шуңа күрә гадәти булмаган хәл күргән саен аны могҗизага, кәрамәткә, ә аны күрсәткән кешене пәйгамбәргә яки изге кешегә санарга кирәк түгел. Беренче карашка могҗиза булып күренгән әйбернең сихер дә булуы мөмкин. Ахыр заманда Дәҗҗәл чыгачак, үзен Аллаһ дип танытачак һәм төрле гадәттән тыш нәрсәләр күрсәтәчәк. Әмма ул күрсәткән нәрсәләр могҗиза түгел, бәлки истидраҗ дип аталалар. Алар бик күп һәм

кешеләр өчен зур сынау булачаклар. Дәҗҗәл яңгыр яудырачак, үләләрне терелтәчәк, игеннәрне үстерәчәк, хайваннарны үз артыннан ияртәчәк һәм башка гадәти булмаган хәлләр эшләп, бик күп кешеләрне үзенә ияртәчәк, бик күп кешеләрнен диннән язуына сәбәп булачак. Шуңа күрә Дәҗҗал фетнәсеннән сакланырга кирәк. Пәйгамбәребез ﷺ әйткәнчә, Дәҗҗалдан йөгереп, яисә «Әл-Кәһф» сүрәсенең беренче 10 аятен укып, яисә гыйбадәт кылганнан соң дога кылып качарга кирәк.

*Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев,*
*Яр Чаллы шәһәре «Ак мәчет» мәдрәсәсе директоры*

*30 март вәгазе,*

*Раҗәб аеның 12 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Иң зур байлык – иман

Әгүүзү билләәһи мин әш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтуһ!

Иң зур байлык – иман, чөнки иманны кибеттән сатып алып та, бакчада үстереп тә булмый, аны заводта җитештермиләр, хөкүмәт тә өләшми, мирас булып та килми. Иман – ул Аллаһтан килгән бүләк. Кемнең иманы бар – ул җиде кат күкләрдән, җиде кат җирләрдән һәм алар арасында булган барча мәхлуклардән яхшырак. Кемнең иманы юк – ул хайваннан да түбәнрәк. Аллаһ иманны безгә әманәт итеп бирде. Без башка әйберләрне кадерләп саклаган кебек, машинаны яхшылап караган кебек, баланы тәрбияләгән кебек, иманга да шундый ук игътибар кирәк.

Һәр гамәлнең үз вакыты бар. Намазның, уразаның, зәкәтнең, хаҗның үз вакытлары бар. Ә иманның вакыты – 24 сәгать.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтте:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ حَقَّ تُقَاتِهِ وَلَا تَمُوتُنَّ إِلَّا وَأَنتُم مُّسْلِمُونَ ﴿١٠٢﴾

**«Ий, мөэминнәр, Аллаһтан каты куркыгыз, Аның хөкемнәрен бозудан бик нык сакланыгыз һәм Коръән белән гамәл кылып, чын мөселман хәлегездә генә үлегез!»**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:102

Беребез дә кайчан, кайда һәм ничек үләсен белми. Ләкин үлем – хак, үлем һәркайсыбызга киләчәк.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтте:

كُلُّ نَفْسٍ ذَائِقَةُ الْمَوْتِ ﴿٣٥﴾

**«Барча кеше үлем ачысын татучыдыр».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:35

Без фатир, машина, бала, эш өчен кайгырабыз, алар турында уйлыйбыз, тырышабыз, алар хакында сөйләшәбез. Иман өчен дә шулай тырышлык куярга кирәк. Спортчы көн саен спорт белән шөгыльләнә, эшмәкәр бизнес хакында, авыл хуҗалыгы белгече уңыш турында уйлый. Ягъни бөтен җирдә үсеш бар. Беренче телефон 5 килограмм авырлыкта иде, аннан кеше уйлап, фикерләп, хезмәт куеп эшләде – телефон кесәгә сыярлык кына булып калды. Телевизор нинди зур иде, аны берничә кеше күтәреп өйгә алып керәләр иде, ә хәзер аны стенага рәсем итеп элеп куябыз. Иманның да үсеше булырга тиеш.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтте:

أَوْ كَالَّذِي مَرَّ عَلَىٰ قَرْيَةٍ وَهِيَ خَاوِيَةٌ عَلَىٰ عُرُوشِهَا قَالَ أَنَّىٰ يُحْيِي هَٰذِهِ
اللَّهُ بَعْدَ مَوْتِهَا ۖ فَأَمَاتَهُ اللَّهُ مِائَةَ عَامٍ ثُمَّ بَعَثَهُ ۖ قَالَ كَمْ لَبِثْتَ ۖ قَالَ لَبِثْتُ
يَوْمًا أَوْ بَعْضَ يَوْمٍ ۖ قَالَ بَل لَّبِثْتَ مِائَةَ عَامٍ فَانظُرْ إِلَىٰ طَعَامِكَ وَشَرَابِكَ لَمْ
يَتَسَنَّهْ ۖ وَانظُرْ إِلَىٰ حِمَارِكَ وَلِنَجْعَلَكَ آيَةً لِّلنَّاسِ ۖ وَانظُرْ إِلَى الْعِظَامِ كَيْفَ
نُنشِزُهَا ثُمَّ نَكْسُوهَا لَحْمًا ۚ فَلَمَّا تَبَيَّنَ لَهُ قَالَ أَعْلَمُ أَنَّ اللَّهَ عَلَىٰ كُلِّ شَيْءٍ
قَدِيرٌ ﴿٢٥٩﴾ وَإِذْ قَالَ إِبْرَاهِيمُ رَبِّ أَرِنِي كَيْفَ تُحْيِي الْمَوْتَىٰ ۖ قَالَ أَوَلَمْ
تُؤْمِن ۖ قَالَ بَلَىٰ وَلَٰكِن لِّيَطْمَئِنَّ قَلْبِي ۖ قَالَ فَخُذْ أَرْبَعَةً مِّنَ الطَّيْرِ فَصُرْهُنَّ

إِلَيْكَ ثُمَّ اجْعَلْ عَلَىٰ كُلِّ جَبَلٍ مِّنْهُنَّ جُزْءًا ثُمَّ ادْعُهُنَّ يَأْتِينَكَ سَعْيًا ۚ وَاعْلَمْ أَنَّ اللَّهَ عَزِيزٌ حَكِيمٌ ﴿٢٦٠﴾

**«Янә кешеләре үлгән, йортлары җимерелгән шәһәр яныннан үтеп баручы Гозәер хәле белән танышыгыз! Ул: «Кешеләр шәһәр белән бергә һәлак булганнар инде, боларны Аллаһ ничек тергезсен?» – дип әйтте. Гозәер, шәһәрдән үтеп, ерак киткәч, Аллаһ аны үтерде, йөз ел үткәч тергезде. Һәм: «Ий, Гозәер, үлеп күпме яттың?» – диде. Гозәер: «Үлеп бер көн яки бер көннән азрак яттым», – дип җавап бирде. Аллаһ: «Ий Гозәер, бер көн түгел, ә йөз ел яттың, ашый торган ризыгыңа һәм эчә торган эчемлегеңә кара – бозылмаганнар һәм ишәгеңә кара», – дип әйтте. Гозәернең үзе белән алган ризыгы һәм эчемлеге, йөз ел буена ятып, бозылмаган, әмма ишәкнең кояшта агарган сөякләре генә калган иде. Аллаһ Гозәергә: «Сөякләрне җыеп, аларга ит кундырып һәм тире үстереп ишәкне тергезгәнебезне карап тор», – диде. Ий Гозәер! Бу эшне сиңа үлгәннән соң терелүгә ышану өчен, кешеләргә дәлил булсын өчен кылдык. Ишәкнең терелгәнен күргәч, Гозәер: «Мин хәзер Аллаһның һәрнәрсәгә көче җиткәнен беләмен», – диде.**

**«Янә Ибраһимның: «Ий Раббым, миңа үлекне тергезеп күрсәт», – дигәнен игътибарга алыгыз! Аллаһ әйтте: «Ий Ибраһим! Минем үлекләрне тергезергә көчем җиткәнлегенә ышанмыйсыңмы әллә?» Ибраһим: «Ий, Раббым, әлбәттә, мин ышанам, ләкин мине якын күргәнлегең белән күңелемнең карарлануын телим», – дип әйтте. Аллаһ: «Ий, Ибраһим, дүрт кошны ал, аларны үтереп алдыңа сал, аннары аларның берәр кисәкләрен тау өстенә ташла. Моннан соң аларны чакыр, әлбәттә, синең яныңа**

**алар йөгереп килерләр», – диде. Яхшы бел – дөреслектә, Аллаһы Тәгалә бөтен эштә җиңүче һәм хикмәт белән эш кылучы».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:259-260

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтте:

فَتَقَبَّلَهَا رَبُّهَا بِقَبُولٍ حَسَنٍ وَأَنبَتَهَا نَبَاتًا حَسَنًا وَكَفَّلَهَا زَكَرِيَّا ۖ كُلَّمَا دَخَلَ
عَلَيْهَا زَكَرِيَّا الْمِحْرَابَ وَجَدَ عِندَهَا رِزْقًا ۖ قَالَ يَا مَرْيَمُ أَنَّىٰ لَكِ هَٰذَا ۖ قَالَتْ
هُوَ مِنْ عِندِ اللَّهِ ۖ إِنَّ اللَّهَ يَرْزُقُ مَن يَشَاءُ بِغَيْرِ حِسَابٍ ﴿٣٧﴾ هُنَالِكَ دَعَا
زَكَرِيَّا رَبَّهُ ۖ قَالَ رَبِّ هَبْ لِي مِن لَّدُنكَ ذُرِّيَّةً طَيِّبَةً ۖ إِنَّكَ سَمِيعُ الدُّعَاءِ
﴿٣٨﴾ فَنَادَتْهُ الْمَلَائِكَةُ وَهُوَ قَائِمٌ يُصَلِّي فِي الْمِحْرَابِ أَنَّ اللَّهَ يُبَشِّرُكَ
بِيَحْيَىٰ مُصَدِّقًا بِكَلِمَةٍ مِّنَ اللَّهِ وَسَيِّدًا وَحَصُورًا وَنَبِيًّا مِّنَ الصَّالِحِينَ ﴿٣٩﴾
قَالَ رَبِّ أَنَّىٰ يَكُونُ لِي غُلَامٌ وَقَدْ بَلَغَنِيَ الْكِبَرُ وَامْرَأَتِي عَاقِرٌ ۖ قَالَ كَذَٰلِكَ
اللَّهُ يَفْعَلُ مَا يَشَاءُ ﴿٤٠﴾ قَالَ رَبِّ اجْعَل لِّي آيَةً ۖ قَالَ آيَتُكَ أَلَّا تُكَلِّمَ
النَّاسَ ثَلَاثَةَ أَيَّامٍ إِلَّا رَمْزًا ۗ وَاذْكُر رَّبَّكَ كَثِيرًا وَسَبِّحْ بِالْعَشِيِّ وَالْإِبْكَارِ ﴿٤١﴾

**«Мәрьямне Раббысы мәсҗид Әкъсага күркәм кабул итү белән кабул итте һәм яхшы тәрбия белән тәрбияләде һәм тәрбияләп үстерү өчен Зәкәрия пәйгамбәргә тапшырды. Зәкәрия Мәрьям янына кайчан гына керсә дә, алдында төрле җимешләр һәм башка ризыкларны күрер иде. Бер кергәнендә: «Ий, Мәрьям, бу ризыклар сиңа кайдан килә?» – дип сорады. Мәрьям: «Бу ризыклар Аллаһ хозурыннан килә, Аллаһ, әлбәттә, Үзе теләгән бәндәсен хисапсыз ризыкландыра», – дип җавап бирде.**

**«Мәрьямнең дәрәҗәсен Аллаһ күтәргәнне күреп, Раббысына ялварып дога кылды. «Ий, Раббым, рәхмәтеңнән миңа бер бала бир! Шиксез, син минем догамны ишетәсең», – дип сорады.**

**«Зәкәрия михрабта намаз укып торганда, Җәбраил килеп: «Ий, Зәкәрия, дөреслектә, Аллаһ сине Яхъя исемле изге угыл белән шатландыра», – диде. Ул Яхъя Аллаһтан булган сүзгә ышанучы булган хәлдә, ягъни Гайсә пәйгамбәргә иң беренче иман китереп, ярдәмче булды. Янә ул Яхъя кавеме арасында хөрмәтле вә олуг булды, һәм дә хатыннар белән сөхбәт итүдән сакланучы изге пәйгамбәрләрдән булды.**

**«Зәкәрия: «Ий, Раббым, миңа кайдан угыл булсын? Дөреслектә, миңа картлык иреште, хатыным да бала тудырмаучыдыр», – диде. Аллаһ: «Әнә шулай Аллаһы Тәгалә теләгәнен кылыр», – диде.**

**«Зәкәрия: «Ий, Раббым, хатынымның йөкле булуына миңа бер галәмәт бир!» – диде. Аллаһ: «Синең кешеләр белән сөйләшә алмавың сиңа галәмәт булыр, кешеләр белән өч көн сөйләшә алмассың, мәгәр ишарат илә генә сөйләшерсең», – диде Аллаһ: «Ий, Зәкәрия, Раббыңны күп зикер ит вә көндезләрен һәм кичләрен намаз укы!» – диде».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:37-41

Өч төрле иман бар:

1. Фәрештәләрнеке – аларның иманнары бер дәрәҗәдә: күтәрелми дә, төшми дә. Ягъни аларның 2 сыйфаты бар: ишеттек һәм буйсындык.

2.Пәйгамбәрләрнеке – аларның иманнары гел үсеп торган, ничек икәнлеген без югарыдагы аятьләрдән күрәбез.

3.Кешеләрнеке – аларның иманнары күтәрелә яки төшә. Фәрештәләр нурдан яралтылганнар. Аларның нәфесләре юк, шуның өчен алар Аллаһ кушканнарын җиренә җитеп үтеп баралар. Пәйгамбәрләр гел иман

өстендә тырышлык куйганнар. Ибраһимның Аллаһтан кешеләрне ничек тергезүен сораганын алдарак әйтеп киттек. Ягъни, күңел тынычлансын, ныграк инансын өчен шулай эшләгән ул.

Бер нәрсә дә үзеннән-үзе булмый, шулай ук иман да үзеннән-үзе артмый. Кешеләрнең иманнары кутәрелә яки үсә. Аларның иманнары гамәлләренә карап була. Кайберәүләрнең иманы мәчеткә килеп, сәдака салып, дога кылдырырга җитә. Икенчеләре – мәчеткә елына ике гает намазына киләләр. Өченчеләре – атнага бер җомга намазына баралар. Дүртенчеләре – 5 вакыт намаз укый, алтынчылары 5 вакыт намазлардан тыш, нәфел намазлары укый, уразалар тота, сәдака бирә һәм башка төрле гыйбадәтләр дә кылалар.

Шулай ук иманны болай бәяләп була. Әгәр кешегә авырлык килсә, ул нәрсәгә ышана башлый, кемгә таяна башлый?

إِنَّ الَّذِينَ قَالُوا رَبُّنَا اللَّهُ ثُمَّ اسْتَقَامُوا تَتَنَزَّلُ عَلَيْهِمُ الْمَلَائِكَةُ أَلَّا تَخَافُوا وَلَا تَحْزَنُوا وَأَبْشِرُوا بِالْجَنَّةِ الَّتِي كُنتُمْ تُوعَدُونَ ﴿٣٠﴾

**«Дөреслектә, иман китергән кешеләр: «Безнең тәрбиячебез – Аллаһ», – диярләр, соңрак иманда, диндә һәм тормышта туры, гадел булдылар, үлгән вакытларында аларга рәхмәт фәрештәләре иңәрләр: «Сез хак мөэминнәрсез, үлемнән вә Ахирәттән курыкмагыз, һәм дөньяда калган якыннарыгыз өчен дә көенмәгез, бәлки үзегезгә вәгъдә ителгән җәннәт белән шатланыгыз», – диярләр».**

«Фүссиләт / Аңлатылды», 41:30

Ягъни төрле хәлдә һәм бөтен җирдә без иң элек Аллаһка таянырга һәм Аннан ярдәм эстәргә тиешлебез.

Без иман өчен тырышсак, бу дөньяда да, Ахирәттә дә тулы бәхеткә, тулы уңышка һәм тулы дәрәҗәгә ирешәчәкбез.

Пәйгамбәр Мөхәммәд Мостафа ﷺ сәхабәләрнең иманын 13 ел буе тырышып үстергән. Сәхабәләр һиҗрәт кылгач, Аллаһ шушы аятьне иңдерә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا آمِنُوا بِاللَّهِ وَرَسُولِهِ وَالْكِتَابِ الَّذِي نَزَّلَ عَلَىٰ رَسُولِهِ وَالْكِتَابِ الَّذِي أَنزَلَ مِن قَبْلُ ۚ وَمَن يَكْفُرْ بِاللَّهِ وَمَلَائِكَتِهِ وَكُتُبِهِ وَرُسُلِهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِ فَقَدْ ضَلَّ ضَلَالًا بَعِيدًا ﴿١٣٦﴾

**«Ий иман китерүчеләр! Аллаһка, Расүленә, Расүленә иңдергән Коръәнгә һәм әүвәл иңдерелгән китапларга хак ышану илә ышаныгыз! Аллаһка хак ышану – Аңа итагать итү, гыйбадәт кылу илә, Расүлгә хак ышану – аңа иярү илә. Коръәнгә хак ышану – аның илә гамәл кылу белән һәм Ахирәткә хак ышану – Ахирәткә әзерләнү илә булыр. Берәү Аллаһка, аның фәрештәләренә, китапларына, расүлләренә һәм Ахирәт көненә ышануны инкяр итсә, яки хак ышану илә ышанмаса, ул кеше бик ерак адашу илә адашты».**

«Нисә / Хатыннар», 4:136

Сәхабәләр: «Без иң элек иманга өйрәндек, аннары Коръәнгә», – дип әйтәләр иде. Алар үзара очрашканда: «Синең иманың, синең намазың нинди хәлдә?» – дип сорашканнар. «Әйдә әле, иманны яңартыйк», – дип сөйләшү алып барганнар. Пәйгамбәр Мөхәммәд Мостафа ﷺ: «Үзегезнең иманнарыгызны яңартып торыгыз!» – дип әйткән. Сәхабәләр: «Йә, Расүлүллаһ, иманнарыбызны ничек яңартып була?» – дип сораганнар. Расүлүллаһ ﷺ: «Ләә иләәһә илләллааһ» сүзләрен еш әйтегез», – дип җавап кайтарган.

Безгә иманны үстерү өчен ни рәвешле тырышлык куярга кирәк соң? Аның 3 юлы бар.

Беренчесе – иман хакында күп сөйләргә кирәк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа ﷺ сәхабәләрне әзерләгән һәм алар һәммәсе дә дәгъвәт кылучы иделәр.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтте:

وَمَنْ أَحْسَنُ قَوْلًا مِّمَّن دَعَا إِلَى اللَّهِ وَعَمِلَ صَالِحًا وَقَالَ إِنَّنِي مِنَ الْمُسْلِمِينَ ﴿٣٣﴾

**«Ислам динендә, Коръән юлында файдалы эшләрне, изге гамәлләрне кылган хәлдә, Аллаһка иман китерергә һәм Ислам динен кабул итәргә кешеләрне чакыручы мөселманның сүзеннән дә күркәмрәк, файдалырак сүз булырмы, һәм ул һәркайда: «Мин мөселман, бу эшләрне эшләргә мин бурычлымын»,– дип әйтәдер. Ягъни: «Бу эш һәр мөселманның бурычыдыр», – дип әйтә».**

«Фүссиләт / Аңлатылды», 41:33

Ягъни иң күркәм сүз – ул Аллаһка чакыру, Аның бөеклеге хакында сөйләү. Моңа бер мисал китерергә була. Бер укытучы дәрес бирә. Соңыннан укучылардан: «Аңладыгызмы?» – дип сорый. Тегеләр: «Юк», – дип җавап кайтара. Икенче, өченче тапкырында сорагач та, укучылар: «Юк, аңламадык», – дип җавап кайтарды. Укытучы: «Сезгә сөйли-сөйли, үзем дә аңладым», – дип әйткән.

Безгә аңлау килсен өчен, безгә күп сөйләргә кирәк. Тел белән йөрәк арасы җир белән күк арасы кебек. Ягъни телдән йөрәккә үтеп керсен өчен, күпме тырышлык куярга кирәк. Сәхабәләр: «Әгәр җәннәт һәм җәһәннәмне күрсәк, безнең иманнарыбыз күтәрелмәс иде», – дип әйткәннәр. Алар бик нык инану белән инанган иделәр. Йөрәкләрендә бернинди дә шикләнү һәм икеләнү юк иде.

Икенчесе – йөрәккә карарга кирәк. Ягъни кая карый ул: Аллаһ ягынамы, мәхлуклар тарафынамы? Бервакыт Ханзалә исемле сәхабә урамга чыгып: «Мин монафыйк (икейөзле)», – дип кычкыра башлаган. Әбү Бәкер аңа: «Син ни өчен шулай дип әйтәсең?» – дип сораган. Ханзалә: «Мин Пәйгамбәр ﷺ янында булганда, минем алдымда Ахирәт, ә өйгә кайткач, дөнья баса. Димәк, мин икейөзле», – дигән. Әбү Бәкер: «Мин дә шулай ук», – дип җавап кайтарды. Алар икесе дә Пәйгамбәр янына баралар һәм аңа үзләренең гозерләрен аңлаталар. Пәйгамбәр Мөхәммәд Мостафа ﷺ аларга: «Әгәр сезнең халәтегез гел минем янымда булган шикелле булса, фәрештәләр, йоклаган җирегезгә килеп, сезгә сәлам бирерләр иде», – дип әйткән.

Өченчесе – Аллаһтан иманыбызны ныгытуын сорау. Пәйгамбәр Мөхәммәд Мостафа ﷺ: «Кемнең ахыргы сүзе «Ләә иләәһә илләллаһ» булса, ул җәннәткә керер», – дип әйткән. Бер хәзрәтнең тутый кошы булган һәм ул аңа «Ләә иләәһә илләллаһ» сүзләрен өйрәткән. Тутый кош гел шушы сүзләрне әйтеп торган. Бервакыт мәче кошка һөҗүм ясап, аны үтерә. Тутый кош үлгәндә: «Кыыһ», – дип аваз чыгарып үлә. Хәзрәт елый башлаган. Кешеләр килеп юатканнар: «Хәзрәт, борчылма, без сиңа шундый ук ике тутый кош алырбыз», – дигәннәр. Ләкин хәзрәт аларга: «Мин кош өчен борчылмыйм, үзем өчен кайгырам, үлгәндә ахыргы сүзем нинди булыр?» – дип җавап биргән.

Шуның өчен Аллаһтан гел сорап торырга кирәк.

Аллаһы Тәгалә барыбызга да тулы иман бирсен, иманлы хәлдә булып, Ахирәт сәфәренә кучкәндә, «Ләә иләәһә илләллааһ»ны әйтергә насыйп итсен. Вәссәләмү галәйкум вә рахмәтүллааһи вә бәракәтүһ.

*Ибраһим хәзрәт Шаһимәрдәнов,*

*«Ярдәм» мәчете имам-хатыйбы*

*6 апрель вәгазе,*

*Раҗәб аеның 19 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Онытылып, тыныч яшәмә!

Барча галәмнәрне бар кылып, аларны тәрбия кылып торучы, барлык нигъмәтләр белән безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итеп кылучы Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләгә хәмед вә сәнәләребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәдкә ﷺ күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек бирсә иде!

Инсаният барлыкка килгәннән бирле, Аллаһы Тәгалә Җир йөзенә 124 мең тирәсе пәйгамбәр җибәргән. Аларның һәрберсе дә кешеләргә бер Аллаһка гыйбадәт кылырга кирәклеген, үлем, бәрзах, җәннәт-җәһәннәм барлыгын исләренә төшереп торганнар. Сәхабәләр заманында, сәхабәләр бер-берләренә исләренә төшерергә курыкмаганнар. Киресенчә, берәр галим янына барсалар, үзләренә берәр вәгазь сөйләвен үтенгәннәр.

Бүгенге көндә дә исләребезгә төшереп торучылар юк түгел. Аллаһка шөкер, һәр шәһәрдә, авылда мәчет-мәдрәсәләребез эшләп килә. Җомга саен халык җыеп, вәгазь сөйләү мөмкинчелекләребез бар. Караңгы төндә ястүгә дә, кеше йокысыннан торганчы, иртәнге намазга да азан әйтү мөмкинчелекләре бар. Ягъни, Аллаһ турында, дөрес яшәү турын-

да, җәһәннәм-җәннәт турында, әлхәмдүлилләһ, һәрвакыт исләребезгә төшереп торалар.

Зиратларыбызга килгәндә, һәрбер кешене мөселманча, җеназасын үткәреп: «Бу кеше ихлас мөселман иде», – дип әйтеп күмәбез. Ләкин күмгәннән соң, ул кеше белән ни булганын белә алмыйбыз. Әлбәттә, Мүнкәр һәм Нәкир төшеп, аннан сорау алачак, җавап кайтара алуыннан, йә рәхәттә, йә газапта торачак, дип әйтә алабыз. Шулай да, конкрет кеше өчен без берни дә әйтә алмыйбыз: котылыдымы ул кеше, юкмы!

Минем сезгә бер сорау бирәсем килә: Аллаһы Тәгалә турында тәүлекнең күпме вакытында уйлыйсыз? Көне буе, торгач һәм ятканда, авырлык, йә шатлык килгәндә, 5 вакыт намаз вакытында?

Ничек кенә булмасын, бүгенге яшәү ритмы белән, бүгенге эшнең күплеге белән зикергә, Аллаһ, җәннәт, җәһәннәм турында уйланып утырырга бик аз вакыт бирелә. Нәфес булсынмы, шайтан булсынмы, икесе дә дөнья белән кызыктырып, Ахирәтне онытырырга тырышалар.

Һәм бу фетнәгә дөньядагы һәрбер кеше – мөселманмы ул, мөселман түгелме, дучар була. «Рухүл-бәйән» тәфсирендә Әбү Исхак Әл-Фәрази сүзләреннән менә мондый риваять китерелә:

«Безнең янга гел бер кеше килеп йөри иде. Ул һәрвакыт йөзенең ярты өлешен каплап йөри иде. Бервакыт мин аннан: «Син безгә бик еш киләсең һәм йөзеңнең бер өлеше һәрвакыт ябык. Моның сәбәбе нидә икәнен әйтә аласыңмы?» – дип сорадым. Ул кеше дә: «Син минем серемне монда булганнарның берсенә дә сөйләмим, дип вәгъдә бирә аласыңмы?» – дип сорады. Мин: «Әйе», – дип әйткәч, ул миңа түбәндәге хәлне сөйләп бирде:

«Мин күпмедер вакыт каберләрдән кәфенлекләр урлап йөрдем. Менә бервакыт бер хатын-кызны күмделәр. Мин соңрак барып, аның каберен казый башладым. Таш плитәгә җитеп туктагач, аны бераз кырыйга этеп, кабернең эчен ачтым. Бер кулым белән бу хатын-кызның кәфенлеген

үземә тарта башладым. Шулвакыт бу хатын да кәфенлекне үзенә тарта башлады. Мин аңа: «Әллә син мине җиңәрмен, дип уйлыйсыңмы?» – дип әйтеп, тезләнеп бастым да, кәфенлекне катырак тарта башладым. Шулвакыт бу хатын кулын күтәреп, минем яңагыма сукты». Бу сүзләрне әйтеп бетерүгә, ул йөзенең ябык өлешен ачып күрсәтте. Анда, чыннан да, биш бармак эзе төшеп калган иде.

Аннан соң ни булганын сорадым. Ул кеше: «Мин кәфенлекне кире аттым да, тизрәк каберне кире күмдем. Шуннан соң беркайчан да каберлекләрне казып, алардан кәфенлекләрне урламаска дип, үз-үземә вәгъдә бирдем», – дип җавап кайтарды».

Әбү Исхак Әл-Фәрази сүзләрен дәвам итеп, болай ди:

«Бу кешедән ишеткәннәремнең барысын да Әүзәгигә хат итеп язып җибәрдем. (Габдеррахман Әл-Әүзәги – Шәм җирлегендә яшәгән бик олуг галимнәрнең берсе. Зур факиһ, төннәрен елый-елый Коръән һәм намаз укып чыгучы зур галим була). Җавап хатында: «Кайгы булсын үзеңә. Ник син иң мөһим әйбер турында сорамадың: мөселман булып күмелгән ничә кешенең башлары кыйбла тарафына борылган килеш ята?» – дип язылган иде.

Мин бу кешедән: «Кәфенлекләрен урларга дип казыган каберләрдә мөселманнарның хәлләре ничек? Араларыннан ничәсе һаман да кыйбла тарафына карап яталар?» – дип сорадым. Ул исә: «Дөреслектә, аларның бик күбесе башларын кыйблага каршы якка борылган килеш яталар иде», – дип җавап кайтарды.

Мин бу кешенең сүзләрен Әүзәгигә ирештердем. Ул исә җавап хатында болай дип язган иде: «Иннә лилләәһи вә иннә иләйһи рааҗигун. Иннә лилләәһи вә иннә иләйһи рааҗигун. Иннә лилләәһи вә иннә иләйһи рааҗигун. Башлары кыйблага каршы борылган кешеләр мөселман булмыйча үлгәннәр!»

Аллаһы Тәгалә һәрберебезне дә бу дөньядан иманлы булып китүебезне насыйп әйләсен!

Без үзебезне һәрвакыт тынычландырып торырга яратабыз. Тормышта да берәр нәрсә килеп чыкса: «Бар да яхшы булыр әле, бар да үтә», – дип әйтергә яратабыз. Шул ук хәлне дингә дә кертеп барабыз. «Без бит мөселман, калганнар кебек фәхеш гамәлләр кылып йөрмибез». «Мин әле намаз булса да укыйм, ә ул тәһарәт тә ала белми», – дип үз-үзебезне юаткан шикелле булабыз. Менә шул вакытта кеше үзен куркынычсызлык астында, дип уйлый башлый. Безнең күбебез үзен җәннәттә дип күз алдына китергәне бардыр. Әмма җәһәннәмдә дип күз алдына китереп караганыбыз бармы? Бар?! Иртән торгач, кичкә кадәр яшәмәм, дип уйлаган бармы? Йә ятканда, иртән уянмам, дип уйлаган бармы? Кыямәт көнендә гамәлләрем өчен җавап биргәнебезне күз алдына китереп караганыбыз бармы? Гамәл дәфтәребезне уң кулыбызга бирерләрме икән, дип уйлаганыбыз бармы? Монафикълар белән бергә җәһәннәмгә тотып алмаслар микән, дип уйлаган бармы? Бар?! Соң ник алайса без шулкадәр тыныч соң? Нигә безнең күзләребездән яшьләр таммый соң? Ни өчен без югары әхлак турында онытып барабыз соң? Мәчеткә килеп кергәч, кем таныш, шуның белән генә күрешәбез. Бервакыт бер кеше Пәйгамбәребездән ﷺ: «Ислам динендә иң хәерле гамәлләр нәрсә?» – дип сорады. Пәйгамбәребез аңа: «Иң хәерлесе – мохтаҗларны ашатуың, таныш булган һәм таныш булмаганнарга сәлам бирүең», – дип җавап кайтара[1]. Ә без һаман да кетәклектәге тавыклар кебек, баш күтәрмичә, җим чүпләп кенә йөрибез кебек.

Беренче очракта үземә вә аннан соң сезгә бер сорау бирәсем килә:

Ә без нинди гамәлләребез өчен гамәл дәфтәрләребезне уң кулыбыз белән алырга телибез соң? Нинди гамәлләребез өчен? Өметләребез өченме? Онытылмыйк!

[1] Имам Бохари, 12; имам Мөслим, 39; Әбү Давыд, 5194, Ибн Мәҗәһ, 3253.

وَأَمَّا مَنْ أُوتِيَ كِتَابَهُ بِشِمَالِهِ فَيَقُولُ يَا لَيْتَنِي لَمْ أُوتَ كِتَابِيَهْ ﴿٢٥﴾ وَلَمْ
أَدْرِ مَا حِسَابِيَهْ ﴿٢٦﴾

**«Әмма гамәл дәфтәре сул кулына бирелгән кеше: «Ий, миңа, гомумән, гамәл дәфтәрем бирелмәгән булсачы! Хисабымны нинди икәнен белмәгән булсамчы!» – дип әйтер.**

«Хаккат», 69: 25-26

Кыямәт көнендә Ахирәтне онытып, дөньяга бирелгән кешеләр болай дип әйтер:

مَا أَغْنَىٰ عَنِّي مَالِيَهْ ۜ ﴿٢٨﴾ هَلَكَ عَنِّي سُلْطَانِيَهْ ﴿٢٩﴾

**«Хәзер инде миңа малым һич файда бирмәде. Инде минем бәйсезлегем вә көчем һәлак булды!»**

Аллаһы Тәгалә газап фәрештәләренә:

خُذُوهُ فَغُلُّوهُ ﴿٣٠﴾ ثُمَّ الْجَحِيمَ صَلُّوهُ ﴿٣١﴾

**««Алыгыз ул кешене, богаулагыз аны! Соңрак җәһәннәм утында яндырыгыз аны!»** – дип әйтер.

«Хаккат», 69: 28-31

Тормыш кайда да кайный. Тавык абзарына – кетәклеккә барып карагыз әле. Акыллары булмаган тавык «дөньясында» да тормыш кайный. Әгәр җим сипсәң, йөгерешеп килеп, бер-берсен этешеп, шул җимне чүпли башлыйлар. Әле бер-берсен чукып та алалар. Менә без дә шулар төсле. Безнең дә ризык Җир буенча чәчелгән һәм ул әзер. Ләкин шуны белсәк тә, шушы тавыклар кебек, башыбызны күтәрмичә, шул ризыкны «чүпләп» йөрибез. Башны күтәреп, ял итәргә онытабыз. Ничек тә күбрәк, зуррак кисәк эләктерергә тырышабыз. Кунакчага югарырак кунаклап, астагыларны нәҗесләргә омтылабыз. Без ризыкның да, әҗәл вакытының

да алдан билгеләнеп куелганнарын онытып җибәрәбез бугай. Әбү Дәрда болай дип әйкән: «Әй, кеше, син бары тик көннәр. Бер көн үтү белән, синең дә бер өлешең кими!» Чыннан да, без күпме генә тырышсак та, алдан билгеләнгән ризыгыбызны киметеп кенә, көннәр үткән саен, алда булачак көннәребезне азайтып кына барабыз. Арттырмыйбыз. Без авылдан шәһәргә баручы кеше кебек кенә. Юлның озынлыгы билгеле. Һәм авылдан ерагайган саен, шәһәргә юл озынаймый, киресенчә, ул юл һаман да кыскара. Дөреслектә, бодай чәчеп, беребез дә солы җыеп ала алмыйбыз. Ягъни, гөнаһлар кылгач, әҗер-савап язылмый. Бу дөнья – ахирәтнең басуыдыр. Хәзер ни чәчсәк, Ахирәттә шуны җыеп алачакбыз да. Шуны онытмасак иде.

Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә дә камил акыл, ныклы иман, Үзен зикер кылучы дуслар бирсә иде. Алган гыйлемнәребез онытылмасын, шул гыйлем белән гамәл-гыйбадәттә булсак иде. Әмин!

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*

*Арча районы Хәсәншәех авылы мәчете имам-хатыйбы*

# Редакция хаты

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәракәтүһ!

Хөрмәтле имамнар, укучыларыбыз! Журналыбыз редакциясе сезне хезмәттәшлек итәргә чакыра.

Пәйгамбәребез хәдисләрендә мөселманнарга булган гыйлемнәре белән уртаклашуның зарурлыгын әйтеп калдыра. Шулай ук имам Әхмәд: «Белем байлыкка охшаган: байлык күбрәк булган саен, аннан күбрәк зәкәт түләнә», – дип әйткән. Имам Гали әйткән: «Белүче үз гыйлемнәре белән бүлешә барган саен, аңа яңа гыйлем чыганаклары ачыла бара, алар үсә, ныгый һәм аныклана. Башкаларны укытканда ул элек алган белемен ныгыта һәм яңасын ала».

«Шура» журналында вәгазьләрегез, мәкаләләрегез, әдәби әсәрләрегезне урнаштырырга теләсәгез, «Сорау-җавап» рубрикасында кызыксындырган сорауларыгызга җавап аласыгыз килсә, «Әңгәмә» сәхифәсе өчен интервью бирергә, редакция хезмәткәрләренә киңәшләрегезне җиткерергә теләгегез булса, **shura@huzur.ru** электрон почтасына яки 420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы 6/27 («Шура» журналына» дип) адресына хатлар юллый, **+7 (843) 598-09-42** номерына шалтырата аласыз.

Редакциягә килгән язмалар үзгәртелә ала, бастырылмаска мөмкин һәм кире кайтарылмый.

# Сорау –
# җавап

**1. Сорау: Дини мәҗлесләрдә, ашларда катнашкан өчен кеше әҗер-савап алачакмы?**

**Җавап:** Бу дөньядагы яшәешебезнең мәгънәсе булып Аллаһы Тәгаләнең сөекле колларыннан булырга омтылу торырга тиеш. Ә алар саныннан булыр өчен, без динебез нәрсә тыйганын, нәрсә рөхсәт иткәнен яхшы белергә тиешбез. Һәм моңа ирешер өчен без кулыбыздан килгәннең барын да эшләргә тиешбез. Мәҗлесләрдә катнашу нәкъ шушы зарури гамәлләр рәтенә карый да. Дини тормышыбызга бәйле мәсьәләләр аңлатылган әңгәмәләрнең файдасы бәхәссез.
Ә Аллаһка яхшырак мәгълүм.

*ТР мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин*

**2. Сорау: Бер агачны икенчесе белән кисештерү (бер төр агачның ботагын икенче төр агачка ялгау) рөхсәт ителәме?**

**Җавап:** Агачларны кисештерүдә гаеп итәрлек берни юк. Әмма бер төр агачны икенчесе белән кисештерү нәтиҗәсендә аның үзенең җимешләреннән тыш башка төр җимешләр бирә башлау мәсьәләсе чагыштырмача күптән түгел туды. Шул сәбәпле, безнең фикеребезчә, әгәр бу кеше сәламәтлегенә зыян китерми икән, рөхсәт ителгән дип санала ала.
Ә Аллаһка яхшырак мәгълүм.

*ТР мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин*

**3. Сорау: Чәчне күчереп утырту рөхсәт ителәме? Юк икән, нинди ысул киңәш итә аласыз?**

**Җавап:** Сүз хәтта үз чәчләреңне күчереп утырту турында барса да, бу тыелган. Башка төрле фикерләр булса да, бүгенге көндә бу күпчелек факиһләрнең карашы. Моңа кешенең тумыштан булган үзенчәлеге итеп карасак, аның тыелган булуына инанабыз.

«Нәрсә киңәш итә аласыз?» – дип сорыйсыз. Беренчедән, чәчләр коелуы кеше өчен ниндидер психологик проблемалар сәбәбенә әверелергә тиеш түгел. Дөньяда чәч коелудан интеккән, пеләш кешеләр чәчләре яхшы булган кешеләргә караганда күбрәк. Кеше башын каплап йөрергә тели икән, аңа түбәтәй киеп йөрергә киңәш итәргә мөмкин. Без башка ысуллар тәкъдим итә алмыйбыз.

Ә Аллаһка яхшырак мәгълүм.

*ТР мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин*

## 4. Сорау: «Әт-тәхият» һәм башка догаларны тәҗвид белән укырга кирәкме?

**Җавап:** Һәр мөселман дин нигезләрен белергә һәм намаз укыр өчен кирәкле дәрәҗәдә дөрес итеп Коръән укый белергә тиеш. Бу мәсьәләләрдә игътибарсыз булырга ярамый. Шул сәбәпле, һәр кеше остаздан тәҗвидкә өйрәнергә тиеш. Ахыйрәттә оятка калганчы, яшькә карамыйча, бу тормышта тырышлык куярга һәм укырга өйрәнергә хәерлерәк. Тәҗвидне өйрәнгәндә без гарәп авазларын дөрес әйтергә өйрәнәбез. Шул рәвешле дөрес итеп Коръән һәм догалар укый алачакбыз.

Ә Аллаһка яхшырак мәгълүм.

*ТР мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин*

### 5. Сорау: Ирем белән аерылганнан соң, ул миңа алиментлар түләп бара. Әмма мин моны тыелган дип ишеттем. Балам була торып, миңа эшләргә рөхсәт ителәме?

**Җавап:** Билгеле булганча, ир өстенә җефетен тәэмин итү йөкләнгән. Аерылышкан очракта исә ир-ат хатынын гыйддә вакытында гына тәэмин итәргә бурычлы, ә ул үткәч, бу бурыч аның өстеннән төшә. Динебез буенча, ир-ат элеккеге хатынын ул яңадан кияүгә чыкканчыга кадәр тәэмин итеп торырга тиеш түгел. Соравыгызда сез балагызны искә аласыз. Әгәр ул бала шушыирегездән икән, аны матди яктан тәэмин итү тулысы белән элеккеге ирегезгә ята. Бу дин күзлегеннән дә, законыбыз буенча да шулай. Сез баланы караган, тәрбияләгән өчен дә ирегездән түләү хакы алырга хокуклы.

Шушы ярдәм сезгә көн күрергә җитәрлек икән, эшләмәсәгез дә мөмкин. Шуны да истә тотарга кирәк, хатын-кызның эшләвенә нindидер киртәләр юк.

Ә Аллаһка яхшырак мәгълүм.

*ТР мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин*

# Үрнәк затлар

# Беренче тугры хәлиф – Әбү Бәкер ؓ

**Тулы исеме:** Әбү Бәкер Әс-Сыддыйк Габдуллаһ ибн Әбү Кухәфә Госман ибн Гамр ибн Кәгъб Әл-Кораеши Әт-Тәмими.

**Әтисе:** Госман ибн Гамр (күп очракта аны Әбү Кухәфә дип йөрткәннәр).

**Әнисе:** Сәлмә бинт Сахр (күп очракта аны Өмм әл-хайр дип атаганнар).

**Кушаматлары:**

1) «Әс-Сыддыйк» – дөрес сөйләүче; бу исемне Мөхәммәд ﷺ аңа Исра вә Миграҗ вакыйгасыннан соң бирә – ул Җәбраилгә ؑ: «Кешеләр миңа ышанмаслар (минем төнлә күккә сәяхәт кылуыма)», – дип әйтә. Җәбраил ؑ аңа: «Ләкин Әбү Бәкер сиңа ышаныр, ул – Әс-Сыддыйк», – дип җавап бирә. Шуннан соң Мөхәммәд ﷺ аны Сыддыйк дип атый башлый;

2) «Гатик» – уттан котылучы; Мөхәммәд ﷺ болай дип әйткән булган: «Әгәр уттан котылучыны күрәсегез килсә, Әбү Бәкергә карагыз».

**Яшәгән еллары:** Әбү Бәкер ؓ Мөхәммәдтән ﷺ 2 яшь тә берничә айга кечерәк булып, якынча 573 елда туган. 634 елда вафат була.

**Хәлифлек еллары:** 632-634 (2 ел, 3 ай һәм 9 көн хәлиф булып торган).

**Балалары:** улы Габдуллаһ һәм кызы Әсма – беренче хатыны Катилә бинт Габделгуззәдән; улы Габдрахман һәм кызы Гайшә – хатыны Өмм Румән бинт Гамирдән; улы Мөхәммәд – Әсма бинт Умәйс исемле хатыныннан; кызы Өмм Көлсем – Хөбәйбә бинт Хариҗә ибн Зәйд: Әбү Бәкер ؓ үлгән вакытта Хөбәйбә йөкле була, баласын иренең вафатыннан соң гына таба.

## Ислам динен кабул итүе

Әбү Бәкер ﷺ олы яшьтәге ирләрдән иң беренче булып Ислам динен кабул итә (Расүлүллаһның ﷺ хатыны Хәдичә ﷺ, аларның гаиләсендә тәрбияләнүче Гали һәм Зәедтән соң дүртенче кеше буларак). Аңа бу вакытта 38 яшь була. Иң беренче булып Мөхәммәд пәйгамбәр белән ﷺ намаз укучы кеше дә Әбү Бәкер ﷺ була. Ул кечкенәдән Мөхәммәд ﷺ белән дус булып яшәгән.

Әбү Бәкернең ﷺ кызы Әсма ﷺ аның турында: «Минем әти исламны иң беренчеләрдән булып кабул иткән. Аллаһ белән ант итеп әйтәм, мин әтиемнең Исламда булмаганын хәтерләмим», – дип әйткән була. Икенче кызы Гайшә ﷺ дә: «Мин әти-әниемне бары тик Ислам динендә хәтерлим. Расүлүллаһ ﷺ иртән һәм кич безгә кермичә калган бер генә көн дә булмый торган иде», – дип әйткән.

Исламга кадәр дә Әбү Бәкер ﷺ бик дөрес кеше була: беркайчан да хәмер эчми, потларга табынмый, ялганламый. Ул иң баштан ук Мөхәммәднең ﷺ пәйгамбәр булуында шик белдерми һәм шул ягы белән башка сәхабәләрдән аерылып тора. Аның иманы шулкадәр көчле була, Мөхәммәд ﷺ әйтүенчә: «Әгәр үлчәүнең бер тәлинкәсенә Әбү Бәкернең иманын куйсаң, икенче ягына калган кешеләрнең иманын салсаң, Әбү Бәкернең иманы авыррак килер иде», – ди.

Шулай ук Әбү Бәкер ﷺ иң беренче дингә өндәүчеләрдән була, шуның өчен аны «беренче хатыйп» дип йөртә торган булганнар. Әбү Бәкернең тырышлыгы белән Госман ибн Гаффән, Талхә ибн Гобәйдуллаһ, Сәгыйд ибн Әбү Вәккас, Габдрахман ибн Гауф, Зөбәер ибн Гаввам кебек җәннәт белән шатландырылган сәхабәләр Ислам диненә килә.

## Әбү Бәкернең ﷺ дәрәҗәсе

Әбү Бәкер ﷺ бик хикмәтле һәм тәкъва кеше була. Ул һәрвакыт изгелеккә омтылып яши, беркайчан да намусына тап төшерми. Ислам динен кабул иткәнгә кадәр дә ул Мәккә шәһәрендә бик югары дәрәҗәгә ия кеше була. Ул Корәеш кабиләсенең иң бай сәүдәгәрләреннән булып, казый вазифасын да башкарган. Сәүдә эшләрендә ышанычлы булуы сәбәпле, кешеләр аның белән эш итәргә яратканнар. Нәтиҗәдә, ул шактый күп мал туплый ала. Ислам динен кабул иткәнгә кадәр үк аның байлыгы 40 мең дирһәм буларак бәяләнә.

Әбү Бәкернең ﷺ дәрәҗәсе Пәйгамбәребез ﷺ янында да югары була. Мөхәммәд ﷺ аны Һиҗрәт кылганда үзенә иптәш итеп сайлый. Аллаһы Тәгалә Коръәндә дә аны Расүлүллаһның иптәше дип атый:

**«Әй сез, иман китергәннәр! Әгәр Аллаһның Илчесенә ярдәм итмәсәгез, Аллаһ аңа ярдәм итәчәк; кәферләр аны Мәккәдән куып чыгарып, китәргә мәҗбүр иткәч, Ул аңа ярдәм итте бит. Ул вакытта аның белән бер генә юлдашы – Әбү Бәкер генә бар иде, һәм алар икәү генә иделәр. Һәм алар тау куышында аларны куа килгән мөшрикләрдән яшеренгәч, Әбү Бәкерне пәйгамбәрнең тормышы өчен курку биләп алды, ләкин Мөхәммәд ﷺ Әбү Бәкерне тынычландырып әйтте: «Кайгырма, Аллаһ безнең белән, Ул безгә ярдәм итәчәк!» Шунда Аллаһ пәйгамбәрнең дусты йөрәгенә тынычлык иңдерде, пәйгамбәрен Аннан (Аллаһы Тәгаләдән) башка беркем дә күрми торган гаскәре (фәрештәләр) белән ныгытты! Шулай кәферләрнең ширеккә чакыруы юкка чыкты, һәм Аллаһның дине җиңде. Аллаһ бөтен нәрсәгә Кодрәтле, Җиңелмәс һәм гамәлләр белән идарә итүдә Хикмәтле!»**

Тәүбә, 9/40

Әбү Бәкер ﵁ Мөхәммәдне ﷺ бик якын күрә. Аның янында ул үзен бик тыныч хис итә, күңелен рәхәтлек биләп ала. Шуңа күрә сәүдә эшләре аркасында бер-берсеннән аерылып торырга туры килсә дә, кайту белән Әбү Бәкер ﵁ тизрәк дусты Әмин ﷺ янына ашыга торган була.

Алар кешеләрне дингә өндәгәндә дә һәрвакыт бергә булалар. Бервакытны алар Кәгъбәтуллаһ янында намаз укыганда, Гокбә ибн Әбү Мөгайт Пәйгамбәребезнең сәҗдәгә киткәнен көтеп тора да, аның өстенә менеп утырып, чалмасының бер очы белән аны буа башлый. Әбү Бәкер ﵁ тизрәк намазын укып бетерә дә, Гокбәне этеп төшерә һәм: «Сез кешеләрне «Раббым – Аллаһ» дигәне өчен генә дә үтерәсезмени?» – дип әйтә. Аллаһы Тәгалә Коръәндә шул вакыйгага охшаш Фиргавен заманында яшерен рәвештә Аллаһка ышанган кеше кыйссасын китерә:

> **«Фиргавен кавеменнән иман китергән кеше үз халкына мөрәҗәгать итеп әйткән: «Әллә сез кешене: «Минем Раббым – Аллаһ!» – дип әйткәне һәм сезнең Раббыгыздан – сезнең тормышыгызның Кодрәтле Хакименнән – сезгә ачык дәлилләр алып килгәне өчен генә үтерергә җыенасызмы? Әгәр ул ялганчы булса, ялганы белән ул үзенә генә зыян китерә; әгәр ул хаклы булса, сез ул кисәткән газапның бер өлешенә булса да дучар ителәчәксез. Аның чикләрен үткән һәм ялганлаган кешене Аллаһ коткармаячак».**

«Мөэмин», 40:28

Башка бер вакытны кешеләрне дингә өндәр өчен Мөхәммәд ﷺ бер йортка кереп киткәч, Әбү Бәкер ﵁ аны саклап урамда кала. Шулвакыт каяндыр мөшрикләр килеп чыгып: «Иптәшең кая?» – дип Әбү Бәкерне ﵁ кыйный башлыйлар. Кыйнаудан ул хәтта аңын югалтып егыла, ләкин Мөхәммәднең ﷺ тормышы өчен борчылып, аның турында бер сүз дә әйтми. Бәни Тәмим кешеләре килеп чыгып кына Әбү Бәкерне ﵁ саклап

кала. Шунда да аңына килгәч Әбү Бәкернең رضي الله عنه беренче сүзе: «Мөхәммәд ﷺ нихәл?» – була. Мөхәммәд ﷺ Әбү Бәкерне رضي الله عنه тугрылыгы өчен бик якын күрә, Һиҗрәт кылганда да үзенә иптәш итеп ул Әбү Бәкерне رضي الله عنه сайлый.

## Әбү Бәкернең رضي الله عنه юмартлыгы

Әбү Бәкер رضي الله عنه Ислам динен кабул иткәнче Мәккә шәһәрендә танылган сәүдәгәрләрдән була. Ислам динен кабул иткәч тә, ул сәүдә белән шөгыльләнүен туктатмый. Ул малын хәләл юл белән табып, аны Ислам дине файдасына тотарга ярата.

Әбү Бәкер رضي الله عنه беренчеләрдән булып Ислам динен кабул иткән колларны хуҗаларыннан сатып алып азат итә башлый. Ул азат иткән колларның берсе соңыннан мәшһүр мөәзин булып киткән Биләл ибн Рабаһ була.

Исламны кабул иткәндә аның байлыгы 40 мең дирһәм buларак хисапланса, Һиҗрәт кылган вакытта ул сумма 5 меңгә кала, чөнки ул бөтен байлыгын ислам файдасына тоткан була. Мәдинәгә күчкәч тә Әбү Бәкер رضي الله عنه үз малын Мәккәдәге гадәте буенча сарыф итә: коллар азат итә, мохтаҗларга ярдәм күрсәтә.

Мөхәммәд ﷺ төрле сугышларга мал җыйганда да, Әбү Бәкер رضي الله عنه беренчеләрдән була. Мәсәлән, Табук сугышына Әбү Бәкер رضي الله عنه үзенең бөтен байлыгы белән килә.

## Әбү Бәкернең رضي الله عنه тыйнаклыгы

Әбү Бәкер رضي الله عنه сәхабәләр арасында булган дәрәҗәсенә карамастан, иң тыйнакларыннан санала, тәкәббер булмый. Әбү Бәкер رضي الله عنه шәһәр читендә яшәүче картларның йортларына барып, аларны җыештыра, сарыкларын сава. Бервакыт Гомәр رضي الله عنه, Әбү Бәкернең رضي الله عنه көн дә шәһәр читенә чыгуыннан шикләнеп, аның артыннан күзәтә. Соңыннан Әбү Бәкернең رضي الله عنه йорт

җыештыруын күргәч: «Мин бу кеше хакында ничек шулай начар уйлый алдым икән», – ди һәм үзе дә бу эш белән шөгыльләнә башлый.

Әбү Бәкер رضي الله عنه хәлиф булганнан соң да бу эшләрен калдырмый. Халык: «Син инде хәзер хәлиф булдың, безне калдырырсың, дип уйлыйбыз», – дип әйтәләр. Әбү Бәкер رضي الله عنه: «Әйе, мин сезнең хәлифегез булдым, ләкин әле иң яхшыгыз түгел», – дип җавап бирә.

## Әбү Бәкернең رضي الله عنه батырлыгы

Әбү Бәкер رضي الله عنه сәхабәләр арасында иң батырларыннан санала. Ул Мөхәммәд ﷺ катнашкан бөтен сугышларда да катнаша. Кайберләрендә гаскәр башлыгы була, кайберләрендә байрак йөртә. Шул ук вакытта ул Мөхәммәднең ﷺ чатырын саклаучы була.

Бервакытны Гали رضي الله عنه сәхабәләр белән утырганда болай дип сорый: «Безнең арада иң батыр кешенең кем икәнен беләсезме?» Сәхабәләр: «Без синнән дә батыррак кешене белмибез, әй, Гали», – дип әйтәләр. Гали رضي الله عنه: «Мин ул кешенең яртысы гына,» – ди. Сәхабәләр: «Кем соң ул?» – дип сорагач, Гали رضي الله عنه: «Әбү Бәкер», – дип җавап бирә. «Бәдер сугышында мөшрикләр гаскәр белән килгәнен ишеткәч, без аларны каршы алырга хәзерләндек, Мөхәммәдкә ﷺ чатыр кордык. Шунда: «Кем Мөхәммәдне ﷺ саклый?» – дип сорагач, бу эшкә алынучы кеше табылмады, бары Әбү Бәкер رضي الله عنه генә алынды. Әбү Бәкер رضي الله عنه шул рәвешле күп кенә сугышларда Мөхәммәднең ﷺ саклаучысы булып торды. Гали رضي الله عنه шулай ук: «Бәдер сугышы көнне миңа һәм Әбү Бәкергә әйтелде: безнең беребезне Җәбраил عليه السلام, икенчебезне Микаил عليه السلام яклап сугыша. Шулай ук Исрафил عليه السلام дә әлеге сугышта безнең белән бер дәрәҗәдә катнаша», – дип әйткән булган.

Өхед сугышы вакытында да Әбү Бәкер رضي الله عنه гаять ныклык күрсәтә: мөселманнар куркуга төшеп, сугыш кырын ташлап киткән вакытта, ул кыю рәвештә Пәйгамбәребез ﷺ янында көрәшүен дәвам итә.

## Әбү Бәкернең ﵁ Аллаһы Тәгаләдән куркуы

Мөхәммәд ﷺ белән тыгыз бәйләнештә булуы сәбәпле, Әбү Бәкер ﵁ Ислам динендә көчле мөселманнардан була. Әбү Бәкер ﵁ Аллаһы Тәгаләдән килгән бөтен хәбәрне беренчеләрдән булып ишетеп, гамәлгә ашырырга ашыга торган була, дөньялыкта кылган хаталары өчен борчылып, күп тапкырлар истигъфар кыла. Бервакыт ул агачтагы кошны күреп әйтә: «Мин дә бу кош кебек булсам иде. Ул теләгән җиренә кунып, Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтләрдән тамагын туйдыра, аңа сорау да юк, җавап та юк...»

## Әбү Бәкернең ﵁ җәннәт белән шатландырылуы

Әбү Бәкер ﵁ үзе исән чагында ук җәннәт белән шатландырылган 10 сәхабәнең берсе була.

Беркөнне Мөхәммәд ﷺ сәхабәләре янына килеп сорау бирә: «Кайсыгыз бүген ураза тотты?» Әбү Бәкер ﵁: «Мин», – ди. «Кайсыгыз бүген мескенне ашатты?» – дип сорагач та, Әбү Бәкер ﵁: «Мин», – дип әйтә. «Кайсыгыз бүген авыруның хәлен белде?» – дип сорый Расүлүллаһ ﷺ. Әбү Бәкер ﵁ янә: «Мин», – ди. «Җеназа намазында кем катнашты?» – дип сорагач та, Әбү Бәкер ﵁: «Мин», – ди. Шуннан соң Мөхәммәд ﷺ әйтә: «Әгәр берәү бу эшләрне бер көндә җыйса, Аллаһы Тәгалә аны җәннәтле кылыр», – ди. Бу көнне Әбү Бәкер ﵁ бу эшләрнең барысын да үтәгән була, ә калган сәхабәләр бу эшләрнең кайберләрен генә үтәгән иделәр.

## Әбү Бәкернең ﵁ хәлиф булып сайлануы

Әбү Бәкер ﵁ 632 елда (һиҗри тәкъвим буенча 11 елда) хәлиф булып сайлана. Мөхәммәд ﷺ вафат булганнан соң сәхабәләр Бәну Сәгъд йортына җыелып, хәлиф сайлау буенча киңәшләшәләр һәм барысы да Әбү Бәкернең ﵁ хәлиф булуына ризалыкларын белдерәләр.

Әбү Бәкер ﵁ өч төрле сәбәп белән хәлиф булып сайлана:

1. Мөхәммәд ﷺ авырый башлагач, намазга чыга алмаганда үзе урынына имам итеп Әбү Бәкерне ﵁ билгеләде. Ул Мөхәммәд ﷺ исән вакытында 17 намазда имам булды. Сәхабәләр шунда: «Мөхәммәд ﷺ Әбү Бәкер белән безнең динебез өчен риза булды, без аның белән дөньябыз өчен риза», – диделәр.

2. Бервакытны бер хатын килеп Мөхәммәдкә ﷺ сораулар бирде һәм киткәндә: «Йә, Расүлүллаһ, әгәр икенче килгәндә сине тапмасам, кемгә мөрәҗәгать итим?» – дип сорагач, Мөхәммәд ﷺ Әбү Бәкергә ишарәләде.

3. 9 нчы һиҗри елда Мөхәммәд ﷺ Әбү Бәкерне хаҗ белән идарә итәргә билгеләде. Бу шулай ук мөселманнарның Әбү Бәкергә ышанычын күрсәтә.

Әбү Бәкер ﵁ 2 ел, 3 ай да 9 көн хәлифлек итте (11-13 һиҗри еллар, милади 632-634 еллар).

Хәлиф булып сайланганнан соң, Әбү Бәкер ﵁ халыкка түбәндәге сүзләр белән мөрәҗәгать итә: «Ий кешеләр! Мин сезнең җитәкчегез итеп сайландым, ләкин мин сезнең арагызда иң яхшысы түгелмен. Мин бик озак Расүлүллаһның ﷺ юлдашы булдым, аннан илаһи галәмәтләр хакында белдем, аның үз-үзен тотышын күзәттем, шуңа күрә ул безгә өйрәтергә теләгәннәрне алдым. Йә, кешеләр, шуны белегез: кеше кыла алган иң акыллы гамәл – Аллаһтан курку, ә иң начар гамәл исә – бозыклык кылу һәм туры юлдан тайпылу. Әгәр мин дөрес гамәл кылсам, миңа ярдәм итүчеләрдән булыгыз; ялгышсам, мине дөресләгез».

## Әбү Бәкернең ﵁ эшләп калдырган мәшһүр эшләре

1. Мөселманнарның бердәмлеген саклап кала

Мөхәммәд ﷺ вафат булганнан соң халык арасында зур фетнәләр куба башлый. Кайберәүләр: «Мөхәммәд ﷺ үлде – дин бетте», – дип әйтә. «Ул үлмәде, Раббысы белән генә очрашырга китте», – дип әйткән кешеләр

дә табыла. Шул рәвешле халык ни эшләгәнен белештермәгән вакытта Әбү Бәкер ﷺ идарәне үз кулына ала һәм: «Әй кешеләр! Кем Мөхәммәдкә ﷺ гыйбадәт кылган булса, ул үлде, сез дә шуның белән һәлак булырсыз. Кем Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылган булса, Ул бар һәм мәңгелек», – дип әйтә. Алга таба ул түбәндәге аятьләрне укый:

> **«Мөхәммәд һичкем түгел, мәгәр Аллаһның хак расүледер. Әлбәттә, аннан әүвәл күп расүлләр килеп киттеләр. Әгәр Мөхәммәд үлсә яки үтерелсә, сез, сәхабәләр, хак динне ташлап, әүвәлге батыл динегезгә кайтырсызмы? Бер мөэмин Ислам динен ташлап әүвәлге батыл диненә кайтса, Аллаһка зарар кыла алмас, мәгәр үзенә зарар кылыр, һәлак булыр. Ислам динендә булганы өчен шөкер итеп, Аллаһ юлында сугыш кылучыга Аллаһ бик тиз җәннәт нигъмәтләре белән хакын түләр».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:144

> **«Ий, Мөхәммәд, син дә үлүче, алар да үлүчеләрдер, үлемгә хәзерләнегез».**

«Зүмәра / Халык Төркеме», 39:30

Шул рәвешле кешеләр Мөхәммәднең ﷺ вафаты белән генә диннең бетмәгәнлеген аңлый һәм яңадан дингә кайта башлый.

Гомәр ﷺ шул вакытта Әбү Бәкергә ﷺ: «Әгәр бу көндә син безнең белән булмаган булсаң, без харап булган булыр идек», – ди.

2. Ислам дәүләтендә тотрыклылык урнаштыра

Мөхәммәд ﷺ вафат булыр алдыннан Усәмә ибн Зәед җитәкчелегендә румнарга каршы гаскәр туплап чыгарып җибәргән була. Гаскәр юлда булган вакытта Расүлуллаһ якты дөньядан китеп бара. Шунда кайберәүләр инде хәзер сугышып та торырга кирәк түгелдер, дип кире кайтмакчы була. Әбү Бәкер ﷺ исә фәрман чыгара: «Мин Мөхәммәд ﷺ

бәйләгән төенне чишмим», – ди һәм гаскәргә юлын дәвам итәргә куша. Бу сугышта мөселманнар җиңүгә ирешә. Әлеге җиңү Мөхәммәднең ﷺ үлеме белән генә диннең бетмәве, ислам дәүләтенең зәгыйфьләнмәгән булуына дәлил булып тора.

3. Ялган пәйгамбәрләр белән көрәш алып бара

Мөхәммәд ﷺ исән булган вакытта да, аның вафатыннан соң да төрле тарафларда ялган пәйгамбәрләр барлыкка килә. Мәсәлән, Мусәйләмә Әл-Кәззәб, Туләйха ибн Әсәд, Сәҗдә исемле хатын. Әбү Бәкер ؓ аларга каршы гаскәр җибәрә һәм ялганнарын фаш итә.

4. Шәригатькә бәйле фетнәне туктата

Мөхәммәд ﷺ үлгәннән соң кайбер мөселманнар намаз уку һәм зәкәт түләүдән баш тарта башлый. Шул вакытта Әбү Бәкер ؓ әйтә: «Мин намаз белән зәкәтне аеручылар белән соңгы сулышыма кадәр көрәшәчәкмен», – ди һәм аларга каршы да гаскәр туплап җибәрә һәм: «Йә дин юлына басасыз, йә җизья (мөселман булмаган кешеләр түли торган салым) түләячәксез», – дип игълан итә.

## Әбү Бәкернең ؓ авыруы һәм вафаты

Тарихчылар Әбү Бәкернең ؓ авыруын ике төрле сәбәпкә бәйлиләр. Беренче караш буенча, Әбү Бәкер ؓ салкын көнне госел алып бик каты салкын тидергән. Икенче караш буенча, яһүдиләр тарафыннан бирелгән агулы ризык ашаган.

Әбү Бәкер ؓ ике атна авырый, шуның 12 көнендә намазга чыга ала.

Әбү Бәкер ؓ үзенең үлеме якынлашуын сизеп, нәсыйхәт һәм васыятьләрен әйтеп калырга ашыга. Шул максат белән кызы Гайшәне чакыртып, малын санарга куша: «Әгәр мин хәлиф булганнан соң малым арткан булса, шул өлешне бәйтүлмалга (казнага) сал,» – дип боера. Шул рәвешле ул үзенең гаиләсенә бер дирһәм дә калдырмый. Малларын казнага кайтарырга боерганын белгәч, Гомәр ؓ аның турында: «Аллаһы

Тәгалә Әбү Бәкерне ярлыкасын. Ул шулкадәр үз-үзен чикләде, шул рәвешле үзеннән соң хәлиф булачак кешеләргә бик зур авырлык тудырды», – ди.

Мөхәммәд ﷺ вафатыннан соң чыккан фетнә кабат кабатланмасын өчен, Әбү Бәкер ﵁ үзеннән соң хәлиф итеп Гомәрне ﵁ билгеләп калдыра.

Гомәр ﵁: «Мин бу урынны үзем теләмәдем. Син миңа аны йөкләдең. Мин синең һәм Расүлүллаһның ышанычын акларга тырышачакмын», – дип әйтә.

Әбү Бәкер ﵁ 13 нче һиҗри елның (милади 634 ел) зөлкагъдә аеның 14 нче көнендә 63 яшендә вафат була.

Соңгы сүзләре: «Әлхәмдүлилләһ, мөселман булып үләмен. Йә, Раббым, мине изгеләр белән очраштыр», – була.

Әбү Бәкергә ﵁ җеназа намазын Гомәр ﵁ үзе укый, каберенә улы һәм Габдрахман ибн Гауф төшерә. Мөхәммәд ﷺ кабере белән янәшә күмелә.

Әбү Бәкер ﵁ тугры хәлифләр арасында үз үлеме белән үлүче бердәнбер кеше. Ул үлгәндә әтисе Әбү Кухәфә әле исән була.

# Әсма бинт Әбү Бәкер رضي الله عنها

Ислам динен иң беренчеләрдән булып кабул итүче сәхабәләрнең берсе (динне 18 нче кеше булып кабул иткән), Расүлуллаһның ﷺ якын дусты һәм ярдәмчесе Әбү Бәкернең кызы, Гайшәнең رضي الله عنها 10 яшькә олырак апасы (аталары бер, аналары төрле), җәннәт белән шатландырылган ун сәхабәнең берсе булган Зөбәер ибн Әл-Гаввәмнең хатыны. Ул 56 хәдисне тапшырган, дип риваять ителә.

**Исеме:** Әсма бинт Әбү Бәкер; Зәтун-нитәкайн (ике пута иясе).

**Туган елы, урыны:** 595 ел/Һиҗрәткә кадәр 27 ел алдан Мәккәдә туган.

**Вафаты:** 692 ел/һиҗри календарь буенча 73 елда Мәккәдә вафат була.

**Әтисе:** Әбү Бәкер Әс-Сыддыйк رضي الله عنه, Мөхәммәд пәйгамбәрнең ﷺ иң якын һәм олы сәхабәсе, аның үлеменнән соң берене хәлиф.

**Әнисе:** Катилә бинт Габделгуззә.

**Тормыш иптәше:** Зөбәер ибн Әл-Гаввәм رضي الله عنه.

**Балалары:** Габдуллаһ ибн Зөбәер; Гурвә ибн Зөбәер; Әл-Мөнзир ибн Зөбәер; Гасыйм ибн Зөбәер; Әл-Мөһаҗир ибн Зөбәер; Хәдичә Әл-Кубра бинт Зөбәер; Өмме Хәсән бинт Зөбәер; Гайшә бинт Зөбәер.

Әсма رضي الله عنها Ислам динен кабул иткәндә бик яшь бер кыз була. Ул иманы, өммәте өчен күрсәткән тырышлыгы, түземлеге һәм сабырлыгы белән һәркемгә үрнәк була алган.

## Ике пута иясе – Зәтун-нитәкайн

Аллаһ тарафыннан Расүлуллаһка ﷺ Мәккәдән китәргә рөхсәт ителгәч, Мәдинәгә юнәлгәндә, Әсма رضي الله عنها аңа һәм әтисенә сәфәргә әзерләнергә ярдәм иткән. Билендәге путасын (билбавын) икегә аерып, капчыкларның авызын шулар белән бәйләгән. Моның өчен Мөхәммәд

ﷺ : «Әсмага җәннәттә ике пута бир», – дип Аллаһка дога кылган. Шул вакыйгага бәйле Әсманы Зәтун-нитәкайн, ягъни ике пута иясе дип атый башлаганнар.

Пәйгамбәребез ﷺ һәм Әбү Бәкер ﵁ Сәур исемле мәгарәдә яшеренгән вакытта да аларга азык-төлек һәм су китерүче Әсма ﵂ булган.

## Сер саклый белүче

Мөхәммәд ﷺ яшерен рәвештә Мәккәдән китәргә туры киләчәген Әбү Бәкернең ﵁ үзенә генә әйтергә теләгән, әмма ул кызларына ышаныч белдереп: «Кызларым сер саклый белә», – дип әйткән. Дөрестән дә, алар Мәккәдән киткәч, аларны эзләп килгән кешеләргә Әсма ﵂ атасының кайда икәнлеген әйтмәгән. Гәрчә Әбү Җәһел моның өчен колагындагы алкасы чыгып очарлык итеп бик каты суккан булса да, ул куркып калмаган һәм Ислам тарихындагы бик әһәмиятле Һиҗрәт вакыйгасы хакында берни белдермәгән.

Моннан тыш, Мәдинәгә киткәндә Әбү Бәкер «3*, Аллаһның Расүленә ﷺ кирәге чыгар дип, бөтен акчасын үзе белән алып киткән, гаиләсенә бернәрсә дә калдырмаган. Шуны ишетеп килгән мөшрик Әбү Күхәфә – Әбү Бәкернең атасы: «Сезгә берни калдырмыйча, ул сезне зур кайгыга салган», – дип сөйләнеп торган вакытта, Әсма ﵂ гаять зирәклек күрсәтеп, атасының акча янчыгына тиз арада ташлар тутырып, сукыр бабасына тоттырып күрсәткән һәм аны: «Кара, бабам, ул безгә менә боларны калдырды», – дип юаткан. Шул рәвешле ул мөселман булмаган туганнарыннан ярдәм кабул итмәячәген дә белдергән.

## Мәдинәдә туган беренче мөселманның анасы

Мәдинәгә Һиҗрәт кылганчы Әсма ﵂ Зөбәер ибн Әл-Гаввәмгә ﵁ кияүгә чыккан. Әсмага өйләнгәндә Зөбәернең ﵁ бер аттан кала башка

бернинди малы да булмаган. Мәдинәдә алар әүвәл бик ярлы яшәгәннәр. Әсма ирен бик хөрмәтләгән, аңа итагать иткән. Аларның биш улы һәм өч кызы туган.

Мәдинәгә күчеп киткән вакытта Әсма ﵂ улы Габдуллаһка йөкле булган. Инде табар вакыты җитүенә карамастан, Әсма Аллаһ ризалыгы өчен, авыр һәм озын сәфәрдән курыкмыйча, Һиҗрәт кылган. Мәдинәгә килеп җитәрәк, Кубә дигән авылда ул Габдуллаһны тапкан. Ул мөһаҗирләрнең Мәдинәдә туган беренче баласы булган. Әсма әле туган сабыен Расүлүллаһка алып килгән. Мөхәммәд ﷺ балага хөрмә чәйнәп каптырган (тәхник йоласын башкарган) һәм аның өчен Аллаһка дога кылган. Бу баланың тууы бөтен мөселманнар өчен дә зур шатлык булган, чөнки ул вакытта яһүдләр: «Без мөселманнарга бозым ясадык, аларның балалары булмаячак», – дип мөһаҗирләрнең күңеленә шик салган булган.

## Юмартларның юмарты

Әсма бик юмарт, башкаларга карата игътибарлы һәм ярдәмчел хатын булган. Аның бу якларын атасына охшаган булуы белән аңлаталар. Әсманың улы Габдуллаһ ﵁ болай дип әйтә торган булган: «Мин үз гомеремдә туган апам Гайшә һәм әнием Әсмадан да юмартрак хатын-кызлар күрмәдем. Әмма аларның юмартлыклары бер-берсеннән аерылып тора иде. Гайшә апа мохтаҗлар арасында таратырлык күләмдә җыелганчы, аз-азлап акча җыя иде. Ә әниемнең кулында берәр нәрсә булса, аны таратмыйча икенче көн җиткәнне дә көтә алмый иде».

## Аллаһ ризалыгы өчен ярату

Әсманың атасы да, сеңлесе дә, ире һәм башка якыннары да мөселманнарның иң беренчеләреннән булган. Әмма ләкин әнисе Катилә Ислам динен кабул итмәгән, хәтта атасы Әбү Бәкердән аерылып киткән

булган. Көннәрдән бер көнне Катилә бүләкләр белән кызы Әсма янына Мәдинәгә килгән. Ул аның әнисе булуына карамастан, Әсма аны өйгә кертмәгән, әүвәл Расүлүллаһның ﷺ рөхсәтен сорарга булган. Ул рөхсәт итмәгән булса, Әсма әнисен кире борып җибәрергә әзер булган. Мөхәммәд ﷺ аңа әнисенә карата якты йөз күрсәтергә, бүләкләрен кабул итеп, аны күркәм рәвештә кунак итәргә боерган, чөнки Катилә, Ислам динен кабул итмәсә дә, бервакытта да мөселманнарга золым кылучылардан булмаган. Шушы вакыйгага бәйле «Мүмтәхәнә» сүрәсенең 8-9 аятьләре иңгән, дип хәбәр итәлә:

**«Аллаһ сезне Ислам диненә каршы сезнең белән сугыш кылмаган вә сезне йортларыгыздан куып чыгармаган кавемнәр белән яхшы мөгамәләдә булудан һәм аларга гаделлек кылудан тыймыйдыр. Дөреслектә, Аллаһ гадел кешеләрне сөядер. Аллаһ, әлбәттә, сезне тыядыр ислам диненә каршы сезнең белән сугышкан вә сезне йортыгыздан куып чыгарган һәм, кәферләргә дус булып, сезне йортыгыздан чыгарырга ярдәм иткән монафикъларга дус булудан. Кәферләргә һәм монафикъларга дус булган мөселманнар алар залимнәрдер».**

## Түзем ана

Әсма бинт Әбү Бәкер ислам тарихына иң түзем әниләрнең берсе буларак кереп калган. Аның инде барлык якыннары, белгән сәхабәләре, шул исәптән сеңлесе Гайшә ؓ дә вафат булган була. Ләкин Әсманың сабырлыгы улы Габдуллаһ белән соңгы очрашуында кабат сынала.

Йәзид ибн Могавия вафатыннан соң хәлифлек Әсманың улы Габдуллаһ ибн Зөбәер ؓ кулына күчкән. Аңа Мисыр, Гыйрак, Хиҗаз, Хорасән җирләре һәм Шамның зур өлеше буйсынган булган. Өмәвиләр шунда ук Зөбәергә каршы сугыш игълан иткәннәр һәм берничә ай дәвамында канкойгыч вакыйгалар барган. Һәлак булуына берничә сәгать кенә калгач,

Габдуллаһ үзенең берничә сугышчысы белән Мәккәдә Кәгъбәтуллаһ янына яшеренгән һәм әнисе Әсма янына киңәш сорап килгән: өмәвиләргә буйсыныргамы яисә һәлак булганчы сугышыргамы. Әнисе аңа хәерле үлем теләп, озатып калган. Баласы Аллаһ юлында һәлак булачагын аңлаган ана кеше улына үлгәнче хакыйкать өчен кыю көрәшергә, дөнья нигъмәтләреннән баш тартырга өндәгән, хәтта өстендәге сугыш киемен салып, киң чалбар гына киеп сугышырга боерган. Шул көннең кояшы баеганчы ук Габдуллаһ ибн Зөбәер шаһит булып Раббысы хозурына күчкән.

Озак та үтми, әнисе Әсма да 100 яшькә җитеп вафат булган. Ул үлгәндә, инде олы яшьтә булуына карамастан, күзләре инде томаланса да, акылы зәгыйфьләнмәгән, бер теше дә төшмәгән була. Әсма мөһаҗир хатыннардан иң соңгысы булып үлгәннәрдән санала. Аның бервакытта да килгән авырлыкларга зарланмаганы, һәрвакыт нык һәм түзем булып кала алуы хәбәр ителә. Аллаһ аннан разый булсын!

# Фән

# Коръән турында гыйлем

(Дәвамы)

## Мәккәдә иңгән аятьләрнең эчтәлегенең үзенчәлекләре

Коръәндәге «Мәккә вәхиләре» дигән өлешнең эчтәлегендә ошбу мәсьәләләргә һәм темаларга аеруча игътибар бирелә:

1. Ислам диненең нигезләрен җиткерү – барча мәхлукларны тәүхидкә, Аллаһы Тәгаләнең Берлеген тануга һәм фәкать Аңа гына табынуга чакыру; Ахыргы Көнгә, Хисапка, Җәннәткә һәм Җәһәннәмгә инандыру; Пәйгамбәребезнең ﷺ һәм башка пәйгамбәрләрнең (Аллаһ алардан разый булсын) миссиясенә инандыру; фәрештәләрнең барлыгына инандыру.

Мисал өчен «Хикәя» сүрәсен генә алыйк һәм уйланыйк. Бу сүрәдә нәкъ әнә шул нигезләр карала. Менә ул сүрәдәге Аллаһы Тәгаләнең Берлеген танытып, фәкать Аңа гына табынырга чакыра торган аятьләр:

**«Раббың аларның күңелләрендә яшергән имансызлык һәм башка бозык уйларын һәм телләре белән изһар иткән нәрсәләрен дә беләдер. Вә Ул – Аллаһ – Аннан башка илаһ юктыр, мәгәр Ул Үзе генәдер, дөньяда вә ахирәттә мактау Аңа хастыр, вә һәр эштә булган хөкем янә Аллаһка хастыр һәм ахырда Аңа кайтарылачаксыз. Әйт: «Беләсезме, әгәр Аллаһ кичне караңгы хәлендә Кыяматкә хәтле калдырса, сезгә Аллаһтан яктылык китерә торган башка илаһ бармы, йә шуны ишетәсезме?» Янә әйт: «Беләсезме, әгәр Аллаһ көндезне якты хәлендә Кыяматкә чаклы калдырса, рәхәтләнеп ял итә торган кичегезне китерергә Аллаһтан башка илаһ бармы? Әллә Аллаһ эшләрен күрмисезме. Аллаһ Үзенең рәхмәтеннән көндез илә кичне бар кылды, кичтә ял итүегез өчен, көндез кәсеп белән Аллаһның фазылыннан**

**таләп итүегез өчен, шаять, Аллаһның бу нигъмәтләренә шөкер итәрсез».**

«Касас / Хикәя», 28:69-73

Шулай ук Кыямәт көненең күренешләрен тасвирлаган «Ибраһим» сүрәсенең ошбу соңгы аятьләре турында да уйланыйк:

**«Аллаһ биргән вәгъдәсенә хилафлык кылыр дип уйлама! Тәхкыйк, Аллаһ көчле, залимнәрдән үч алачак. Ул көндә җир башка җир белән алмаштырылыр вә күкләр, вә кешеләр ялгыз вә кодрәт иясе булган Аллаһ хозурына китерелерләр. Ул көндә залимнәрне күрерсең – чылбырлар белән богауланган булырлар. Аларның киемнәре утта кыздырылган бакырдан яки сагыздан булып, йөзләрен ут каплар. Аллаһның бу гадел хөкеме һәр кешегә кылган эшенә күрә җәза бирер өчен. Аллаһы Тәгалә, шиксез, бик тиз хисап итүче. Бу сөйләүләр кешеләргә Ахирәттә булачак хәлләрне белдерү һәм ирештерүдер, Аллаһның рәхмәте вә газабы кемгә булачагын белеп торсыннар өчен һәм вәгазьләнеп Аллаһка тәүбә итеп төзәлсеннәр вә гөнаһлардан саклансыннар һәм Аллаһның бер генә икәнлеген белеп, Аңа гына гыйбадәт кылып вә гакыллы кешеләр вәгазьләнсеннәр өчен».**

«Ибраһим», 14:47-52

«Каф» сүрәсеннең ошбу аятьләрен укып уйланганнан соң йөрәкләр Ахыргы Көннең барлыгына ышану белән тула башлый:

**«Әллә ул гафилләр өсләрендәге күккә карамыйлармы. Без аны ничек терәксез төзедек, вә ул күкне йолдызлар белән зиннәтләдек, вә ул күктә һичнинди ярык, кимчелек юктыр. Дәхи дә җирне киң итеп яраттык, вә анда таулар салдык, вә**

**җирдә һәр үсемлекне аталы-аналы итеп үстердек, күңел күзе илә күреп, фикерләр һәм вәгазьләнер өчен, һәрбер Аллаһка кайтучы инабәтле бәндәләргә. Дәхи Без күктән файдалы булган суны иңдердек, аның белән бакчалар үстердек, вә урып алына торган игеннәрне үстердек. Вә озын, төз хөрмә агачын үстердек, ул хөрмәнең тезелгән бөреләре бардыр. Бәндәләргә ризык булсын өчен, ул су белән шәһәрләрнең үлгән табигатен тергездек. Каберләрдән кубарылып чыгу да шулай булыр».**

«Каф», 50:6-11

Менә «Кыямәт» сүрәсенең соңгы аятьләрендә бирелгән тагын бер саллы дәлил:

**«Әллә адәм баласы үзенә Аллаһтан йөкләмә йөкләтелмәүне, Аллаһка каршы эшләрдә ихтыярга куелуны һәм ахырда җавапсызлыкны телиме? Ул кеше мәнидән бер генә тамчы булган иде түгелме? Моның соңында оешкан кан булды, Аллаһ аны халык кылып кеше сыйфатына китерде. Аннан ир һәм хатын итеп халык кылды. Бу эшләрне эшләгән Аллаһның үлекләрне тергезергә көче җитмәсме?»**

«Кыямәт», 75:36-40

2. Дәлилләр, мисаллар куллану һәм төрле аңлатулар аша төрле ширки һәм дәһри карашларны һәм тар-мар итү, ялган караш тарафдарларының табына торган потларын чебен дәрәҗәсеннән дә түбәнрәк итеп күрсәтү.

Менә ошбу «Хаҗ» сүрәсенең аятен кара һәм уйлан:

**«Әй кешеләр! Сезгә гаҗәеп мисал китерелде, аны ишетегез Аллаһтан башка илаһка тоткан сыннарыгыз бер чебен дә халык кыла алмаслар, гәрчә барысы да җыелсалар, әгәр сыннарыгыз өстеннән бернәрсәне чебен алып китсә, ул нәрсәне кире кайтарырга сыннарыгыз кадир булмаслар, сыннарга табынып, алар-**

**дан ярдәм таләп итүче кеше дә зәгыйфь булды, ярдәм таләп иткән сыннар да зәгыйфь булдылар. Кешеләр Аллаһны тиешле зурлау белән зурламадылар, Аллаһ куәтле вә җиңүчедер. Аллаһ пәйгамбәрләргә килә торган илчене фәрештәләрдән ихтыяр итәр вә кешеләргә килә торган илчене кешеләрдән ихтыяр итәр, Аллаһ ишетүче вә күрүче».**

«Хаҗ», 22:73-75

Шулай ук Аллаһы Тәгаләнең «Ганкәбүт» сүрәсендә китерелгән ошбу сүзләре турында да уйлан:

**«Аллаһтан тыш сыннарны да дус тоткан мөшрикләрнең мисалы үрмәкүч кебектер: ул үзенә өй үрде, әлбәттә, өйләрнең иң зәгыйфе үрмәкүч өедер, салкыннан, яңгырдан файда бирмидер, шуның кебек сыннарны дус тоткан мөшрикләр дә алардан һич файда күрмәсләр, әгәр шуны белсәләр».**

«Ганкәбут / Үрмәкүч», 29:41

Билгеле ки, тәкълид, ягъни әүвәлгеләрнең гадәтенә сукырларча ияреп бару – бик зур ялгышлыкларга китерә торган куркыныч бер гамәл. Мөшрикләр исә, үзләренең динсезлекләрен аклар өчен, нәкъ шул сукыр ияручеләр кебек, үзләренең ата-бабаларына сылтанып бардылар да инде. Шуңа күрә дә Коръән, мөшрикләрнең һәм аларның ата-бабаларының ошбу үзенчәлеген исәпкә алып, кешеләрнең фикерләү сәләтләрен арттырырга һәм акыл офыкларын киңәйтергә дип тырышты. Шуның аша ул мөшрик-кәферләрнең ахмаклыгын фаш итте һәм аларны тәкълид кылып барганнары өчен хурлыкка калдырды. Фикер йөртә белгән һәрбер кеше моннан файдалы нәтиҗә ясарга тиеш. Бу бигрәк тә Ислам дошманнары артыннан сукырларча ияручеләргә кагыла.

Аллаһы Тәгалә әйтә: **«Әгәр аларга Аллаһ иңдергән Коръән хөкемнәренә иярегез, диелсә, алар әйтәләр: «Бәлки аталарыбызны**

**нинди диндә, нинди гамәлдә тапсак, шул гамәлгә иярәбез, аларның юлыннан чыкмыйбыз», – дип. Йә, шайтан аларны адашкан аталарына ияртеп, бидгать гамәлләрне кылдырып, җәһәннәмгә алып бара түгелме? Аталарының юлы җәһәннәмгә барса да, ул юлдан чыкмыйбыз диярләрме?»**

«Локман», 31:21

Шулай ук: **«Алар Аллаһ һәм пәйгамбәр сүзенә колак салмадылар, бәлки әйттеләр: «Без аталарыбызны бер диндә таптык, һәм аларга ияреп аларча дин тотабыз һәм Аллаһтан башкага гыйбадәт кылабыз», – дип. Синнән элек бер шәһәргә Аллаһ газабы илә куркытучы пәйгамбәр җибәрсәк, аларның нигъмәткә чумган олуглары әйтте: «Безнең аталарыбыз да шул диндә иделәр, алар диненнән чыкмыйбыз, без дә аларга иярәбез», – дип. Син аларга әйт: «Мин сезгә сезнең аталарыгызның диненнән дөресрәк вә турырак дин алып килгән булсам да, сез аталарыгызның батыл диненә иярәсезме?» Алар пәйгамбәргә әйттеләр: «Сезнең илә җибәрелгән дингә ышанмыйбыз». Без алардан каты газаб илә үч алдык, игътибар илә кара пәйгамбәрләрне ялганга тотучыларның ахыр хәле нинди булганын».**

«Зүхърүф / Зиннәтләнү», 43:22-25

3. Мәхлукат һәм галәмнәр турында дәлилләр китереп Аллаһы Тәгаләнең бөеклеген һәм кодрәтлеген раслаулар, илаһият һәм рубубият тәүхиде турында һәм, шулай ук, торгызылу һәм Кыямәт көннәре турында уйландырулар.

«Мәккә сүрәләрендә» Коръәннең чиксез (ирешә алмаслык) гомум белеме алдында фәннең көчсез булуы раслана, чөнки Коръәндә галәмнәр, кеше, аның тормышы, мәхлукатка кагылышлы хөкемнәр һәм Аллаһның

галәмнәр белән идарә итү тәртипләре турында мәгълүматлар һәм гыйлемнәр бирелә.

Менә «Локман « сүрәсендәге бу аятьләргә кара, анда кеше үз акылы белән ача алмаган, акылына сыйдыра алмаган һәм хәтта фәннең дә көчсезлеген исбат иткән гыйлемнәр тупланган: **«Әллә күрмисезме, Аллаһ күктә булган кояш, ай, йолдызларны вә җирдә хайваннарны вә табигать байлыгын сезгә файдаландырды, сезгә күренгән вә күренмәгән нигъмәтләрен мул итеп. Кешеләрдән бәгъзеләре Аллаһ хакында яки Аның дине хакында дәлилсез, белемсез, мәгърифәт нуры булган Коръәннән башка һәм үзе һидаятьсез булганы хәлдә хакны инкяр итеп вә ялганны яклап тартышырлар. Әгәр аларга Аллаһ иңдергән Коръән хөкемнәренә ияреґез диелсә, алар әйтәләр: «Бәлки аталарыбызны нинди диндә, нинди гамәлдә тапкан булсак, шул гамәлгә иярәбез, аларның юлыннан чыкмыйбыз», – дип. Йә, шайтан аларны адашкан аталарына ияртеп, бидгать гамәлләрне кылдырып, җәһәннәмгә алып бара түгелме? Аталарының юлы җәһәннәмгә барса да, ул юлдан чыкмыйбыз диярләрме? Берәү үзен вә бөтен эшен Аллаһка тапшырса, вә һәр эштә яхшылыкта булса, ул кеше һич өзелү ихтималы булмаган таза арканга тотынды, ягъни Коръән хөкемнәре шул таза аркан хөкемендә булып, Коръән белән гамәл кылу гүя шул арканга тотынудыр. Бит һәр эшнең ахыры Аллаһка кайтыр. Берәү Коръәнне инкяр итеп кәфер булса, аның көферлеге сине көендермәсен, аларның кайтачаклары Безгәдер, кылган эшләреннән үзләренә белдерербез һәм җәза кылырбыз. Аллаһ күкрәкләр эчендә ниләр барын белүчедер. Безгә итагать итмәгәннәрне нигъмәтләребездән дөньяда гына файдаландырабыз, соңыннан аларны каты газапка илтербез. Әгәр син алардан җирне вә күкләрне кем халык кылды, дип сорасаң, әлбәттә, әйтерләр: «Аллаһ халык кылды», – дип. «Мактау Аллаһкадыр!» диген. Бәлки аларның**

**күбрәге мактауның Аллаһка тиешле икәнен белмиләр. Җирдә вә күкләрдә булган барча байлык һәм мәхлук Аллаһныкыдыр. Ул – Аллаһ байдыр, һичкемгә мохтаҗ түгелдер, кылган эшләрендә макталуга лаектыр. Әгәр җир йөзендәге агачлар каләмнәр булсалар иде, дәхи бер диңгезгә җиде диңгез кушылып яза торган кара булса иде, шул кара белән Аллаһның сүзләре язылса, яза-яза кара бетәр иде, әмма Аллаһның сүзләре бетмәс иде, Аллаһ көчле вә хөкемчедер».**

«Локман», 31:20-27

Шулай ук «Әнгам» сүрәсенең аятьләрен дә кара: **«Шиксез, Аллаһы Тәгалә вак орлыкларны һәм җимеш төшләрен яручы, ягъни җиргә салган һәр орлыкны үстерүче, Ул үлектән терекне чыгарыр вә теректән үлекне чыгарыр, бу эшләрне эшләүче – Аллаһтыр, Аллаһтан ничек дүнәсез, ягъни Аңа итагать итүне ничек куясыз? Ул таңны булдыручы вә төнне ял итәргә пәрдә кылды һәм кояш белән айны көн хисапларын белергә дип уңай кылды, бу эшләрне кылучы – кодрәт вә белем иясе Аллаһтыр. Янә Ул – Аллаһ, караңгы төннәрдә сахрада вә диңгезләрдә йөргән вакытыгызда юл табар өчен маяк итеп сезнең өчен йолдызларны бар кылды. Белгән кешеләр өчен аятьләребезне ачык бәян кылдык. Аллаһ сезне бер җаннан күбәйтте, сезгә Аллаһ билгеләгән әҗәлегезгә чаклы дөньяда карарланыр урын булыр һәм үлгәннән соң Кыямәт көненә чаклы икенче төрле хәлдә карарланыр урын булыр. Тәхкыйк, аятьләребезне ачык фәһемләп аңлатып сөйләдек, аңлаган кешеләр өчен. Ул, Аллаһ, күктән яңгыр суын иңдерде. Ул су белән һәртөрле үсемлекне җирдән чыгарып үстердек һәм һәр үсә торган табигатьне яшел төстә җирдән чыгардык, алардан берсе өстенә икенчесе тезелеп үскән орлыкларны вә җимешләрне чыгарабыз, янә күп җимешле ботаклары җиргә якынлашкан хөрмә агачларын үстерәбез һәм дә йөзем, зәйтүн, анар бак-**

**чаларын үстерәбез, ул җимешләр төсе вә тәме белән бәгъзеләре бер-берсенә охшаган булыр, әмма бәгъзеләре бер-берсенә охшамаган булыр. Аларның җимешләнгән вә өлгергән вакытларында карагыз! Никадәр гаҗәеп булып җимешләнәләр һәм пешеп өлгерәләр, дөреслектә, ул җимешләрнең шулай өлгерүендә – ышанучы кешеләргә Аллаһы Тәгаләнең кодрәтен белергә дәлилләр бар».**

«Әнгам / Терлек», 6:95-99

4. «Мәккә вәхиләре» шунысы белән дә үзенчәлекле булып тора – анда пәйгамбәрләр һәм аларның кабилә-кавемнәре турында кыйссалар бар. Ә «Мәдинә вәхиләре»ндә пәйгамбәрләр турында хәбәрләр юк, мәгәр «Бәкара» белән «Маидә» сүрәләреннән башка, чөнки боларда Мусаның ﷺ һәм аның халкының тарихы бирелә. Шулай ук, «Гыймран әһеле» һәм «Сафлар» сүрәләреннән башка, чөнки аларда Гайсә ﷺ һәм Муса ﷺ турында кыйссалар китерелә.

Коръәннең «Мәккә вәхиләре» өлешендә пәйгамбәрләргә һәм борынгы халыкларга игътибар бирелүе югарыда әйтеп узган вәхиләрне өлешләп иңдерү тәртибенең хикмәтле бер феномен булуын исбатлый.

Бу тарихи кыйссалар Пәйгамбәребезнең ﷺ һәм мөселманнарның ышанычларын һәм көчләрен ныгытуга ярдәм иттеләр, аларны авыр сынауларда тынычландырдылар. Шулай ук, бу кыйссаларда мөселманнарның дошманнарына карата кисәтүләр һәм нәтиҗәләр ясарлык үтемле гыйбрәтләр дә булды.

Мисал буларак, «Әгъраф», «Юныс», «Һуд» һәм башка сүрәләрне кара. Син аларда тирән нәсыйхәтләр һәм файдалы нәтиҗәләр табарсың һәм Аллаһы Тәгаләнең хаклыкны җиңүгә китерү өчен һәм аны өстенлеккә чыгару өчен мөэминнәргә һәм яхшылык кылучыларга ярдәм итүен, ә аларның дошманнарына – җиңелү китерүен күрерсең.

5. Коръәннең «Мәккә вәхиләре» төркемендә әхлакый нормаларның нигезләре һәм барча заманнарга һәм кешеләргә кагыла торган гомуми иҗтимагый кагыйдәләр аңлатыла. Анда китерелгән әхлакый кыйммәтләр: тугрылык, итагатьлек, туганнар белән аралашу, ата-ананы хөрмәт итү, кунакчыллык, калебнең һәм телнең сафлыгы һ. б. әхлакый сыйфатлар кешеләргә тыныч һәм имин булып исламча яшәргә ярдәм итәләр. Коръән үзенең гүзәл теле белән бу кыйммәтләрнең әһәмиятен һәм асылын аңлатып күрсәтте һәм аларны кешеләрнең йөрәкләренә дә сеңдерде һәм, киресенчә, аларда начар сыйфатларга карата: имансызлыкка, намуссызлыкка, гаделсезлеккә, кыз балаларны үтерүгә һәм, гомумән – кеше үтерүгә, зиначылыкка карата нәфрәт уятты.

Менә бу «Исра» сүрәсендәге ун әхлакый кагыйдәне васыять иткән аятьләргә кара: **«Аллаһ хөкем итте вә әмер бирде фәкать Аллаһка гына гыйбадәт кылырга һәм ата-анага изгелек итәргә. Әгәр син исән чакта аларның берсе яки икесе дә картлыкка ирешсәләр, син аларга «уф» та димә, вә каһәрләмә, кәефләрен бозма, бәлки аларга һәрвакыт йомшак вә мөлаем сүзләр сөйлә! Вә аларга шәфкать итеп, рәхим канатларыңны җәй! Вә әйт: «Ий, Раббым, алар мине кечкенә чагымда мәрхәмәт белән үстергән кебек, Син дә аларга дөньяда һәм ахирәттә шәфкать кыл!» Күңелләрегездә нинди ниятләр вә теләкләр барын Аллаһ белә, әгәр күңелләрегез яхшы булса, Аллаһ, әлбәттә, тәүбә итеп төзәлгән кешеләрне гафу итәдер. Дәхи якын кардәшләрнең вә мескеннәрнең вә мосафирларның хакларын бир! Әмма малыңны тиешсез җирләргә исраф итмә! Тиешсез урынга малны исраф итүчеләр, әлбәттә, шайтан кардәшләредер, шайтан Раббысына кәфер булды. Мохтаҗ кешеләр килеп синнән ярдәм сораганда синең бирергә һичнәрсәң булмаса, Раббым рәхмәт итеп нигъмәт бирсә, сезгә бирер идем, дип, алардан йөз чөерсәң, ул вакытта йомшак сүзләр әйтеп күңелләрен табарга тырыш! Мохтаҗларга сәдака**

**бирүдә кулыңны муеныңа баглап куйма, сараннар кыяфәтендә шулай ук кулыңны бөтенләй ачып җибәрмә, ягъни үзеңә калдырмыйча биреп бетермә, әгәр киемеңә хәтле биреп бетерсәң, ул вакытта ялангач хәлендә үзеңне шелтәләп, хәсрәтләнеп утырырсың. Тәхкыйк, Раббың теләгән кешесенә киң ризык биреп, бай кылыр вә теләгән кешесен фәкыйрь кылыр, әлбәттә, Ул бәндәләрен күрә вә хәлләрен беләдер. Шуның өчен фәкыйрь кеше хәсрәтләнмәсен, сабыр итсен! Фәкыйрь булудан куркып, балаларыгызны үтермәгез! Балаларыгызны да үзегезне дә Без ризыкландырабыз, әлбәттә, үз балаларын үтерүләре гафу ителми торган хатадыр, зур гөнаһтыр. Зинага якын да бармагыз, аның сәбәпләреннән дә ерак булыгыз, чөнки ул пычрак эш, вә бик яман кабахәт юлдыр. Аллаһ үтерүне хәрам кылган җанны үтермәгез, мәгәр үтерергә хакыгыз булса гына. Берәү хаксыз золым белән үтерелсә, үтерелгән кешенең вәлисенә (якынына) ихтыяр бирдек, теләсә үтерүчене үтерсен, теләсә үтермичә мал алсын, теләсә гафу итсен! Ләкин бу эшләрдә чиктән үтмәсен, бер кеше урынына ике кешене үтермәсен, яки мал алса, тиешлесеннән артык алмасын! Тәхкыйк, ул варис Аллаһтан ярдәм бирелмеш булды. Ятимнәр малына да якын бармагыз, ягъни аларның малыннан аз гына да файдаланмагыз, мәгәр ятимгә файда итү юлы белән, аның малына катнашыгыз, яки ятим тәмам үсеп акылга утырганчы аның малына якын бармагыз! Вә гаһедләрегезне һәм вәгъдәләрегезне үтәгез, бозмагыз! Чөнки гаһедләрен бозган кешеләр Кыямәт көнне соралачаклардыр. Дәхи үлчәгәндә үлчәүләрегез дөрес булсын, тигез үлчәгез вә дөрес үлчи торган гадел мизаннар белән үлчәгез! Гадел үлчәсәгез, үзегезгә хәерледер вә ахыры да күркәм булыр. Вә дәлилең, белемең булмаган нәрсәгә иярмә, ягъни дәлилсез гамәл дә кылма, хөкем дә итмә, фәтва да бирмә! Аллаһ биргән колак, күз, күңел – боларның һәрберсеннән Кыямәт көнне сорау булыр, аларны саваплы урыннарга гына кул-**

**ланыгыз! Җир өстендә зураеп күкрәк киереп йөрмә! Чөнки син никадәр зурайсаң да, җирне яру хәлеңнән килмәс, һәм никадәр зурайсаң да, таулар хәтле зурая алмассың! Югарыда Аллаһ тыйган эшләрне эшләүче кеше явызлыгы белән Аллаһ хозурында яман кеше саналды. Ошбу хөкемнәр Аллаһның хикмәтеннән сиңа вәхи ителгән хөкемнәрдер, хикмәт Аллаһ иңдергән Коръәндәдер. Аллаһ янына тагын бер нәрсәне Аллаһ итеп алма! Әгәр ул эшне эшләсәң, Аллаһның рәхмәтеннән киселгән булырсың һәм шелтәләнгән хәлдә җәһәннәмгә ташланырсың».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:23-39

*(Дәвамы бар)*

*Нуретдин Гыйтырның*

*«Коръән турындагы фәннәр» китабыннан*

# Хәнәфи мәзһәбенең төп китаплары

Имам Әбү Хәнифәнең гакыйдә буенча «Әл-Фикһ әл-әкбәр» дип аталган һәм башка гыйльми әсәрләре бар. Фикһ мәсьәләләре буенча хезмәтләр калдырмый. Аның бар карарларын шәкертләренең берсе Мөхәммәд ибн Хәсән Әш-Шәйбәни туплый.

Ул түбәндәге хезмәтләрнең авторы булып санала:

– «Әл-Фикһ әл-әкбәр»;

– «Әл-Фикһ әл-әбсәт»;

– «Әр-Рисәлә»;

– «Васыййәт» (улы Хәммәдкә һәм Әбү Йосыфка);

– «Касыйдә Ногмания»;

– «Мәгърифәт әл-мәзәһиб»;

– «Әл-Муснад» (хәдисләр җыентыгы).

Әбү Йосыф (Ягъкуб ибн Ибраһим Әл-Әнсари) һиҗри буенча 113 елда туа. Башта ул Ибн Әби Ләйләдән дәресләр ала, соңрак Әбү Хәнифәдә укый башлый, һәм аның вафатына кадәр дәресләрен калдырмый. Кыяс һәм мөстәкыйль фикерләү яклы булу белән беррәттән, ул хәдисләр гыйлемен дә яхшы белгән, ә аны Мәдинәдә имам Мәликтән өйрәнгән. Шул рәвешле, ул фикерләрен хәдисләр белән ныгытыкан. Өч хәлиф – Мәхди, Һади һәм Харун Рәшид хакимлек иткән чорда ул казый вазифасын үтәгән. Әбү Йосыфның дәүләт эшлеклесе булуы мәзһәбнең гамәли өлкәдә үсешенә тәэсир итә.

Әбү Йосыф авырган вакытта, Әбү Хәнифә аның хәлен белешергә килә һәм аның турында: «Бу егет үлсә, бу бик үкенечле булачак. Ул җир йөзендәге иң галим кеше», – дип әйтә. Яхъя ибн Мәгыйн аның турында: «Иҗтиһад кешеләре арасында мин хәдисләрне Әбү Йосыфтан да яхшырак белгән кешене күрмәдем», – ди. Әбү Йосыф һиҗри буенча 182 елда вафат була.

## «Китаб әл-әсәр»

Бу хезмәтне Әбү Йосыфның улы Йосыф үзенең әтисеннән, ә әтисе Әбү Хәнифәдән тапшыра.

«Ихтиләфү Әбү Хәнифә вә Ибн Әби Ләйлә». Бу хезмәттә Әбү Йосыф Әбү Хәнифә белән казый Ибн Әби Ләйлә (һиҗри буенча 148 елда вафат) арасындагы бөтен каршылыкларны чагылдыра. Монда Әбү Хәнифә карашлары яклана. Әбү Йосыфның бу хезмәтен Мөхәммәд ибн Хәсән Әш-Шәйбәни тапшыра. Ул имам Шәфигыйның «Әл-Өмм» дип аталган китабының ахыргы өлешендә искә алына.

## «Әр-радд галә сийәрил-Әүзагый»

Бу әһәмиятле хезмәттә сугыш вакытында мөселманнар белән мөселман булмаганнар арасындагы мөнәсәбәтләр һәм сугыш җиһады мәсьәләләренә караган Әл-Әүзагый белән башка галимнәр арасындагы бәхәсләр чагылыш таба. Монда Әбү Йосыф гыйраклыларның фикерләрен хуплап, Әл-Әүзагыйның карашларын кире кага.

## «Китаб әл-хәраҗ»

Бу бәяләп бетергесез хезмәттә Әбү Йосыф Ислам дәүләтенең финанс өлкәсе өчен үзгәрешсез һәм катгый тәртипне билгеләгән... 

Чыганакларда Әбү Йосыфның түбәндәге хезмәтләр авторы булуы искә алына:

«Әдәб әл-кады». Кәтиб Чәләби һәм башка кайбер авторлар тарафыннан искә алына.

«Әл-мәхариҗ». Заһид Әл-Кәүсәри фикеренчә, Мөхәммәд ибн Хәсән исеменнән чыккан бу китап, дөреслектә, Әбү Йосыфның иҗат җимеше.

Моннан тыш, аңа түбәндәге хезмәтләр дә карый: «Мәбсут», «Китаб әл-җәвәмигъ», «Китаб әр-радд галә Мәлик ибн Әнәс», «Китаб ихтиләф әл-әмсар», «Китаб әл-әмәли», «Китаб ән-нәвәдир», «Муснад әл-имам Әбү Йосыф».

## Имам Мөхәммәд ибн Хәсән ибн Фәркад Әш-Шәйбәни

Ул һиҗри буенча 132 елда Вәситәдә туа, Куфәдә үсә. Башта Әбү Хәнифәдә укый. Әбү Хәнифәдән соң Әбү Йосыфның гыйльми төркеменә кушыла һәм фикһта зур нәтиҗәләргә ирешә. Әбү Йосыфта алган сабакларына өстәмә рәвештә ул Мисгар ибн Кидам, Мәлик ибн Мөгаввәл, Гомәр ибн Зарр Әл-Хәмәдәни, Суфьян Әс-Сәүри, Әүзагый кебек галимнәрдән дәрес ала. Аннан соң өч ел дәвамында ул имам Мәлик ибн Әнәстә хәдисләр һәм фикһ өйрәнә һәм аның «Мөвәттә»сенең иң билгеле тапшыручыларының берсе була. Шулай ук ул тел гыйлеме һәм әдәбият өлкәсендә дә тирән гыйлемнәргә ия була.

Әбү Йосыф вафатыннан соң аңа Гыйракта фикһны җитәкләүне тапшыралар. Имам Мөхәммәдтә гыйлем алган күп кенә шәкертләр күренекле галимнәр була. Ул үзе дә бик күп китаплар язган. Киләсе буыннарга Гыйрак фикһын җиткерүче булып та нәкъ ул тора. Шәфигый, Әбү Гобәйд Әл-Касим ибн Сәлләм, Һишам ибн Гобәйдүллаһ Рази, Гали ибн Мөслим Туси, Яхъя ибн Мәгыйн, Мөхәммәд ибн Сәмәга һәм башка бик күп мәшһүр галимнәр аннан риваятьләр тапшырган.

Әбү Гобәйд Мөхәммәд турында болай дигән: «Мин Аллаһ китабын Мөхәммәд ибн Хәсәннән дә яхшырак белүче беркемне дә күргәнем булмады». Шәфигый исә болай дип әйткән: «Имам Мөхәммәднең сүзгә оста-

лыгыннан чыгып, мин хәтта Коръәнне аның шивәсендә[1] иңдерелгән, дип әйтә алыр идем».

Имам Мөхәммәд һиҗри буенча 189 елда Рий шәһәрендә вафат була. Аллаһ аңа рәхмәтле булсын.

Беренче чор факиһлары арасында имам Мөхәммәд бик күп әсәрләр иҗат иткән авторлар исемлеген җитәкли. Аларның иң әһәмиятлеләре безнең көнгә кадәр сакланып килгән.

Имам Мөхәммәднең бер генә әсәренең дә язылган вакыты төгәл билгеле түгел. Бары тик кайсы әсәрләре алданрак, кайсылар соңрак язылганы мәгълүм.

## «Әл-Асыл» («Нигез»)

Бу әсәр шулай ук «Әл-Мәбсүт» («Тәфсилле аңлатма») исеме астында билгеле. Имам Мөхәммәд үзе бу әсәргә сылтама ясаганда, шул атамасын кулланган. Багдадка күчеп киткәнче, әле Күфәдә булганда ук, имам Мөхәммәд әсәрен шәкертләренә әйтеп яздырган. Бу аның иң күләмле һәм әһәмиятле әсәре. Күпмедер дәрәҗәдә ул аның башка әсәрләренең, бигрәк тә «Заһирар-ривәя»гә кергәннәренең, нигезе булып тора. Бу китапның бездә булган басмасына кульязмаларда булмаган «Китаб әл-мәнәсик» («Хаҗ китабы») кертелгән. Ул Хәким Шәһиднең (һиҗри буенча 334 елда вафат) «Мохтасар»ыннан алынып, Әбү Вафа Әл-Әфгани тарафыннан китапка өстәлмә рәвешендә кертелгән була.

Бу әсәр имам Мөхәммәднең күп кенә шәкертләре тарафыннан тапшырыла. Иң билгеле нөсхә – Җүзҗәни тапшырганы. Бүгенге көндә таралган «Әл-Асыл»ның прототибы ул тапшырганга һәм өлешчә генә Әбү Хәфс Әл-Кәбир тапшырганга барып тоташа. Имам Мөхәммәднең «Әл-Асыл»ны «Китаб әс-саләт», «Китаб әл-бәйгъ» кебек аерым китаплар рәвешендә иҗат итүе, һәм аннан соң гына аларны бер әсәр итеп туплавы риваять

[1] Шивә – сөйләш.

ителә. Кайбер авторларның аның «Китаб әс-саләт» («Намаз китабы»), «Китаб әз-зәкәт» («Зәкәт китабы»), «Китабән-никах» («Никах китабы») кебек хезмәтләре барлыгын искә алулары шуңа бәйле. Бу очракта күз уңында «Әл-Асыл»ның «китаб» дип аталган зур бүлекләре тотылган.

«Әл-Асыл»ның беренче дүрт томында темалар сорау-җавап формасында, диалог рәвешендә карала. Шушындый рәвештә бу әсәр фәтвалар китабына охшаш. Кем соравы һәм кемнең җавап бирүе буенча төрле фикерләр бар. «Әл-Асыл» имам Мөхәммәдкә шәкертләре биргән сораулардан һәм имамның аларга җавапларыннан төзелгәндер, дип фаразларга мөмкин. Имам Мөхәммәднең җавабыннан соң шәкертләре еш кына: «Ник сез мондый хөкем бирдегез?» – дип сорый торган булганнар. Һәм ул ник нәкъ шундый карар кабул итүен аңлатып киткән.

«Әл-Асыл»ның теле «Әл-Җәмигъ әс-сәгыйр» һәм бигрәк тә «Әл-Җәмигъ әл-кәбир» белән чагыштырганда гадирәк һәм күпкә аңлаешлырак.

Әс-Сәрахси (һиҗри буенча 483 елда вафат) бу әсәрнең язылуының әһәмиятлелеген ассызыклап, имам Мөхәммәднең «Әл-Асыл» әсәре үзенчәлекле ысул белән язылган, һәм бу аны башка фикһ китапларыннан аерып тора, дип әйткән. Бу ысул күпләр тарафыннан кабул ителгән һәм аннан соң да киң кулланылган. Нәтиҗәдә бу фикһ китапларының без күнеккән стиле барлыкка килүгә китергән. Икенче атамасы – «Әл-Мәбсүт» («Тәфсилле аңлатма») – хезмәтнең үз эченә фикһның бар мәсьәләләрен һәм темаларын алуын күрсәтә. Аеруча шуны да ассызыкларга кирәк: имам Мөхәммәдтән соң хәнәфи фикһы турында язучы бар галимнәр дә бу хезмәткә таянган. Хәнәфиләр фикеренчә, бу әсәрне тиешенчә үзләштермичә, галим иҗтиһад дәрәҗәсенә ирешә алмаган.

*(Дәвамы бар)*

*Камил хәзрәт Сәмигуллинның*
*«Введение в ханафитский фикх» китабыннан*
*Рәмзилә Шафикова тәрҗемәсе*

# Мирас

# Милли матбугатыбыз

(Дәвамы, башы журналның 18 санында)

## Казандагы гарәби хәреф илә матбага

Мәктәпләр, мөгаллимнәр вә укыр өчен китаплар булынмадыгы сәбәбенән Казан шәһәре Русия кулына төштеге көннән унсигезенче гасыр милади башына кадәр әһеле ислам тәмам каралып җитмеш иде. Һәр никадәр бәгъзе адәмнәр Дагыстан тарафыннан вә бәгъзе берләре Бохара вилайәтләрендә тәхмил итеп [укып] кайттырлар вә монда кайттыклары соң, мәдрәсә ачып дәрес илә мәшгуль булырлар исә дә, болар бик аз вә дәресләре асылсыз булдыгыннан халыкның хаҗәтен тәэмин итәр мәртәбәдә түгел иде. Бәлки дәресләр хөласә [йомгак] кеби бәгъзе бер китаплар укытмактан гыйбарәт булмыштыр. Өязләр түгел, хәтта бик күп губерналарда мөдәррис вә мәктәп исемендә бер шәй булынмас иде. Бәгъзе карьяләрдә меллалар вә боларның хатыннары бала укытып шөгыйльләнер булсалар да, боларның күбрәк дәресләре иман кәлимәләре вә намаз ниятләре (күңел сабагы) укытмактан гыйбарәт булмыштыр.

Мөселманнарның һәр шәйдән мәшәкать чикмәкләре китап юклыгы җәһәтеннән булмыштыр. Әлифбаларны такталарга язып укытырга мәҗбүр булмышлардыр. Коръән шәрифләрне дә каләм илә язып укымышлардыр.

Фәкать бөйлә шәйләр бары тик бай вә мелла балаларына махсус бер шәй кеби булып, гавам баласы исә гомумият илә бөтенләй укымактан да буш тормыштыр.

Ошбу хәлләреннән гаҗиз булып мөселманнар император Александр беренчегә риҗанамә [гариза] күндереп, Казан матбагаларында Коръән вә бәгъзе әсәрләрнең басылмакларын сорадылар. Шуңа күрә унсигезенче гасыр азагында Казан шәһәрендә гимназия хозурында булган матбагага

гарәби хәрефләр китерелеп, ислам әсәрләре табгы итәргә фәрман падиша садир [бар] булды. Әһеле ислам ошбу рөхсәтне ганимәт [бүләк] беләрәк, үзләренең хираҗәтләре [мадди ярдәмнәре] илә мохтаҗ булган әсәрләрне табгы иттерергә башладылар.

Казан шәһәрендә дарелфөнүн (университет) хозурында булган матбага вә шул матбагада 1800 елдан башлап 1899 ел башына кадәр басылып чыкмыш әсәрләр хакында профессор Н. Ф. Кононов тарафыннан бер фиһрист китабы [библиографик күрсәткеч] басылып чыкмыштыр.

Профессор Кононов дияр: «Казан шәһәрендә гимназия йортында ачылмыш матбага өчен Петербургта Сенат матбагасы тарафынан хәрефләр вә ике данә станок күндерелде. Вә матбага да «Азиатский» исеме илә ачылды. Мәзкүр матбага 1806 елдан прапорщик Габделгазиз Бурнашев исемендә бер мөселман тасрифына бирелде. Ләкин мәзкүр Бурнашев ошбу ел, 26 ноябрьдә истигъфаэ итеп [эшеннән азат ителеп], урыныннан чыкты. Моннан соң бәһане ваклап түләмәк шарты илә мәзкүр матбага Казан сәүдәгәрләре Апанаев[1] карамагына бирмештер. 1806 елдан башлап 1815 елга кадәр ошбу матбагага һәр ел ике мең сум бакыр хәзинәдән ярдәм бирелеп тормыштыр. Моннан соң үзенең табышы чыгышына җитәрлек булып бармыштыр. 1842 ел, 24 августында Казан шәһәрендә булган олуг янгын вакытында бу матбага да янмыш вә шулвакыт хәзинә өч мең сум иганә бирмештер».

1828 ел ахырында «Азия матбагасы» университет матбагасы илә кушылды вә һәмишә әүвәлге рәвештә ислам әсәрләре басып торды. Университет матбагасы илә кушылдыгы соң да, үзенең «Азиатский» исемен беркадәр вакыт сакламыш булса кирәк. Иске бер Коръән шәриф ахырында бөйлә рәвештә басылдыгы күрелде:

1 Ошбу Апанаевның ни исемдә вә кем углы идеге хакында мәгълүмат тапмадык. Фәкать ошбу ел Казанда нәшер булынмыш «Идел» мәҗмугасында (26 нчы бит) Гали Йосыф углы дип күрсәтелмештер.

«Бу Кәляме шәриф Казанның почетный гражданин первый гильдии сәүдәгәр Габдулла Мөхәммәдрәхим углы Юнысовның хираҗәте илә мөселманнар файдасы өчен укыганнардан дога хәер өмид итеп Казан университетларының «Азиатский табгыханә»сендә хәзинәлектән (?)[1] басма булынмыштыр. Шәһре Казанда 1839 нчы сәнәдә румя илә».

1857 елларда Казанда Кукубин исемендә икенче бер матбага ачылды вә 1870 елларда дәхи башка матбагалар мәйданга килмештер. Рәхмәтулла Әмирханов[2] исемендә бер зат тарафыннан ташбасмаханә (литография) ачылдыгы басылмыш булган рисаләләрдән мәгълүм булыр.

1813 елда Казан шәһәрендә «Библия җәмгыяте» («Библейское общество») ачылдыгы соң, мөселман әсәрләре аз басыла башлар, мәзкүр җәмгыять исә моның зарарына һәртөрле чаралар табар дип зан ителер булды. Вакыйган [чынлыкта] җәмгыять үзенең мәсләгендә кямил гайрәт илә дәвам итте, халыклар зан әйләдекләреннән [уйлаганнарыннан] артык чаралар мәйданга китерде, фәкать ислам әсәрләре генә әүвәлгесе кеби, бәлки әүвәлгедән дә зиядә [артык] сурәттә басылыр булды вә бик ерак җирләргә җибәрелеп таралыр иде.

Казанда ачылмыш «Азиатский матбага» вә аннан соң ачылмыш Кукубин матбагасы сәбәбеннән мөселманнар арасында «китап сәүдәсе» исемендә яңа бер сәүдә мәйданга чыкты.

Мөселманнар үз хираҗәтләре [акчалары] илә Коръән, Һәфтияк шәриф вә башка әсәрләр бастырырлар вә боларны да Нижгород, Эрбет кеби бөек базарларга вә ерак шәһәрләргә җибәреп саттырырлар иде.

1 Сорау билгесе авторныкы. – Төз.

2 Рәхмәтулла Әмирханов (1805–1876) – Казан шәһәре татар ратушасында тәрҗемәче булып эшли. Мәгърифәтче, гарәп һәм фарсы телләрен белү өстенә, рус телендә дә иркен аралашкан. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасының беренче басмасын нәшер итә. 1841 елда аның тарафыннан 40 елга исәпләнеп төзелгән «Горрәлек» дип аталган беренче татар басма календаре дөнья күрә. Шулай ук мәгърифәтче – «Зөбдәтен-нәсаих» («Иң яхшы киңәшләр», 1849), «Гакаиде мәнзумә» («Дини ышану шигырьләре», 1856) исемле китаплар авторы. – Төз.

Аз вакытлар эчендә Казан басмасы буларак ислам әсәрләре Сибирия, Кырым, Кавказ, Хива, Бохара, Сәмәрканд, Алма-Ата, Ташкент кеби ерак вилайәтләргә тарала башлады.

Ошбу китап сәүдәсе Русия өчен мадди вә мәгънәви бөек файдалар бирмештер. Русия мәмләкәте эчендә Коръән вә дини әсәрләр бастырдыгын күрдекләрендә гомумә мәшрикъ мөселманнары Русиягә дуслык күзе илә карый башламышлар вә моның илә бәрабәр ошбу әсәрләр бәрабәренә Русия дәүләтенә кәллиятле [күп күләмдә] акча вә мал бирер булмышлардыр.

Оренбург собраниесе архивында Дахилия [эчке эшләр] министры тарафыннан Оренбург собраниесе исеменә язылмыш рәсми бер кәгазь күрдем. Мәзкүр кәгазь илә министр Казанда басылачак Коръән шәрифнең эшләрен ашыктырырга боерадыр, әгәр дә Коръән вә Һәфтиякләр Азия тарафына китәчәк кәрваннардан калсалар, Русия өчен зарар булы турында бер сәбәп күрсәтәдер.

Китабе Коръән сәүдәсе Русиядә мөселманнар утырмыш вилайәтләрдә мәшһүр базар вә ярминкәләр булыныр иде. Моның илә генә канәгать ителмәде, күтәреп сатып йөрүчеләр һәрбер олуг вә кечек мөселман авылларына кадәр йөреп чыгарлар иде. Тимер юллар вә пароходлар юк, сәфәр сәбәпләре җиңел түгел вакытларда хәтта урман вә сазлык араларында булган карьяләрдә дә биш-ун данә Коръән шәриф булынмасына ошбу күтәреп йөрүчеләр сәбәп булмышлардыр.

## Әдәбиятыбызның нигезләре

«Әдәбиятыбызның нигезләре» бәхәсе «Милли матбугатыбыз»да түгел, бәлки «әдәбиятыбыз» бәхәсендә сөйләнергә тиешле булса да, кирәге чыктыгы илә бу җирдә һәм бераз сөйләп китәргә тиешледер.

Дөньяның сер вә хәрәкәте, тәдриҗ [эволюция] илә тәкәммел [камилләшү] кагыйдәсенә мөбәни булдыгыннан [буйсынганлыктан] һәр кавемнең әдәбиятлары хорафат вә әүһам [бозык уй] илә капма-каршы булдыгы беркадәр мәгълүмдер. Хәтта бу көндә иң бөек бер урын тотмыш вә гали фәннәр эченә кермеш тарих гыйлеме дә күбрәк әүһам арасыннан интихаб ителеп [сайланып алынып], ике сакыймнан [бозыктан] бер мөстәкыйм [дөреслек] чыгармак ысулына бинаән ителмештер [нигезләнгән]. Ошбу сәбәптән милли матбугатыбызның иң элек мәртәбә мәйданга чыкмыш әсәрләрен әдәби җәһәттән бу көнге хәлләрдән бик түбән хисап итәргә тиешле.

Башка кавемнәрнең дә әдәбият нигезләре һәм безгә күрә [бездәге кебек] «Кисекбаш», «Мәликә» кеби әсәрләр булдыгын хәтерләп, безнең бу җирдә исемнәрен яд итәчәк [искә алачак] рисаләләрдән тәгаҗҗеб итмәсләр [гаҗәпләнмәсләр]. Бөек биналарның нигезләренә һәрвакыт вак ташлар салырлар.

Әдәбиятыбызның иң элек басылып чыкмыш нигезләре ошбу әсәрләр була белер: 1) Әлифба иман шарты [белән]. Моның сахибе Мортаза бине Котлыгыш, әгәр дә ул түгел исә, кем булса да аның шәкертләреннән берәр зат булыр; 2) «Пиргали [Пиргули] васыяте». Мөәллифе Төркия галимнәреннән Мөхәммәд Пиргали. Һәр бите 17 юлдан 171 бит буларак һәфтияк шәриф кыйтгасында [кисәгендә] яшел кәгазь белән басылмыштыр; 3) «Сөбател-гаҗизин». Мәшһүр бер әсәрдер. 4) «Фәүзен-нәҗат». Фарсычадан тәрҗемә ителмеш манзум бер китаптыр. 5) «Сәйфелмөлек». Хыялый вә манзум бер әсәр. 6) «Шәҗәрәи төрек»[1]. Хива ханы Әбелгазый [Баһадирхан] әсәре булып, граф Н. П. Румянцев тарафыннан нәшер булынмыштыр. Ошбу әсәрләрдән әүвәлге дүртесе 1802 елда, бишесе 1825 елда басылмыштыр. Моннан соңнарында еллары куелыр. 7) «Кыйссаи Йосыф с.г.в.». Манзум булган ошбу әсәр хакында «Мәшһүр хатыннар»

[1] «Төрки халыкларның нәсел-ырулары язуы». – Төз.

нам [исемле] китапта (307–308 нче битләр): «Заныбызга күрә, Болгарда ерак бабаларыбыз әсәрләреннәндер. Эчендә булган бәгъзе бер кәлимә вә лөгатьләр болай уйларга сәбәп бирәдер. Низамы [шигырь төзелеше] гаять тә төзек, лөгате ачык вә фәсыйх [матур] булып, өслүбе һәм мәргуб [әйбәт] вә әсәрледер», – димеш идек. Ошбуны укыдыгында фазыйль [галим] мөхтәрәм Галимҗан хәзрәт [Баруди] әсхәбеннән булган Шәһәр әфәнде[1] мәзкүр китапның иске язма нөсхәсенең ахырыннан ике бит кадәр шәй күчереп җибәрде. Мәгәр дә басма нөсхәләрдә ахырыннан ике бит кадәр җирен ташламышлар, имеш.

Ошбу ташланмыш җирдә әсәр сахибенең [язучының] Гали исемендә идеке вә китапны тарих алты йөз утызынчы ел рәҗәб аеның 30 нчы көнендә тәмам иттеге бәян ителмештер.

Мәзкүр тарих Болгарда ислам хөкүмәте көчле булдыгы вакытларга тугры киләдер. Фәкать болгарилар әсәремедер, юкса Төркестан тарафында язылмышмыдыр? Хакыйкатьне исә ачык Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре белер. Әгәр дә исеме илә бәрабәр назыйм [шагыйрь] үзенең кавем-кабиләсен вә мәнсуб булдыгы [яшәгән] җир вә мәмләкәтен язмыш булса иде, әлбәттә, гүзәл итмеш булыр иде. Фәкать, ни өчендер, саранлык итмештер[2]. Бу китап 1839 да басылмыштыр. 8) «Горрәлек»[3]. Рәхмәтулла Әмирханов әсәре булып, кырык ел мөддәт [вакыт] өчен тәртип ителмештер. 1841 ел басылмыш. 9) «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви». Сахибенең тәрҗемәи

---

[1] Шәһәр Шәрәф (1879-1938) – «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем ала, шунда ук гарәп әдәбияты, тел һәм ислам дине философиясе, тарих һәм шәригать кануннары фәннәрен укыта. – Төз.

[2] Шәһәр әфәнде хәбәренә күрә, ошбу язма нөсхә ахырында язучы болай дип язган: «Китап тәмам булды, кятиб фәкыйрь Сәлим бине Рәхимколый (Асар. Җ. 1, 149 бит). Ли әҗли мелла Ибраһим 1814 ел, 27 март көнендә Уфа шәһәрендә».
Бу китапның сахибе ул Ибраһим,
Атасы таулы Газиз иде Хәлим.
Гөнаһларын гафу кылсын Кәрим рәхим,
Ахирәттә җәннәт рузый кылсын имди.

[3] Горрәлек – табель-календарь. – Төз.

хәле «Асар»да мәзкүрдер[1]. 10) «Пәнднамә». Хәмид Бихәд тәрҗемәсе. 11) «Ләтаифе Хуҗа Насретдин». 12) «Мөхәммәдия». Нашире Казыйм бәк; 13) «Мәгърифәтнамә». Ибраһим Хаккый әсәре. 14) «Мөһиммәтел-мөслимин». Әхиядән тәрҗемә. Боларның һәрбере 1845 тә басылмыштыр. 15) «Бәдәвам». Мәшһүр бер әсәр. 16) «Хәким ата». 17) «Бакырган». 18) «Кисекбаш». 19) «Мәликә». Болар 1846 елларда басылмыштыр. 20) «Ахырзаман» («Тәкый гаҗәп»). 21) «Тәгъбирнамә». Янабигъ тәрҗемәсе. Болар 1847 дә басылмыштыр. 22) «Башмак шәриф хасиятләре». 23) «Мәдхе имам әгъзам» («Алма китабы»). 24) «Кодехен-нур вә тәфсире әбҗәд». 25) «Кыйссаи Сөләйман». Болар 1848 дә басылмышлар. 26) «Иман мәгънәсе». 27) «Могъҗизатен-нәби». Фарсычадан тәрҗемә. 28) «Мәүлед шәриф». Болар 1849 да. 29) «Рисаләи газизә». Мәшһүр бер әсәр булып, сахибе «Асар»да мәзкүрдер[2]. 1850 ел басылмыш. 30) «Тутыйнамә». 31) «Рисаләи нурнамә». 1851 дә басылмыш. 32) «Нәсыйхәтәс-салихин». 33) «Сигез җәннәт мисалы». 1852 дә. 34) «Фәзаилеш-шөһүр». Сахибенең тәрҗемәсе «Асар»да Җамалетдин исеме астында мәзкүрдер[3].

## Элек басмалар хакында иҗмали хисап

1801 ел ахырыннан игътибарга өч ел эчендә «Азиатский табгыханә»дә 11000 данә әлифба (Иман шарты), 7000 данә һәфтияк, 3000 данә Коръән шәриф вә 10200 данә башка китаплар басылмыштыр. Фәкать ошбу китаплар арасында мөстәшәрикъләр тарафыннан бастырылмыш беркадәр гарәби әсәрләр дә булыр.

---

1 Суфи шагыйрь Әбелмәних Каргалый турында китап. – Төз.

2 Сүз тарихчы һәм язучы Таҗетдин Ялчыгол (1768–1838) турында бара. – Төз.

3 Сүз Мамадыш өязе Шәдче авылы имамы Җамалетдин бине Бикәш турында бара. Р. Фәхреддин язуынча, аның «Фазилеш-шөһүр» китабы Казанда һәр елны бер-ике тапкыр һәм һәр чыкканда берничә мең данә белән дөнья күргән. Китап мәдрәсәләрдә дәреслек буларак кулланылган. – Төз.

1855 елдан игътибарга 1864 елга кадәр, ягъни ун ел мөддәтендә Казанда дарелфөнүн матбагасында 1084320 данә һәфтияк, 19000 Коръән шәриф басылган. Кукубин матбагасында басылмыш әсәрләр бу хисапка дахил түгелдер.

## Кәнди ислам матбагаларыбыздан риҗа [үтенеч]

Русиядә гарәби хәреф илә матбагалар ачылдыгы соң басылмыш әсәрләр хакында кулыбызда мөфассәл сурәт илә [кыскача] мәгълүмат юктыр. «Әсам китап» [китаплар исемлеге, ягъни библиография] рәвешендә бер әсәр мәйданга китерелмәде. Безләр дә җәдид вә бөек эшләргә икъдам [тырышлык кую] булмадыгыннан, бәлки бере бер эш башласа, сарык кабиленнән бөтенесе шуның артынча йөрергә гадәтләндекләреннән күп әһәмиятле шәйләр мөһмәл калыр [ташланыр]. Бездә эшне азагына кадәр башкару гадәте юк. Әлифбалар, тәҗвидләр, җәгърафияләр [географияләр] инде беркадәр булды, ихтимал ки, болардан соң башка эшләргә дә кул сузучылар булыр. Милли эшләребезне дә мөстәшарикъләргә [көнчыгыш белгечләренә] тапшырып: «Алар эшләсеннәр», – дип тормаклыгыбыз, әлбәттә, тиеш түгелдер.

Галибәлек [бөеклек], шаулап вә шалтырап йөрмәклекне һич сөймәдегем вә байгыш мәгыйшәтне Мисыр хөкемдарлыгына фида итмәячәгем хәлдә халыкларның юбилейлар итеп йөрдекләре гаять хушыма китмәктәдер. Игътикадыма күрә, юбилей илә сәяхәтнамәләр тарих күперләренең кадакларыдыр. Юбилейлар сәбәбеннән тарихлар яңарыр, мәхкәмләшер.

Ибне Фазлан сәяхәтнамәсе Болгар тарихыбыз өчен [...] бөек сәрмая [табыш] булмышлардыр.

Юбилейлар әксәр [күпчелек] бер кемсәгә гаид булыр исә дә, шул хакта язылмыш хисапнамәдә мөнәсәбәт башка шәйләрдән дә күп хәбәрләр

булыр. Әгәр дә иң элек Коръән шәриф вә дини китаплар басылдыгы мөнәсәбәт илә Русия мөселманнары 25 вә 50 еллык юбилей ясап, шул хакта рисаләләр нәшер итмеш булсалар иде, матбугатыбызның тарихы бу көндә үз-үзеннән мәйданга килмеш булыр иде.

Һәрхәлдә, бу көнге ислам матбагалары һәр ун елда булмаса да, һәр егерме елда бер дәфга үзләренең басып чыгармыш әсәрләре хакында мөфассәл [кыскача] сурәттә хисап дәфтәре нәшер итмәкләре ләземдер. Әгәр, дә хакыйкать хәлдә, болар милләт хезмәте итмәк касды [нияте] илә эшкә керешмеш булсалар, бу тугрыда исля мөсаһәлә итмәсләр [ягъни игътибар итәрләр].

Бу хезмәтнең нәүбәте [башы] иң элек мөхтәрәм «Тәрҗеман» матбагасына вә аннан соң Петербургта Ильяс мирза Бораганский[1] вә аннан соң да Казан шәһәрендә борадәрән Кәримовлар матбагасына[2] вә аның бәгъдендә [аннан соң] Оренбург шәһәрендә «Кәримов, Хөсәенов» матбагасына[3] килсә кирәк.

Шура. – 1908. – №10. – Б. 324–326; №8. – Б. 231–233; №17. – Б. 525–527; №21. – Б. 673–675.

*Мәкалә Фәхреддин Ризаэддин «Мәшһүр адәмнәр: «Шура» журналы сәхифәләреннән» китабыннан, (Казан: «Рухият», 2012)*

[1] Бораганский Ильяс Мирза улы (1852–1920) – нашир, китап басу остасы, педагог. Бу шәхеснең Петербургта 1894–1910 елларда хосусый татар матбагасы була. Анда «Нур» газетасы басылуы мәгълүм. – Төз.

[2] Кәримовлар басмаханәсе («Матбагаи Кәримия») – икенче гильдия сәүдәгәрләр Мөхәммәтҗан һәм аның абыйсы Шәрифҗан Минһаҗетдин уллары тарафыннан 1900 елда Казанда ачыла. Бу басмаханәдә «Таң йолдызы», «Тавыш», «Кояш» газеталары дөнья күргән. – Төз.

[3] «Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкясе» басмаханәсе (беренче исеме «Кәрими Ф. басмаханәсе») – 1901 елда Оренбург шәһәрендә Гыйльман Кәримов тарафыннан ачыла. Аннары аның улы Фатих Кәримигә күчә. 1906 елның икенче яртысыннан «Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкясе» басмаханәсе дип үзгәртелә, ширкәтнең хуҗалары Ф. Кәрими, Х. Хөсәенов, Т. Соловьёв була. Биредә «Вакыт» газетасы һәм «Шура» журналы басылган. – Төз.

# Пәйгамбәрләр тарихы

## Хәзрәти Ягъкуб ﷷ вә Йосыф ﷷ

Исхакның ﷷ Гыйсә вә Ягъкуб исемле уллары игезәк иделәр. Хәзрәти Исхак дога кылды: Гыйсәгә Аллаһы Тәгалә бик күп бала бирде, Ягъкубка нәбилек[1] бирде. Хәзрәти Ягъкубны Аллаһы Тәгалә Бәни Кәнганны дингә өндәргә җибәрде.

Ягъкубның ﷷ унике углы булды. Араларында Йосыфны бигрәк сөядер иде. Хәзрәти Йосыф бер төш күрде. Төшендә унбер йолдыз вә ай сәҗдә кылдылар. Бу төшне атасына сөйләде. Ягъкуб ﷷ бу төштән улының пәйгамбәр булуын аңлады. «Кардәшләреңә сөйләмә», – диде. «Сиңа дошманлык кылырлар», – диде. Кардәшләре Йосыфның төшен белделәр, аталарының Йосыфны артыграк яратканын аңладылар, Йосыфка хәсәд[2] иттеләр, аталарына әйттеләр: «Йосыф белән бергә кырга чыгыйк», – диделәр. Аталары рөхсәт бирде. Йосыфны алып чыктылар да, бер аулак җиргә барып, Йосыфны коега салдылар. Ул вакытта хәзрәти Йосыф ун яшендә иде. Йосыфның кардәшләре Ягъкуб аталарына кайтып: «Йосыфны бүре ашады», – дип әйттеләр. Күлмәкне ялган кан белән буядылар, аталарына күрсәттеләр.

Хәзрәти Йосыф коеда өч көн торды. Дүртенче көн кое янына бер кәрван килеп туктады, хәзрәти Йосыфны коедан чыгардылар. Шул көндә Йосыфны кардәшләре карарга килгәннәр иде. Күрделәр: коедан чыккан. Кәрван янына барып: «Бу безнең колыбыз иде», – дип бик очсыз бәһа белән Йосыфны саттылар. Йосыф ﷷ кәрван халкы белән Мисырга барды. Мисыр патшасының мал мәэмүре[3] хәзрәти Йосыфны сатып алды. Баласы

---

[1] Нәбилек – пәйгамбәрлек.

[2] Хәсәд – көнчелек, көнләү, күралмау.

[3] Мал мәэмүре – мал караучасы.

юк иде, хәзрәти Йосыфны үзенең баласы итте. Бер көн мал мәэмүренең хатыны Зөләйха илә хәзрәти Йосыфка ифтира[1] кылдылар да, хәзрәти Йосыфны хәбескә[2] яптылар.

Мисыр патшасының ашчысы белән ширбәтчесе хәбестә иде. Алар бер төш күрделәр, төшләренең тәгъбирен хәзрәти Йосыфтан сорадылар. Хәзрәти Йосыф әйтте: «Берегез хәбестән чыккач асылыр, берегез хуҗасының ширбәтчесе булыр», – диде. Йосыфның ﷺ тәгъбире туры килде: берсе чыгып асылды, икенчесе ширбәтче булды. Йосыф ﷺ һаман хәбестә калды.

Бервакытны Мисырның патшасы бер төш күрде. Үзенең төш юраучыларыннан сорады: «Ялган төш», – диделәр. Ширбәтче хәбескә барып, бу төшне Йосыфка ﷺ сөйләде. Йосыф ﷺ әйтте: «Җиде ел ашлык бик күп булыр, җиде ел ачлык булыр», – диде. Соңыннан Йосыфны ﷺ хәбестән чыгардылар, Мисырның хәзинә нәзыйре[3] итеп куйдылар.

Йосыф ﷺ әйткәнчә, җиде ел ашлыклар бик күп, яхшы булды, соңыннан җиде ел бик ачлык булды. Йосыф ﷺ ашлык күп булган елны ашлыкның артканын амбарларга тутырып куйды. Аннан ачлык еллары килде. Һәр тарафтан ашлык алыр өчен Мисырга килә башладылар. Ачлык Шам тирәсендә дә була башлады. Хәзрәти Ягъкуб ун углын Мисырга ашлык алырга җибәрде. Мисырга килделәр. Хәзрәти Йосыф кардәшләрен таныды, алар хәзрәти Йосыфны танымадылар. Хәзрәти Йосыф сорады: «Сез ничә кардәшсез?» – диде. «Унбер», – диделәр. «Бер кардәшебез атабыз янында калды», – диделәр. «Икенче килгәндә ул кардәшегезне алып килегез, алып килмәсәгез, ашлык бирмим», – диде. Икенче килгәндә Биньяминне дә алып килделәр. Хәзрәти Йосыф ашлык бирде, соңыннан Биньяминне бер хәйлә белән алып калды. Кардәшләре бик сорадылар,

1 Ифтира – яла ягу.

2 Хәбес – кулга алу, ябу.

3 Нәзыйр – караучы.

бирмәде. Кайтып аталары хәзрәти Ягъкубка сөйләделәр. Хәзрәти Ягъкуб сабыр итте, соңрак улларын яңадан Мисырга җибәрде.

Мисырга баргач, хәзрәти Йосыф үзен кардәшләренә белдерде. Атасы хәзрәти Ягъкубны Мисырга чакырды. Хәзрәти Ягъкуб Йосыфтан عليه السلام аерылгач елап күзләре сукыр булган иде. Хәзрәти Йосыф бер күлмәкне кардәшләренә биреп җибәрде: «Атам күзләренә сөртсен», – диде. Ягъкуб عليه السلام нәбилек куәте белән углы җибәргән күлмәкне исеннән белде, йөзенә сөртте, күзләре ачылды. Аннан соң Ягъкуб عليه السلام үзенең җәмәгатьләре белән Мисырга китте. Анда унҗиде ел хәзрәти Йосыф белән бергә торды. Аннан соң хәзрәти Ягъкуб вафат булды. Үзенең васыяте буенча Кәнган җиренә илтеп, атасы Исхак عليه السلام янына дәфен ителде. Хәзрәти Ягъкуб вафат булгач, 54 елдан соң 125 яшендә Йосыф عليه السلام вафат булды. Йосыфның عليه السلام кабершәрифе Муса عليه السلام килгәнче Мисырда иде, аннан соң Муса عليه السلام хәзрәти Йосыфның табутын алып, хәзрәти Ягъкуб янына илтеп күмде.

## Әюб عليه السلام

Хәзрәти Исхакның Гыйсә исемле углының нәселеннән Әюб عليه السلام дөньяга килде. Аллаһы Тәгалә хәзрәти Әюбкә балалар бирде, күп мал бирде. Соңыннан Аллаһы Тәгалә, аны сынау өчен, балаларын үтерде, куйлар вә дөяләрен һәлак кылды, ашлыкларын хәраб итте, хәзрәти Әюбкә бер авыру бирде: тәненнән итләре череп төште, бөтен гәүдәсенә кортлар ябышты. Әюб عليه السلام боларның барчасына сабыр итте, соңыннан Аллаһы Тәгалә шифа бирде, сәламәтләнде. Аллаһы Тәгалә малларын, балаларын яңадан ике өлеш итеп бирде. Хәзрәти Әюб күргән мәшәкатьләренең мөкяфәтен[1] алды вә 90 яшендә икән вафат булды.

1 Мөкяфәт – 1) хезмәт бәрабәренә бирелгән премия, бүләк; 2) яхшылыкка каршы эшләнгән яхшылык.

## Хәзрәти Шөгәеб ﷺ

Хәзрәти Шөгәеб ﷺ бик фәсыйх[1], бик бәлигъ[2] иде, шуның өчен хатиб әл-әнбия дип аталды. Начар эшләргә даимчылык кылган Әикә вә Мәдьян халкына пәйгамбәр булды, аларны хак дингә өндәде. Хәзрәти Шөгәебнең сүзе бик татлы вә бик әсәрле иде, шулай булса да, кавеменә хак дингә керү насыйп булмады. Соңыннан Аллаһы Тәгалә ул кавемнең барчасын ут яудырып һәлак кылды. Аннан соң хәзрәти Шөгәеб иман китергән кешеләр белән Мәккәгә барды, 200 елдан артыграк яшәгәч, вафат булды.

## Муса ﷺ

Хәзрәти Муса Бәни Исраилдән, ягъни хәзрәти Ягъкуб нәселеннән Гыймран исемле кешенең углыдыр. Хәзрәти Ягъкубның ләкабе[3] Исраил булган өчен, балаларына Бәни Исраил дип әйтелде. Бәни Исраил унике кабилә булды. Һәр кабилә хәзрәти Ягъкубның бер углыныңдыр. Бу унике кабиләнең барчасына берьюлы исбат Бәни Исраил дип әйтелде.

Бәни Исраил хәзрәти Йосыф заманында Мисырда иделәр. Мисырның асыл халкы кыптыйлар иде, потка табыналар иде. Алар Бәни Исраилгә бик дошман иделәр, Бәни Исраилне бик хәкарәт[4] кылалар иде. Авыр эшләргә, начар эшләргә Бәни Исраилне кушалар иде. Бәни Исраилнең Мисырдан китүләрен теләмиләр иде. Бәни Исраил, хәкарәттән котылу өчен, Мисырдан качып, Аллаһы Тәгалә тарафыннан вәгъдә кылынган, бабаларының йорты булган Кәнган җиренә китүне телиләр иде.

Ул вакытта Мисырның патшасы Фиргавен иде. Гайбтән[5] хәбәр бирүчеләр Фиргавенгә әйттеләр: «Бәни Исраилдән бер бала туар, синең

1 Фәсыйх – матур һәм килешле итеп сөйли белүче.

2 Бәлигъ – матур, төзек, тулы мәгънәле итеп (язылган, сөйләнгән).

3 Ләкаб – кушамат.

4 Хәкарәт – хурлау, кимсетү, хур итү.

5 Гайб – билгесез әйбер.

дәүләтеңнең китүенә сәбәп булыр», – диделәр. Фиргавен Бәни Исраилдән дөньяга килгән ир балаларны барысын да үтерергә боерды. Һәр иргә кешеләр куйды. Бәни Исраилдән дөньяга килгән ир балаларны үтерә башладылар. Ул вакытта хәзрәти Муса дөньяга килде. Анасы бу хәлдә хәзрәти Мусаны Аллаһ саклар, дип сандык эченә куеп, Нил суына атты. Фиргавеннең хатыны суда сандыкны күргәч, тотып алды. Ачып караса, эчендә бер бала бар. Ул баланы алып, үзенә угыл итте. Фиргавеннең хатыны бу баланы имезергә сөт анасы эзләтте. Хәзрәти Мусаның анасы үзен бу баланың анасы икәнен белдермичә, Фиргавеннең йортына барып, баласын имезеп тәрбия итә башлады. Хәзрәти Муса үсеп җитте.

Бер көн урамда кыптыйлардан бер кеше белән Бәни Исраилдән бер кеше кычкырышалар иде. Хәзрәти Муса күрде дә, барып кыптыйны сугып үтерде. Соңыннан, Фиргавеннән куркып, Мәдьянга килде. Мәдьянда Шөгаебнең ﷺ кызына никахланды. Берничә вакыт Мисырда торды, аннан соң хатыны белән Мисырга китте.

Мисырга барганда Тур тавына очрады. Аллаһы Тәгалә аңа пәйгамбәрлек җибәрде, могҗиза итеп таяк бирде. Кардәше Һарунга ﷺ да пәйгамбәрлек бирде, икесенә бергә Мисырда Өлүһият дәгъвасында булган Фиргавенне һәм кавемен хак дингә өндәргә боерды.

Хәзрәти Муса кардәше Һарун белән Мисырга бардылар, Фиргавенне һәм кавемен хак дингә өндәделәр. Фиргавен могҗиза истәде. Хәзрәти Муса таягын җиргә куйды – аждаһа булды. Фиргавенне тәхете белән йотарга касд итте. Фиргавен хәзрәти Мусадан үтенде. Хәзрәти Муса аждаһаны кулына алды – таяк булды. Аннан соң Фиргавен бик күп сихерчеләр җыйдырды. Сихерчеләр бер җиргә чыгып, агачларны, җепләрне халыкка елан итеп күрсәттеләр. Хәзрәти Муса таягын җиргә куйды: аждаһа булды, сихерчеләрнең барча еланнарын, җепләрен йотты. Сихерчеләр моны күреп, барчасы иман иттеләр. Фиргавен иман итмәде, аннан соң Мусадан ﷺ һәм аңа ияргән Бәни Исраилдән курка башлады.

Бер көн Фиргавен Бәни Исраилгә Мисырдан чыгарга рөхсәт бирде. Хәзрәти Муса бер кичәдә Бәни Исраилне Мисырдан алып чыкты. Фиргавен рөхсәт биргәненә бик үкенде. Аларны артларыннан гаскәр белән куып Фиргавен үзе чыкты. Муса ﵇ Бәни Исраил белән Сүәеш диңгезе[1] янына килделәр. Муса ﵇ диңгезгә таяк белән сукты: диңгездән унике юл ачылды. Хәзрәти Муса Бәни Исраил белән бу унике юлдан чыктылар. Фиргавен дә алар артыннан керде. Бәни Исраил чыгып җиткәч тә, сулар капланды. Фиргавен гаскәре белән суга баттылар.

Аннан соң хәзрәти Муса Кәнган җирен алу өчен гамәлика халкы белән сугышмакчы булды. Бәни Исраил: «Без сугышмыйбыз», – диделәр. Хәзрәти Мусаның сүзен тотмадылар. Хәзрәти Муса явыз дога кылды: Бәни Исраил Тийә сахрасы дигән җирдә кырык ел калды, һич бер җиргә китә алмадылар.

Шул вакытларда Муса ﵇ Тур тавына барды. Аллаһ тарафыннан Тәүрат шәриф бирелде. Шуның өчен Мусага ﵇ Кәлимуллаһ дип әйтелде. Хәзрәти Муса Турда вакытында, Бәни Исраилдән Сәмири исемле бер монафикъ бер бозау сурәте ясап, Бәни Исраил шул бозау сурәтенә табына башладылар. Һарун ﵇ боларны эшләреннән тыярга бик тырышты, тыңламадылар. Муса ﵇ Турдан кайтып күрде, бик ачуланып бозау сурәтен диңгезгә атты. Аларга Тәүрат шәрифне өйрәтте.

Бәни Исраил кырык ел Тийә сахрасында тордылар, бер җиргә дә китә алмадылар. Аннан соң Һарун ﵇ вафат булды. Аннан соң Муса ﵇ Тийә сахрасында, Кәнган чокырына якын җирдә, Бәни Исраилне Йушагъка ﵇ тапшырып, үзе вафат булды. Вафат булганда хәзрәти Муса 120 яшендә иде.

*(Дәвамы бар)*

*Галимҗан Баруди, 1899 ел*

---

1 Сүәеш каналы (Суэцкий канал).

# Тарих

# Беренче мөфти – Мөхәммәдҗан

Губернатор голәмәләр арасыннан ышанычлы бер кешене мөфти итеп тәгаен кылды. Мөфти итеп Мөхәммәдҗан Хөсәенов билгеләнде.

Духовное собрание архивында менә шулай язылган: 1756 елда туган 33 яшендәге кеше. Әүвәл Каргалыда, аннан соң Бохарада гыйлем алган. Фарсы теле белән яхшы таныш, Бохарадан Әфганга чыгып Кабул шәһәрендә торган. Фәезхан кебек әмирләр белән һәм башка хөкүмәт кешеләре белән катнашкан кеше. Чыгышы – сәүдәгәр сословиясеннән. Торак йорты Уфа губернасы Солтанай авылында. Элек Оренбургта офицер була. 1785 елның 9 нчы июлендә казакъларны Россия белән итагать һәм солых белән яшәргә чакырып комиссиягә казакълар өчен ахунд булып барган. Казакъларны хөкүмәткә буйсындыруда күп хезмәте күрелде. Аннан соң Кавказ ягына барып, Россия әсирләрен азат итте. Кавказдагы (Кабардин) халкын Россиягә итагать кылырга ант иттерде. Аннан соң Әстерхан тирәсендәге төрекмәннәр арасында йөреп, аларны вәгазьләп, Россия хөкүмәтенә итагать иттерде. Ошбу хезмәтләре өчен берничә каршылык очраклары да булды. Шундый хезмәтләр белән Әби патшага танылды да, мөфти итеп билгеләнергә муафикъ булды. Аннан соң император Павел тарафыннан да күп медальләр бирелде. Оренбургтагы зур хөкүмәт йортына кереп утырды һәм башка зур бүләкләр алды.

Мөхәммәдҗан мөфти халыкларның теләкләрен хөкүмәткә ирештергәндә күп хезмәт иткәне шикелле, хөкүмәт тарафыннан да халыкка күп иркенлекләр алып бирде.

Бу вакытларда татар-башкорт, казакъ һәм башка халыкларның баш күтәрүеннән Әби патша бик курка иде. Көчләп чукындыру эшләре бөтенләй бетте. Мәчет, мәдрәсә салуга рөхсәт булды. Моның өстәвенә, Оренбургка, Верхний Урал, Троицкий, Омский шәһәрләренә хөкүмәт хисабына мәчет салынды. Бер дини мәдрәсә салынды. Мөдәррис Мөслим

хәзрәт иде. Имтиханнар кылып, имамнар тәгаенләп, тынычлык хакында ишарә итә иде. Ләкин язулар бар да русча барды. Ачылган көннән башлап, Духовное собрание Уфада биш елга кадәр торды. Биш елдан соң Оренбургка күчерелде. Оренбургтан 1802 елда яңадан Уфага күчерелде. Ләкин исеме Оренбургское духовное управление булып калды.

Диннәрен чын күңелдән сөйгән һәм үз халыкларын дин кардәш дип йөргән мөселманнар өчен яңа мөфти куелу бик кадерле. Мөселманнар арасында мөфтинең абруе, кадере, дәрәҗәсе гаять югары урында булган кебек, хөкүмәт түрәләре арасында да дәрәҗәсе гаять югары иде, хокукы зур иде, һичбер поп яки миссионер аңа каршы килә алмый иде. Бер җирдә мәчет яки мәдрәсә салырга дисә, бер кеше каршы килми иде. Мөфти казнадан айга 125 сум акча жалуния алу өстенә күп бүләкләр дә алган. Тормышы яхшы иде. Бик пөхтә, күркәм, байлар кыяфәтендә йөри иде. Уфа урамнарында дүртәр пар ат җигеп горуранә йөри иде. Хөкүмәт түрәләре дә алай йөри алмый иде. Муллаларны ышанычлыларны һәм казыйларны үзе лаеклы итеп сайлый ала иде. 1789 елдан 1889 елга кадәр йөз ел вакыт эчендә башкорт, казахлардан казыйлар була алмады. Йөз елдан соң гына алардан казыйлар була башлады. Татар халкында булган комсызлыктан Мөхәммәдҗан мөфти дә котыла алмады. Уфа губернасында Мират авылы янында очсыз гына, арзан гына итеп 2284 дисәтинә җир хуҗасы да була алды. Аның өстәвенә кызы Фатыйманы казакъ ханы Җиһангир Бүкәханыфка биреп, никахлап, аңардан күп елкы маена хуҗа булып, имениесендә ат үрчетеп, аны сатып, зур малга ия булды. 1815 елда чиктән үтте. Мөфтинең атлар саны 50 меңгә җитте (халык файдасына эшләүне онытты) дип газетага язылды. Мөәррих (тарихчы) Мәрҗани үзенең «Мөстәфадел-әхбар»иендә: «Мөхәммәдҗан мөфти атлар сатып 50 мең сум акча һәм күп мал җыйды, үлгәндә шул акчалар өстенә ятып үлде», дип яза. Оренбургтагы үз йорты өстенә, Уфада Пушкин урамында зур агач йорт салып, күп атлар тотып, рәхәт гомер сөреп вафат булды ﷺ.

Ләкин югарылыкның зәвәле да була бит. Ахыр көнендә башкорт авыллары шул имениене даулап судка бирделәр. Җирен суд белән алдылар. Үзе судта гаеп йөкләп утырды. Ахыр гомерендә рус хөкүмәте көчәеп җиткәч, восстаниеләр беткәч, ул җәһәттән куркыныч беткәч, мөфтинең үгетнәсыйхәтенең дә кирәге беткәч, хөкүмәт алдында да бәһасы беткән иде. Үзе дә бер байга әверелгәч, халык алдында да абруе калмады. Шулай итеп бәхет туктап, тынычсыз көннәрдә 1824 елда һиҗри 1239 да шәүвәлнең 20 сендә Уфада үз йортында 68 яшендә, 36 ел 10 ай мөфти булып гомер итеп вафат булды. Өч улы, бер кызы калган. Бер улы офицер. Фатыйма казакъ ханы хатыны. Маллар кайдан килде, шунда китеп беткән. Мөфти хәзрәтнең гыйлеме уртача булган диләр. Күп игътиразлар кылганнар. Кеше гаебен күрү ансат, әмма эш кылу авырдыр. Шул вакыттагы тынычсызлыкларны туктатып, тыныч дөнья коруга хезмәте зурлыгы хактыр. Мөхәммәдҗан хакында «Әд-дин вәл-әдәб» журналының беренче ел чыгарылышында, Гыймад әфәнденең язуыннан укыганыбыз җитә. Ул вакыттагы хәлләрне аңлар өчен минем тәкъдимем: «Шул авыр вакытта син шул эштә булсаң, ни эш кылыр идең?»

## Икенче мөфти – Габдессәлам

Мөхәммәдҗан мөфти вафат булгач, төрле галимнәр мөфтилеккә тәкъдим ителде: Казаннан Габдессаттар хәзрәт Сәгыйдов һәм Урый Фәтхулла бин Хөсәен кебекләр. Ләкин Оренбург тирәләренә һәм хөкүмәткә мәгълүм кеше булуы сәбәпле, Оренбургның Габдессәлам хәзрәтне Оренбург губернаторы тәгаенләп тә куйды. Шул регистрация белән 1825 елның 30 сентябрендә Александр I указ да бирде. Собрание архивындагы язмалар буенча, Габдессәлам мөфтинең тәрҗемәи хәле будыр: Габдессәлам бин Габдеррәхим 1826 сәнәдә 53 яшендә, бер улы Габдерәуф 20 яшендә, бер улы Әхмәд 2 яшендә, Гыйниятулла 1 яшендә, барысы бергә

Уфага килделәр. 1799 елда Оренбургның таш мәчетендә имам, 1805 елның 14 нче декабрендә ахунд һәм мөдәррис, 1806 елда хөкүмәт тарафыннан хезмәтләре өчен мөкәфәт итеп, елга 150 сум вазифа тәгаен ителгән. 1814 сәнәдә алтын медаль бирелгән һәм 80 сумга вазифасы арткан (230 сумга куелган). 1817 елда бөтен түләүләрдән азат ителгән. Шул ук елда янә дә 70 сумга вазифасы арттырылган (барысы 300 сум). 1820 елда 100 сум бүләк бирелә һәм казакълар арасына барып, андагы хәлне тикшерү комиссиясенә әгъза итеп билгеләнә һәм андагы кайбер тәдбирләренә мөкәфәт итеп 500 сумлык алтын сәгать бирелгән. 1825 елның 30 сентябрендә Уфага күчеп килде. Йорт алыр өчен император Алексей 14000 сум бүләк бирә. Моннан соң да күп медальләр бирелде. Мондый дәрәҗәләренә Мөхәммәдҗан мөфтинең эче поша иде. Шуңа күрә араларында низаглар була иде. Бу низаглар Мөхәммәдҗан мөфтинең куен дәфтәрендә күренә. Бу хәлләрне «Шура» журналының 1914 елгысында укырга мөмкин.

Габдессәлам мөфтинең беренче эше шулдыр: халыкка сәлам белән хитабнамә таратты, һәм Уфа шәһәрендә мәчет булмау сәбәпле, җәмәгать намазы укылмау бик зур кимчелек икәнен аңлап һәм аңлатып, иганәтләр теләде. Мәдрәсәләр, имтихан йортлары кирәклеген белдерде. Шуннан сон Казан губернасының Чар өязе Байлар Ырысы Габделмөэмин бай Фәтхулла хәзрәт киңәше белән Уфага мәчет салды. Бу 1830 ел иде. Моңа кадәр Уфада мәчет юк иде. Бу эшне башкару Габдессәлам мөфти белән Габделмөэмин байга насыйп булды. Мөфти үзе имам булды. Бу мәчет 1896 елда зурайтылды.

1828 елда казакълар тәмам буйсындырыла. 1846 елда Оренбургта Кәрвансарай йорты салынган. 1828 елда имамнарга митрикә дәфтәре бирелә. Габдессәлам мөфти төрмәләргә имамнар җибәреп мәхбүсләрне нәсыйхәт кылдыру эшләре эшләгән, һәр шәһәрдә бер мулла хабесханәгә барып йөргән. 14 ел мөфти булып торган. 67 яшендә 1840 елда, һиҗри

белән 1255 елда Уфада вафат була. Варисларына 4849 сум акчасы кала. Үз хәтер дәфтәреннән күчерелгән «Шура» журналында мәкалә бар.

*Габделхак Саматовның*
*«Милләтебездә Ислам дине» китабыннан*

# Мөселман руханиларына каршы репрессияләр

*(Дәвамы, башы журналның 18 санында)*

Октябрь ахырында Буа кантонында, дин хезмәтчеләренә салым йөкләнелүгә бәйле, руханиларның массакүләм чыгышлары күзәтелә. Берләшкән дәүләт сәяси идарәсе (ОГПУ) карашынча, башлап җибәрүче кеше мөхтәсиб Мөнир Халитов була. Аңа каршы җинаять эше кузгатыла, ләкин ул качып китәргә өлгерә.

Шул ук елны Түбән Чәке авыл мәктәбе укытучысы Шәрифзидә Моратова, мәчетләр ябылуга каршы чыгып, бер төркем авылдашларын җыя һәм мәчет бинасыннан флагны һәм инкыйлабка бәйле плакатларны йолкып төшерә.

Шулай ук республикадан читкә сөрелгән муллаларны озату да массакүләм дәшмичә протест белдерү чараларына әйләнеп китә. 6 июльдә Әгерҗе станциясендә күпчелеге хатын-кыздан торган 200ләп кеше җыела. Алар Владимир өязенә сөргенгә җибәрелгән мөхтәсиб Адутовны озатырга килә, теләгән кешеләр сәдака китерәләр. Шушында ук мөхтәсибләрне иреккә чыгару хәрәкәтен оештырып җибәрү карары кабул ителә.

Калинин М. И. белән бергә сөргендә булган Ижау заводы эшчесе Гайсинны Мәскәүгә командировкага җибәрәләр. Ләкин ниндидер билгесез

сәбәпләргә бәйле ул Казанга хәтле генә барып җитә. Адутов урынына калган һәм аны иреккә чыгару өчен тырышлык куеп йөргән Мостафинны да 1929 елның августында хөкемгә тарталар һәм өч елга ирегеннән мәхрүм итәләр, 1930 елда исә срогын биш елга кадәр озайталар.

Казаков мәчете мулласы Гаяз Якуповны, Печән базары мәчете мулласы Таиб Алтынбаевны, Әҗем мәчете мулласы Кыям Габдулгафуровны кулга алганнан соң, Вахитов исемендәге заводта һәм «Красный Восток» заводында, аларны иреккә чыгаруларын таләп итеп, имзалар җыю башлана. Барлыгы 209 кеше кул куя. Ләкин ОГПУ тырышлыгы белән әлеге акциягә нокта куела. ГПУ бүлегенә чакыртылган делегация вәкилләрен, сезнең үзегезне дә инкыйлабка каршы көрәшүчеләр исемлегенә кертәчәкләр, дип куркуга салалар.

Кулга алынганнарны иреккә чыгару эшләрендә Казан мөхтәсибәте секретаре Әюп Фәйзуллин гаять активлык күрсәтә. 12 нче мөхтәсибәтнең утырышында ул Гаяз Якупов гаиләсенә даими ярдәм күрсәтүне булдыру буенча тәкъдим ясый. Бу вакыйгаларга хәтле әле күптән түгел генә Якупов үзе зур төркем мөселманнар белән бергә 1927 елның 16 мартында вокзалда мөхтәсиб Кәнәфи Мозафаровны сөргенгә озатып кала һәм аңа сәфәре өчен 70 сум акча тоттырып җибәрә.

Әмма протестлар көннән көн азая башлый. Күбесе үзләре өчен куркуга кала. Бу уңайдан 12 нче мөхтәсибәтнең җыелышында Фәйзуллинның әйткән сүзләре игътибарга лаек: «Әгәр без бердәм булсак һәм куркып калмасак, алга китә алачакбыз. Куркуга бирешсәк, безне юк итәчәкләр. Муллаларыбызны кулга алганда, без куркаклык күрсәттек».

1926 елның октябрендә Республика эчке эшләр Наркоматы (НКВД) Казан мөхтәсибәтенә мәчет ачарга рөхсәт бирми, хәтта моның сәбәпләрен дә аңлатып тормый. Мулла Касыйм Салихов нарком урынбасарына мөрәҗәгать иткәч тә, ул: «Сәбәбе табылыр», – дигән җавап ала, чөнки алар ОК ВКП (б) һәм ОГПУ указы нигезендә эшлиләр. Шушы вакыйгалардан

соң, 10 октябрьдә «Кызыл Татарстан» газетасында Хуҗиевның «Муллалар читән аша сикереп чыга» дигән заказ белән язылган мәкаләсе бастырыла. Нәкъ шул вакытта мулла Гаяз Якупов үз даирәсендә: «Мин мәчетне ташлап китәрмен, мөгаен. Монда үзара килешеп эшләнгән көрәш бара. Килеп көчләп туктатмаячакларына ышаныч юк», – дип әйткән була. Ике ел да үтми, аны да Соловкига озаталар.

1927 елда ОГПУ үзенең иң зур уңышы дип дини мәктәпләрнең санын киметүне атый. Югарыдан һәр мәдрәсә ачу омтылышларын юк итәргә дигән фәрман килә. Сәбәп буларак рәсми рөхсәт юклыгын китерәләр. Шулай ук укыту программасына дөньяви предметлар укытуны кертү таләбен дә кире кагарга дигән күрсәтмәләр бирелә. Бу инде яңалык булмый. 1914 елда ук Мамадыштан Яснитский исемле өяз полициясе начальнигы (исправник) Казан губернаторына язган рапортында: «Гасыйм Гатин һәм Ибраһим Бикмөхәммәтов исемле указлы муллалар рөхсәтсез рәвештә татар балаларын уку-язуга өйрәтәләр», – дип хәбәр итә. Инспектор таләбе буенча, алардан сорау алына һәм эшләре судка тапшырыла. 20 нче елларда Гатинның эшләре белән инде ОГПУ шөгыльләнә башлый. 1924 елның маенда Казан шәһәре милиция башлыгы ярдәмчесе Брегин И. 7 яшьтән алып 14 яшькә кадәр булган балаларга дини гыйлем биргәне өчен сукыр Габдулла Сәмигуллинны җавапка тарта.

Әлбәттә, гомумән алганда, дини мәктәпләрнең саны кимүдә боларның да тәэсире булмый калмаган. Шул ук елның октябрендә, ярминкә тәмамланганнан соң, Буа мулласы Ибраһим Хөсәенов йортында Сембер өязе Тархан районының 17 мөхтәсибе җыела. Әлеге җыелышта, башка мәсьәләләр белән беррәттән, дини гыйлем бирүнең чыдый алмаслык дәрәҗәгә төшүе, шуңа мөнәсәбәтле чит илләргә мөрәҗәгать итү ихтыяҗы туу мәсьәләсе дә күтәрелә.

Әмма дингә каршы башланган көрәш зурга китә. 1927 елда, гәрчә Диния нәзарәте вәкиле казый Кәшәф Тәрҗеманов мәдрәсә ачуга рөхсәт

алган, инде 15 шәкерт җыелган һәм мөдир буларак Таһир Ильясов билгеләнгән булса да, ОГПУның Көнчыгыш бүлеге начальнигы Петросьянц Татар бүлегенең начальнигы Кандыбиннан барлык мәдрәсә ачу омтылышларын юк итүне һәм укыту программасына дөньяви фәннәрне кертүне кире кагуны таләп итә.

Мөселманнарның ризасызлыгы әледән әле төрле чыгышлар барлыкка килүгә китерә. 1930 елның гыйнварында Буа волосте Яңа Чуклы авылында булган вакыйгалар моңа ачык мисал. Биредә, колхоз составына керүгә каршы котыртканы өчен Шакир Галләмов исемле мулланың кулга алынуы сәбәпле, массакүләм чуалышлар, атышлар була, чекист һәм милиция хезмәткәрләреннән торган оператив группа вәкилләрен кыйнап ташлыйлар. Опергруппаны авылдан куып чыгарганнан соң, авылда төнге каравылчылар билгеләнә. Ләкин гыйнварның 15 нән алып 16 сына каршы төнендә авылга Сембердән 90 аттан торган җәзалау отряды килеп төшә. 20 кеше кулга алына, шул исәптән Галләмов һәм өч хатын-кыз: мулла хатыны Сара һәм Галләмовны яклап чыккан Узбәкова Мәфтухә, Ибниәминова Сара. Шушы вакыйгалардан соң башка торак пунктларында да бик күп кешеләрне, шул исәптән, мөселман дин хезмәткәрләрен кулга алулар башлана. Иске Задур авылыннан мулла Биккулов, Түбән Чәкедән Дунаев, Югары Каракитәдән Ямашев, Яңа Ишледән – Мәрдиев, Олы Чылныдан Усмановны кулга алалар. Операция вакытында барлыгы 800 кеше кулга алына. Кандыбин ОГПУ рәисе урынбасары Ягодага җәзалау операциясе хакында доклад ясаганда, Галләмовның хатынын һәм Сара Ибниәминованы, шулай ук Яңа Чокалыдан алты кешене атып үтерергә рөхсәт сорый.

20 нче елларның урталарыннан башлап законсыз рәвештә дини китаплар таратуны чикләү башлана. Аларның эшчәнлеге түбәндәге өлкәләрне үз эченә ала: китап бастыру эшенә киртәләр кору, нигезсез рәвештә тиражны киметү, рәсми рәвештә басылып чыккан журналларны сатуны тыю, аларны таратучыларны кулга алу, «Ислам» журналын-

да репрессияләнгән мөселман эшлеклеләренең материалларын басарга рөхсәт итмәү, текстның эчтәлеген ирекле рәвештә шәрех кылган рәсми цензура.

Казанда мөселман китаплары таратуның берничә үзәге була. Дини әдәбиятны сату белән Шәгар Шәрәф, Хәйретдин Әхмәтҗанов, Гайнетдин Мөкминов, Шәрифҗан Кәримов, Габдессәлам Катаев, Габбас Ибраһимов һәм Гариф Закиров («Шәрык» китап кибете) шөгыльләнә. Сәүдә итү тыелмаган, ләкин хакимият аны законсыз буларак кабул итә. 1928 елның октябрендә Ш. Шәрәфне кулга алганнан соң, Ак мәчеттәге 250 пот төрле китапны, шул исәптән Коръән, тәфсир, дөньяви фәннәр буенча дәреслекләр, фәнни китапларның шактый зур тиражын һәм Галимҗан Шәрәфнең «Тарихи гыйлем»ен үз эченә сыйдырган складка арест салына. Бу уңайдан Газиз Гобәйдуллинның 1921 елда «Дин тарихы» китабы хакында әйткән сүзләре чынга аша: «Совет хөкүмәте вакытында икенче томны бастырырга тырышмасаң да була, барыбер басмаячаклар». Унҗиденче мәчет имамы Сәед Вахидов та үзенең фәнни хезмәтләре хакында шундыйрак сүзләр әйткән була. Ул гына да түгел, җирле үзидарәнең дингә каршы көрәшәчәген алдан күзаллап, ул дини китапларның гына түгел, гомумән, гарәп имлясендә басылган теләсә нинди әдәбият яки документның юкка чыгарылачагын фаразлый. 1927 елны ОГПУның Башкорт бүлеге җитәкчесе Музыкант Мәскәүдән Петросьянцтан СССРның Европа һәм Себер өлешләренең Диния нәзарәтендә чыккан «Ислам» журналының 12 нче саны буенча түбәндәге күрсәтмәләр ала: «Без сөргенгә озатылган мулла Хәнәфи Мозафаровның мәкаләсен бастыруга кискен каршылыгыбызны белдерәбез. Башглавлит аша «Ислам» журналы редакциясенә шуны белдерергә кирәк: без беркая да Совет хөкүмәте дошманнарының мәкаләләрен бастырырга рөхсәт итмәячәкбез. Югыйсә, «Ислам» журналы киләчәктә бөтенләй чыгудан туктаячак».

1927 елда Диния нәзарәтенә үзенең типографиясен ачарга рөхсәт ителми. Хакимият фәрманы белән «Һәфтияк шәриф»нең тиражы 50 меңнән 15 меңгә кадәр төшерелә. 1927 елның июлендә Габбас Ибраһимов Казанда дини китаплар бастыру өчен кооператив типография ачу мәсьәләсен хәл итү өчен Уфага килә. Мөфтият аңа бу сорауны җирле үзидарә белән хәл итәргә киңәш итә. Пароходта кайтканда чекистлар Ибраһимовны кулга ала, янында 33 мең акча табыла. Шул вакытта ОГПУ Главлит белән килешеп «Ислам»ның күләмен бер басма биткә калдыра, тиражын да 4 меңнән 2,5 меңгә кадәр киметә. ТатОГПУ хезмәтчесе Мозафаров, канәгатьлек белдереп: «Татар руханилары арасында җитди ялгышлыклар юк, түбән тәгәрәү һәм салымнардан зарлану күзәтелә. Диния нәзарәтенең абруе төште, «Ислам» сатылмый да, язылучылары да калмады диярлек», – дип әйтә. Ул вакытта журналны Спас кантонында 180, Минзәләдә 70 кеше яздырып ала. Басма хезмәтләр генә түгел, хәтта мәктәп укучылары тарафыннан кулдан язылган һәм 1925 елдан бирле чыгып килгән «Ислам баласы» журналы да фетнә чыгара торган язмалар исемлегенә кертелә. 1928 елда журналның редактор әгъзалары Исхак Закиров, Зөфәр Абдуллин һәм башкалар кулга алына. Ул гына да түгел, Гаяз Якуповка һәм мөәзин Шәрифҗан Ибраһимовка гаеп такканда, аларның шул журналга кагылышы барлыгы кулланылачак.

Дини китаплар бастыру бөтенләй туктатыла диярлек. Шул өлкәгә кагылышлы мәсьәләләрдә чит илләр белән мөнәсәбәт тә туктатыла. 1928 елның мартында ОГПУ тарафыннан бертуган Кәримовларга Һиндстаннан Мөхәммәд Абдул Тәубтан килгән хат конфискацияләнә. Әлеге хатта аларның басмаханәләрендә чыккан дини китаплар исемлеген сорап мөрәҗәгать ителгән була. Бары тик «Безбожник», «Фән һәм Дин», «Безбожник у станка» кебек басмаларга гына дәүләт тарафыннан ярдәм күрсәтелгән.

Диния нәзарәтенең абруена килгәндә, Мозафаров хаклы булган. ОГПУ эшчәнлеге нәтиҗәсендә, нәзарәтнең эчке эшләренә зыян китерелә, шунда эшләгәннәр куркытыла. Мөфти Риза Фәхретдиннең реформаторлык эшләренә бәйле туган каршылыкларны ОГПУ үз файдасына куллана. Мөфтиятнең җирле үзидарәнең законсыз эшчәнлегенә тәэсир итә алмавы да аның абруен төшергән, әлбәттә. Әмма ләкин моңа бәйле ОГПУ алдында башка мәсьәлә килеп туа: мөселманнар һәм хакимият арасында урталыкта калмас өчен, мөфтият һәр мәсьәләне хәл итү өчен мөселманнарны җирле үзидарәгә борып җибәрә башлый. ОГПУга бу бер дә ошамый. Диния нәзарәтенең абруен төшереп, алар мөселманнар белән икәүдән икәү генә калу ихтималын күз уңыннан очкындыралар. Бу уңайдан Петросьянцның Музыкантка язган хаты игътибарга лаек: «Иң куркынычы шунда: иң түбән дәрәҗәдәге руханилар яисә мөселманнарның күпчелеге белән безнең арада арадашчы калмаса, нишләрбез. Диния нәзарәте кебек органнар тормоз вазифасын башкаралар. Алар үзләренең йогынтысын бөтенләй югалтып бетермәскә һәм шул ук вакытта контрольдә тотылырга тиеш. Бу мәсьәләне бары тик ОГПУ хәл итә ала».

Хакимиятнең тоталь басымы шартларында утызынчы елларга таба Татариядән күчеп китүләр күбәя башлый. Күчеп китүчеләрнең күпчелеге, нигездә, Урта Азия якларына юнәлә, чөнки чит илләргә китү хакында уйларга да мөмкинчелек калмый. Чуриле волостеның Курса Почмак авылы мулласы Сабир Әхмәтҗанов, бу котылгысыз халәтне күреп: «Мин хәзер шуны аңладым: безгә Татар республикасында яшәргә ирек бирмәячәкләр. Үз-үзеңә кул салу яраклы эш түгел. Гаиләмне калдырам да, китәм», – дип әйткән. ОГПУда болай дип теркәлгән: «... күпчелек муллалар, муллалыкларын ташлап, алга таба Төркия һәм Әфганстанга китү максаты белән, Төркестан, Урта Азия якларына күчеп китәләр». ОГПУ хезмәткәрләре, Татариядән китәргә җыенган муллаларны теркәп барырга һәм аларның чит илләр белән нинди элемтәдә торуларын тикшерергә, дигән боерык

алалар. «Чистай кантонында Гали Мостафин һәм Мөхәммәт Богданов актив рәвештә күчеп китү темасын күтәрәләр. Шул вакытка таба Урта Азия якларына күчеп киткән йөзләгән кешеләр арасында Иркен поселогыннан Кәшәфетдин Таһиров, Кызыл Сукачы авылыннан Харрис Фәхретдинов, шулай ук Буа өязенең Каракашлы авылыннан Габдулла Гатауллин да була. 1929 елның маенда Арбаш авылыннан Вафа Рахматуллин, Пускән авылыннан Габделәхәт Сафин, Мамадыш өязенең Олыяз авылыннан Абдуллин һәм Юсупов, үзара килешеп, шундагы вазгыятьне белер өчен, Юсуповны Урта Азиягә озаталар. Алар бөтенесе дә күпбалалы, һәркайсының иң кимендә җиде баласы була. Ләкин ОГПУ хезмәткәрләре болар хакында инде хәбәрдар була. Балтач волком ВКП (б) секретаре Мухаметкулов Арчадагы ОГПУ вәкиленә волостьтән дүрт мулланың чыгып китүе хакында һәм тиешле чаралар күрергә кирәклеге хакында хәбәр итә. Балтач авылы мулласы Сабир Сәгадиевнең 1930 елда Ташкентта үзе артыннан күзәтүләрен сизүе дә очраклы күренеш булмый. ОГПУ хәтта Казанга барып кайтуны да күзәтергә кирәк дип таба. Мәсәлән, Хәсәншәех авылы мулласы 1930 елда Казанга килде, дип теркәп куелган. Даими яшәгән урыннарыннан берәр кая сәфәргә чыккан руханиларга карата: «Салым түләүдән качучы», – дигән гыйбарә куллана башлыйлар. Казандагы вазгыять тә яхшырак булмый.

ОГПУ хезмәткәрләренең дини тормышка кысылуы шулкадәр киң җәелә һәм ачыктан ачык башкарыла, хәтта прокуратура да бу гамәлләрдән ризасызлык белдерә башлый. Бу бигрәк тә ОГПУ тарафыннан яңа сайланган мөхтәсибәт әгъзаларына Диния нәзарәте биргән шәһадәтнамәләрне тартып алуда күренә. 1928 елда 20000 шундый шәһадәтнамә хәзерләнә. Тат ОГПУ башлыгы Николаевка таныклыкта мөселман җәмәгате җитәкчелеген үз эшләрен намус белән башкаруларын таләп иткән гыйбарәнең язылган булуы ошамый. Нәтиҗәдә, ул җирле үзидарә вәкилләренә әлеге шәһадәтнамәләрнең таралуын булдырмас өчен ча-

ралар күрергә тиешлегән белдергән циркуляр бастырып чыгара, хәтта, 1926 елгы җинаять кодексының 125 нче матдәсен кулланып, әлеге таныклыкларны рәсми рәвештә тапшыруны тыярга тырыша. Тат ОГПУ вәкиле Хвостов хәбәр итүенчә, Әгерҗе мөхтәсибәте тарафыннан алынган 180 таныклыкның 64 экземпляры тартып алынган. Тат ОГПУ хезмәткәре Лобановка язган белдерү кәгазендә Спас кантонының прокурор ярдәмчесе Маланин: «Спас кантоны мөхтәсибәте тарафыннан дини эчтәлекле таныклыклар тапшыру законсыз гамәл буларак карала алмый, чөнки алар совет хакимиятенең тулы хокуклы органнары тарафыннан расланган Диния нәзарәте уставы нигезендә тапшырылган», – дип хәбәр итә. Ләкин шәһадәтнамәләрне законсыз рәвештә тартып алуларны күреп, Тат ОГПУ үзләренең хезмәтчеләренә: «… инде алынган таныклыкларны тартып алырга кирәк түгел, бәлки аларның киләчәктә таралуын кисәтергә кирәк», – дип боерык белдерә.

1931 елның 1 апрелендә милиция тарафыннан Октябрь районы Би күле авылы мулласының барлык дини китаплары тартып алына һәм яндырыла. Авылда яшәүчеләр тавыш куптарып, митингка җыела. Республика сайлау комитеты хезмәткәре Генидуллин В. халыкны көч-хәлгә тынычландыра ала, нәтиҗәдә, Үзәк Диния нәзарәтенә жалоба язарга кирәк, дигән карарга киләләр. Ләкин Диния нәзарәте нәрсә эшли ала соң? Ул үзе дә хөкүмәтнең репрессия чаралары басымы астында калган була.

Большевиклар Казан мөселманнарының малы белән дә бик кызыксына башлый. 1925 елның 10 сентябрендә тышкы эшләр наркомы Григорий Чичерин үзенең Татар республикасы Совнаркоматына язган хатында «изге урыннарда» Казан мөселманнары милкендә булган нинди әйберләр барлыгын хәбәр итәргә куша. Мәскәүгә юнәлдерелгән дипломатик белдерүдә түбәндәгеләр хәбәр ителә: Мәдинәдә бер мәчет, мәдрәсә, бертуган Дебердыевларның вакф сәүдә нокталары һәм складлары бар; Мәккәдә «Мурат әфәнде» һәм «Низаметдин әфәнде» тәккәләре

(дәрвишләр җыела торган урын), шулай ук башка биналар; Истамбулда да Казан мөселманнарының милкендә булган биналар бар.

*Ровель Кашапов*

# Мөкри Әбүбәкер[1]

Без тасвирларга җыенган Әбүбәкер Яһүдә улы Габдрәшитов 1840 елда хәзерге Татарстан Республикасы Чүпрәле районы Иске Шәйморза авылында туа. Ул вакытта авыл Сембер өязе Сембер губернасына караган. Әбүбәкернең әтисе Яһүдә һәм аннан элек яшәгән берничә буын барысы да руханилар булганнар. Ә нәсел башы (безгә билгеле булганнарның) Мостафа бабайны Шәйморзалылар Ислам дине кануннарын яхшы белүче буларак Пенза өлкәсеннән чакыртып алалар. Ул анда Төмән (Темников) өязеннән күчеп килгән була. Мостафа бабай килгәндә (17 гасыр башлары) авылда бер мәчет эшләп килә.

Мәчетләр эшчәнлеге белән бәйләнешле вакыйга авылыбыз башланып китүе вакытын ачыкларга ярдәм итте. Билгеле булганча, безнең авылларның 300 ел һәм аннан элегрәк тарихы буенча документлар бик аз, юк дәрәҗәсендә, чөнки архивлар Казанда да, Мәскәүдә дә янып беткән.

Патшабикә Анна Иоановна һәм аннан соң Елизавета Петровна вакытларында Казан губернасындагы барлык мәчетләрне исәпкә алалар. Биредә 291 нче номер белән Иске Шәйморза мәчете дә исәпкә алынган. Мәчет төзелгәнгә 100 ел дип әйтелә. Димәк, мәчет төзелү 1642 елларга туры килә. Ул елларда мишәрләр яңа авылларны мәчет төзелеше белән башлаганнар. Мәчетләргә кагылышлы документ сенатка тапшырылган һәм аның архивында янгынга эләкми калган. Шәйморзаның җир алу документы да 1645 ел

1 Мөкри – Коръән укучы; Коръән укырга өйрәтүче.




١ فیورال ـ ١٩١٤ سنه

١٨ ربیع الاول ـ ١٣٣٢ سنه

مشهور آدملر والوغ حادثه‌لر

مقرئ ابو بکر (*)

(شاه‌میرزا حضرت)

مشهور مقرئ ابو بکر، سمبر اویازی «ایسکی شاه میرزا» اسملی آولده امام و مدرس بولوب ٦٠ یاشنده وقتنده ١٣٢١ـ١٩٠٤ نچی یل ١٦ نچی ذوالقعده (٢١ نچی غینوار) ده وفات ایتدی. قبری اوشبو قریه مزارلغنده‌در.

**انسابی.** قوزنیتسکی اویازنده بولسه کیره‌ك «تومه‌ن» اسملی آولدن مصطفی تکلدیف اسملی بر آدم، یوقاریده ذکر ایتولگان «ایسکی شاه میرزا» قریه‌سینه کوچوب کیلگان ایدی. اوشبو مصطفی نك عبد اللطیف، سبحانقل، عبد الرشید، عبد الغفار اسمنده اوغلاری بولوب مونلردن ده عبد اللطیف ایله سبحانقل، اورنبورغ یاننده‌غی «قارغالی» شهرینه کوچوب کیتدیلر. «سعید» اسملی رساله‌ده «قارغالی» نك ٢ نچی یاشیل مسجد امام‌لری بیان ایدلگانده: «ایکنچی امام، اوزباك بن سبحانقل بن مصطفی» دیب ذکر قیلنغان اوزباك اوشبو سبحانقل اوغلیدر. عبد الرشید ایله عبد الغفار «ایسکی شاه میرزا» ده قالدیلر و هر ایکیسینك نسللری کوبدر. صاحب ترجمه ابو بکر، عبد الرشید بن مصطفی سلاله‌سندن بولوب آتاسی یهوذا بن یعقوب بن عبد الرشید و آناسی‌ده حسن جان بنت عبد الغفار ایدی. ابو بکر نك فاضل مرجانی‌غه قرابتی اوشبو آناسی حسن جان طرفندن ایدی.

(*) باصلماغان «آثار» دن صابلانوب آلندی.

**تحصیلی.** ابو بکر حضرتلری «زادور» قریه‌سنده فتح الله بن ولید حضورنده تحصیل ایتدی، صوڭره قازان شهرینه باروب مرجانی حضرتلرینك اصحابی آراسینه کردی. مرجانی تربیه‌سنده کوب سنه‌لر قالدی و ختم درس ایتدی. اوشبو وقتده «آدای» قریه‌سینه باروب طاهر حضرت حضورنده قرائت مشق ایتکان ایدی. ١٨٦٧ ده عربستان‌غه کیتدی و «مدینه» ده طوروب قرآن حفظ قیلدی. ایکنچی مرتبه حججدن صوڭ «مصر» غه کیلوب اون سنه مقداری علم ایله شغللندی. قرائت علمنده بولغان استاذی شیخ محمد المتولی الشافعی بولوب عبد الهادی نجا الابیاری، ابراهیم السقا، عبد الرحمن البحراوی، عبد القادر الرافعی، حسن الطرابلسی کبی الوغ ذاتلردن اجازت آلدی.

**امامتی.** ابو بکر حضرتلری ١٨٧٨ میلادی اییول آخرلرنده اوزینك وطنی بولغان «شاه میرزا» قریه‌سینه قایتوب مذکور قریه‌ده برنچی مسجد حضورنده ملا محمد علیم بن فتح الله غه شریك امام بولدی. امتحان قیلنور ایچون دیب «اوفا» گه باردیغنده «عتق» قریه‌سنده شیخ احمد اللطیف ایله ملاقات ایتمش و اوشبو مناسبت ایله مذکور شیخ اوز بالالرینی و شاگردلرینی مونك حضورینه قرائت مشق ایتدررگه یبارمشدر.

**مدرس و شاگردلری.** ابو بکر حضرت، اوکاز آلدیغندن صوڭ شاگرد تربیه‌سی ایله شغللندی و کوبره‌ك درسی اوزی

Р. Фәхретдиннең «Мөкри Әбүбәкер» мәкаләсеннән. «Шура» журналы, 1914 ел, 3 сан.

белән имзаланган һәм мәчетне исәпкә алу датасына тәңгәл килә. Димәк, авылның башланып китүе 1645 елларга туры килә.

Мәчетләрне исәпкә алу аларны вату-туздыру өчен эшләнә. Казан губернасында 536 мәчетнең 418е җимертелә.[1] Патшабикә указына тормыш өстәмәләр кертә. Себер һәм Әстерхан юлларын саклау кирәге килеп чыга. Бу эшне башкалар белән бергә Сембер сызыгын саклаучыларга, шул исәптән Шәйморзалыларга тапшыралар, шулай итеп авыл мәчете вату-җимерү эшеннән имин кала.

Менә шушы авылга Мостафа килеп төшә һәм җиң сызганып эшкә керешә. Крестьяннарның җир эшләре, хөкүмәт алдындагы бурычлары динебез кануннары белән берләшеп эшләп китәләр һәм уңай нәтиҗә бирәләр.

Мостафа тиз арада авылдашлар алдында абруй казана, аның вәгазьләре үтемле һәм Ислам диненең башкалардан өстенлеген яхшы ачыклап күрсәтә. Бу чорның эш нәтиҗәләре документларда сакланмаган, әмма алар халык күңелендә калганнар. Мостафа нәселе ишәя, зурая. Мулла-мөәзиннәр, хәлфәләр бер тирәгә төпләнәләр. Шуңа авылның бер төп урамы «мулла урамы» дип йөртелә башлый.

Мостафаның дүрт улы була, шуларның икесе – Сөбханкол һәм Габделлатыйф – Оренбург бистәсендәге Каргалы (Сеитов посад) авылына китәләр. Шунда соңрак Сөбханколның улы Үзбәк икенче «Яшел» мәчеттә имам-хатыйб булып таныла. Бу турыда язучы Г. Әхмәров искә ала[2].

Муллалар нәселендә туган Әбүбәкер башлангыч белемне әтисе һәм Задур авылында яшәүче Вәлит улы Фәтхулладан ала. Таләпчән һәм гадел Фәтхулла Әбүбәкердә тормышка дөрес караш тәрбияли, мөселман кануннарын төгәл үтәүне оештыра.

Шуннан соң укырга булган сәләтен күреп, үзенең омтылышын искә алып, Әбүбәкерне Казанга Мәрҗани мәчетенә юллыйлар. Әнисе ягыннан

[1] «Гасырлар авазы» журналы, 2004 ел, №2, 74-81 б.

[2] «Тарихи-документаль җыентык», «Хәтер» нәшрияты, 2000 ел, 267 б.

туган булганга күрә, ул остазның үз гаиләсендә яшәп, мәчет янындагы мәдрәсәдә белем ала.

Монда ул дәресне уңышлы үзләштереп кенә калмый, ә бәлки дәрәҗәле галимнәр белән аралаша. Күп укый һәм җымгыятебездә Ислам диненең зур көчкә ия булуына төшенә.

Шуларны искә алып, белемен Гарәбстанда тирәнәйтергә карар кыла. Мәдинә шәһәрендә укып, Коръән-хафиз булып кайта. Бераз вакыт әнисенең мәдрәсәсендә балаларга сабак биргәч, өйдәгеләр ризалыгын алып, кабат хаҗ сәфәренә юнәлә. Үзенең изге бурычын үтәгәч, Каһирәнең танылган Ислам университетына килеп, ун ел буена укып һәм эшләп, зур уңышларга ирешә, галим һәм мәгърифәтче булып җитлегә. Кыйраәт гыйлемендә булган остазы шәех Мөхәммәд Әл-Мөтәвәли Әш-Шәфигый булып, Габделһади Нәҗа Әл-Әбрари, Ибраһим Әс-Сәка һәм башка олуг затлардан белем ала.

Әбүбәкер хәзрәтләре 1878 елның июль ахырларында үзенең туган халкына һәм Исламга тугры хезмәт итү өчен Диния нәзарәтенә кайтып ирешә. Аңа башка җаваплы эшләр дә тәкъдим итеп карыйлар, әмма ул максатыннан тайпылмый, туган Шәйморзасына кайтып эшләүне мәгъкүл күрә.

Уфага указ алырга барганда күп авылларда муллалар белән аралаша. Муллалар яшь галимнең белемен, матур итеп Коръән укуын күреп, үз балаларын да Шәйморзага җибәрергә булалар. Шунда ул Р. Фәхретдин эшләгән авылда була, аның белән күп юнәлешләрдә фикер берлеген ачыклыйлар һәм шуннан соң бер-берсен югалтмый хат язышып торалар.

Яшь галимгә урыннардагы мәчет-мәдрәсәләр өчен муллалар һәм мөдәррисләр әзерләү бурычы йөкләнә. Аның таныклык бирү хокукы була һәм аларны рәсмиләштерү өчен мөһер бирелә. Эшне ул Иске Шәйморза үзәк мәчетенә караган мәдрәсәдә башлап җибәрә. Яңа бина төзелә, мөгаллимнәр туплана. Беренче елларда укучылар якын-тирәдәге авыл-



Әбүбәкер хәзрәт Габдрәшитов

лардан булса, берничә елдан Оренбург, Сарытау, Казан, Буа һәм Чистай, Уральск, Орск, Эстәрлетамак, Касыйм һәм Әстерханнан да шәкертләр һәм имам эшен камилләштерергә теләгәннәр килә.

Шәйморзаның һәм Әбүбәкернең даны еракларга тарала. Һәр елны Иделдә навигация ачылу белән Тәтеш һәм Ундыр пристаньнәре аша укучылар килә. Җәяүләп, атлар җигеп яисә самавырларын дөягә бәйләп шәкертләр килә. Шул елларда Шәйморза халкы гомердә күз күрмәгән экзотик хайван – дөяләр күрәләр һәм бу манзараны телдән-телгә күчереп әле дә сөйлиләр.

Җәй көннәрендә мәдрәсә һәм мәчет эчләре, манара һәм түбәләре, ихата эчләре шәкертләр белән тулы була, һәртөрле көй белән укылган Коръән тавышлары күкләргә кадәр яңгырый торган була, дип сөйли халык.

Төрле җирләрдән җыелган башкорт, типтәр, мишәр шәкертләре берберсе белән чәйдәш, казандаш һәм сабакташ, үзара дустанә булып, бер остазга буйсынырлар иде. Шуннан гомерлек дуслар булып аерылышалар иде.

Әбүбәкернең үзенә генә хас мәкаме булып, Русия мөселманнарының күңеленә бик хуш килә. Табигый һәм мөләем тавыш тыңлаучыларның күңелен яулап алып, рухи ләззәт бирә торган булган. Болар турында Р. Фәхретдин «Асар» китабында җентекләп яза[1].

Әбүбәкер Коръән укыганда аны кешеләр эчке бер тетрәү белән тыңлаганнар, күпләр, күңелләре тулгач, күз яшьләренә ирек биргәннәр. Кызганыч, бу Коръән уку ысулы хәзер инде онытылган.

[1] 3 том, 279 б.

1941-45 елларда сугыш вакытында Казанның Мәрҗани мәчетендә мулла булып Иске Шәйморзадан Мирза мулла Бәркиев торган.

Ул бәлки Әбүбәкер мәкаме белән укучы соңгы кешеләрнең берсе булгандыр. Аны Казан халкы да бик хөрмәт иткән. Мулла җәй көнәрендә Кече Шәйморзага минем бабам Усманов Кәлимуллага кунакка кайта торган иде. Совет заманы булса да, тирә-як авыл халкы аны чират торып хөрмәтләп мәҗлескә чакыра иде.

Әбүбәкер балаларны яңача укыту яклы була, хәтта дәреслекләр язып, шулар белән үзе укыта һәм хәлфәләрне өйрәтә.

Аның губерна дәрәҗәсендә дәүләт эшләрендә дә катнашуы мәгълүм. 26 ел эшләү дәверендә ул меңләгән шәкертне имам-хатыйб, мулла, мөдәррис итә. Кыска гына вакыт эчендә тагын өч мәчет һәм мәхәллә төзүгә ирешә. Авылда мәчетләр саны алтыга җитә.

Авылның кайбер имамнары читтән килеп эшлиләр. Мәсәлән, Камалетдин Фәхретдинов – Буа районы Черки-Дүртиле авылыннан, Галиулла хәзрәт Муллин – Ульян өлкәсе Кулатка авылыннан, Буа ягыннан Гаязетдин Мусин һ. б. Алар Шәйморза халкын яратып, үз итеп, үзләре дә шул авыл кешеләре булып беткәннәр, нәсел-ырулары да шунда яшәп калган.

Әбүбәкер губернада мөселманнар казые була. Бу җирлектә зурга киткән дәгъваларын тикшереп, шәригать кануннары нигезендә хөкем иткән, милләтара конфликтларны җайга салу һәм башка күп вазифалар башкарган.

Бер елны мәшһүр Мәкәрҗә ярминкәсенә имам булып барган (Түбән Новгород).

Мәшһүр Мәрҗани белән хат язышып торган. Р. Фәхретдин архивында Мәрҗанинең Әбүбәкергә Мисырга язылган 2 хаты сакланган. Бу хатларда олуг остаз Әбүбәкерне «туганым» дип атый. Хатларның берсендә тәфсирдә язылган бер риваять буенча ачыклык кертә, моннан тыш, Галимҗан Барудига арадашчы аша җибәрелгән китапларын тапшыру-

ны сорый. Бу хатлар ике арада элемтә регуляр алып барылганлыгын һәм Әбүбәкернең Г. Баруди белән дә якын аралашканы турында сөйли. Хатлар 1841 елның 27 июлендә һәм 1867 елның ноябрендә язылган. Без аңлаганча, бу вакытта Г. Баруди Мисырда булган.

Дин әһелләренең вәгазьләре һәм башка аңлату чаралары авыл крестьяннары общинасына уңай йогынты ясаган. Мәсәлән, XX гасыр башларында авыл мәчетләре төзелеп бетеп, бай крестьяннар Сираҗетдин Бәхтиев һәм Бәрхиевләрнең берсе (алар күп, нәкъ кайсы икәне билгесез) Түбән Чәке авылы мәчете төзелешенә ике меңешәр сум акча биргәннәр. Кече Шәйморза авылы мәчете төзелешенә булган чыгымнарны үз өстенә Вәлиулла Бәрхиев ала.

19 гасыр ахырында авылда иген уңмау сәбәпле ачлык еллары булган. Шәйморзаның хәлле крестьяннары шул вакытларда халыкка зәкәт итеп иген өләшкәннәр, авылда ачтан үлү очраклары булмаган. Зәкәт алырга тирә-як авыл халкы да килгән. Хәтта урман асты кешеләре дә (60-80 чакрым) килгәннәр. Таныш булмаган кешеләр булгач, хәрамләшү булмасын өчен, аркаларына акбур белән номер сала торган булганнар.

Хәзрәтнең гаилә хәленә килгәндә, ул 1879 елда Яңа Тингәле авылы мулласы Габделлатыйф Яһүдә улы Биккуловның Мәрфуга исемле кызына өйләнә. Бу хатыны 1887 елда вафат була. Аннан соң икенче кызы Фатыйманы никахлый. Әйтергә кирәк, Мәрфуга һәм Фатыйма безнең якларда бик танылган язучы Касыйм Биккулов һәм җәмәгать эшлеклесе Ибраһим Биккуловның әтиләре Җамалетдин белән бертуганнар. Фатыйма да 1896 елда үлеп китә. Моннан соң Шәйморзадан сәүдәгәр Бәхтиев кызы Гайшәне никахлый. Инде бу хатыны да 1900 елда бала тапканда вафат була.

Улы Мөхәммәд беренче хатыныннан, Гайшәдән кызы Өммегөлсем кала. Аны бабасы Сираҗетдин тәрбиягә ала, ул байның улы Зариф карамагында булып, яшьтәш кызлар белән бергә үсә.

Билгеле булганча, мәчет-мәдрәсәләребез электән тәрбия һәм белем учагы булып саналганнар. Аларның эшчәнлеге һәрвакыт губернатор күзәтчелеге астында булган.

1898 елда шундый тикшерүгә Әбүбәкер мәчет-мәдрәсәсе дә дучар ителә. Сембер губернасы мәгариф өлкәсендә баш инспектор А. Афанасьев тикшерү нәтиҗәләренә багышланган отчетта түбәндәгеләрне язып калдыра:

«Окончив образование в медресах, шакирды нередко поступают в высшие мусульманские училища в Казани и Уфе, где проходят полный курс богословской науки.

Потом направляются либо в Аравию и Персию, либо в Бухару, иногда в Египет для получения высшего духовного образования и должности имама-хатыпа, мударриса, муллы и другие.

Правда, очень немногие проходят указанный путь получения образования. Но зато эти немногие приобретают репутацию ученых ислама. Толпа слушает их как пророков, как представителей высшего, недоступного людям видения.

Мне привелось беседовать с одним из таких имамов в д. Старое Шаймурзино Абубакиром хазратом.

Я немного удивился богословской эрудиции и его глубочайшей вере в абсолютную святость и превосходство мусульманства и тому благоговению, с каким вниманием слушали его простые люди.

Жаль, что переводчик, через которого я беседовал с муллой, иногда затруднялся переводить его речи, находя их слишком высокими для неподготовленного понимания».

Язмадан күренгәнчә, рус дәүләтенең дәрәҗәле чиновнигы А. Афанасьев, ислам диненең һәрьяклап кыерсытылган чорында, Әбүбәкер хәзрәтнең үз-үзен аямыйча, ифрат бирелеп һәм нәтиҗәле эш башкаруын

таныrга батырчылык иткән. Бу отчетның күчермәсе авыл музеенда саклана.

Р. Фәхретдин түбәндәгеләрне язып калдыра:

Әбүбәкер хәзрәт мөстәкыйль фикер йөртүче, гайбәт сөйләүне һәм ялагайлануны сөймәс кеше булып таныла, бервакыт ялган сөйләмәс. Буш вакытларын дини, фәнни һәм әдәби әсәрләрне диккать белән укып уздыра. Яңа китаплар, басмалар белән кызыксына. Ниндидер яңа китап басылуын ишетсә, кеше аша булса да алдырырга тырыша, мондый эшкә акча жәлләми торган була. «Дөньяда яшәү өчен рәсми булган хөкүмәт телен һәм әдәбиятын белү кирәк», – дип халык арасында барган бәхәскә үзенең фикерен ачык итеп әйтә. Яшь вакыттан хәзерлеге булмаса да, картайгач тырышып, русча сөйләргә һәм газета-журнал укырлык дәрәҗәдә рус телен өйрәнә.

Әбүбәкер ифрат дәрәҗәдә гадел кеше булган, нахакка кеше рәнҗетүчеләрне күрә алмаган. Үзенә кагылган усал ниятле кешеләрне зирәк җавап белән бастырган, мондый ниятләрне алдан хәзерлек күреп, юлларын яба торган булган.

Мәсәлән, 1897 елда булган перепись вакытында бар халык «чукындырырга хәзерләнәләр» дип тавыш чыгарган. Бу шартларда Шәйморза авылының тыныч калуы – имамнарның дөрес аңлатуы нәтиҗәсе.

Әбүбәкер үзенең шәкертләрен яраткан, бервакытта да аларны кыерсытырга бирмәгән. Ул масаючан кеше булмаган, эш нәтиҗәләре булса да, бервакытта да мактанмаган.

Габдрәшитов Әбүбәкер Яһүдә улы – имам-хатыйб, мөдәррис, казый, Ислам галиме – 1904 елның 21 гыйнварында каты авырудан соң алтмыш дүрт яшендә вафат була. ТР Чүпрәле районы Иске Шәйморза авылы зиратында дәфен кылына.

Аның эшчәнлеге матбугат чараларында һәм китап-журналларда яктыртылган. Мәсәлән, Ш. Шәрәфнең 1915 елда чыгарылган «Ш. Мәрҗани»

китабында Әбүбәкер турында бик җылы һәм халык файдасына хезмәт итүе турында язылган. Р. Фәхретдин Әбүбәкернең вафатына 10 ел узу уңаеннан 1914 елның март аенда «Шура» журналының тулы бер номерын аңа багышлый. Хәзерге вакытта 1998 елда Казанда булып узган конференциядә (галим Р. Әмирхан) Әбүбәкер хәзрәт эшчәнлегенә югары бәя бирә. 2010 елда «Рухият» нәшриятында басылып чыккан Р. Фәхретдиннең «Асар» китабында Әбүбәкер эшчәнлеге шактый киң яктыртылган. Аңа булган рәхмәтләребез дога булып барып ирешсен иде. Моннан башка соңгы унлап елда район газетасында бер мәкалә, Чаллыда чыга торган «Ислам нуры» газетасында бер мәкалә дөнья күрде.

Бүген, динебез кабат күтәрелгән чорда, хәзрәтнең нәтиҗәле эшчәнлеге тәҗрибә булып куллануга лаек. Заманында Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдин, Г. Барудилар белән иңгә-иң эшләгән дин галиме Әбүбәкер Яһүдә улының эшчәнлегенә игътибар кими төште кебек.

Якташлары менә бер гасырдан артык инде аның васыятьләренә тугры булып яши. Аның киң колачлы эшчәнлеген, гыйбрәтле гамәлләрен һәм фикерләрен онытмыйча күңел түрендә саклый.

Үлүенә 120 еллап вакыт узса да, авыл зиратындагы кабере һәрвакыт каралган, чистартылган. Күпсанлы шәкертләренең берсе Ибраһимов Йосыф (Йосыф мөәзин) үзе бик авыр тормышта яшәсә дә, Ходайның һәр бирмеш көне, һава шартларына карамый, хәзрәтнең кабере янына барып догалар укый торган булган. Тормышы авыр булганга, Ульянда яшәүче 2 улы Йосыфны шәһәргә алып китәргә уйлыйлар. Әмма Йосыф: «Хәзрәтемне беркемгә дә ташламыйм», – дип тәкъдимне кире кага. Йосыф мөәзин 1969 елда вафат.

Хәзрәт каберенә сукмак бервакытта да өзелми. Аның 2 баласы да репрессия корбаннары. Мөхәммәд ялган донос нигезендә 1930 елда кулга алына һәм шуннан кайта алмый. Өммегөлсем гаиләсе белән фатирла-

рын ташлап, Урта Азиягә китеп котылалар, гомер буе куркыныч астында яшиләр.

Әбүбәкернең бай китапханәсе юкка чыккан. Әтисе үлгәндә улы Мөхәммәд Төркиядә була. Әтисенең соңгы өйләнгән хатыны тиздән өеннән һәм авылдан чыгып китә. Якын туганнары, хәзрәтнең китаплары, тарихи язмалары, дин гыйлеме буенча булган хезмәтләре юкка чыгуында шушы хатыны гаепле, дип сөйләп калдылар.

1929-30 елларда Мөхәммәд үзе кулга алынып, йорт-җире, барлык мал-мөлкәте, терлекләре дәүләт файдасына тартып алына. Китапханә тулысынча тар-мар ителә. Анда, мөгаен, К. Биккулов искә алган нәсел шәҗәрәсе, авыл тарихы да булгандыр. Алар берсе дә сакланмаган.

Хәзер бик зур авырлыклар белән бу мәгълүматны яңадан торгызу өстендә эшлибез, үзем дә шушы нәсел кешесе.

Хәзрәтнең ике баласы ягыннан да оныклары һәм онықчыклары репрессия дулкынына эләккән һәм авыр тормыш шартларында яшәгән кешеләр булса да, барыбер җәмгыятькә кирәкле шәхесләр булып җитешәләр. Шәйморзалылар кебек үк ел саен диярлек (Урта Азиядән сирәгрәк), бабалары каберен зиярәт кылалар.

Шәрипов Салих һәм Габдрәшитова Розалина шушы соңгы елларда бабалары кабергенә истәлек ташы куйдылар. Авылдагы дини бәйрәмнәр, мәҗлесләрдә һәрвакыт хәзрәт рухына дога укыла.

Тарихи мәгълүматлар, халкыбызның буыннан-буынга сакланып килгән риваятьләре Әбүбәкер бин Яһүдә бин Ягъкуб бин Габдрәшит хәзрәтләрен бик тырыш, ифрат матур мәкамгә һәм камил акыл, зур сәләткә ия булган зур галим, мөдәррис, казый һәм күренекле шәхес итеп раслыйлар.

*Минзаһит Гимадеев, Яр Чаллы шәһәре,*

*«Авылым хәтирәләре», «Үткәннәр эзеннән» китаплары авторы,*

*«Шәйморза» китабы соавторы, КамАЗның атказанган хезмәткәре*

# Дүрт ягым кыйбла: Арчаның тарихи халкына бер сәяхәт

(Дәвамы)

Арча ягының борынгы галимнәреннән тагын да берсе – Ашыт авылында имам-мөдәррис Сәйфелмөлек улы Габденнасыйр, Мортаза улы Мозаффар мулла нәселеннән булып, ул бабасы хәзерге Чүпрәле районы Чокал авылы имамнарыннан икән. Габденнасыйр имам җитмеш биш ел гомер кичереп, 1833 елда вафат була.

Ул Шырдан мәдрәсендә укый, аннары тагын берничә мәдрәсәдә белем алып, данлыклы Оры авылында Хәбибулла ишан мәдрәсәсенә килә, анда мөритлек мәртәбәсе ала, берара Ашытта мәдрәсәдә укый. Зур белемнәр иясе булып җитешә. Ашытта аны имам-мөдәррис итәләр. Мәдрәсәсе даны тиз арада тирә-якларга тарала. Аңа Казан, Буа, Сембер якларыннан шәкертләр килә, Бәһаветдин Мәрҗани дә, Шиһабетдин Мәрҗанинең атасы, аңарда укый.

Сәйфелмөлек улы Габденнасыйр имам хак сөйләүче, иманы дөрес, гамәлендә шәригать кушканча эш итүче, гадәти тормыш белән яшәүче булган. Заманында Хәбибулла ишанга мөритлек итеп, аңардан иҗазәтнамә яздырып алса да, аны, ишан белән мөфти арасындагы дошманлык сәбәбендә булыр, яшереп саклаган һәм кешеләргә бер генә дә күрсәтмәгән.

Хатыны Мәхбүбә исемле булып, Туктамыш байның кызы икән. Күп балалар үстергәннәр. Мәхбүбә, иреннән соң калып, 1842 елда вафат булган. Кабере Ашыт зиратында.

Габденнасыйр Ашыти бик тә диндар кеше икән. Аның әүлиялек сыйфатлары да күренгән, изгелек һәм чисталык-гыйффәт һәммә чалымнарыннан сизелеп торган.

Аның җеназасында олы имамнар катнаша. Арадан Сөбханкол Мәрҗани улы Баһаветдин, аның укучысы һәм Шиһабетдин Мәрҗанинең атасы: «Ашыт зиратында вәли кабере бар. Халык, ышанып, аның каберен зиярәт итеп йөрсәләр дә, бу көн бу вәли дәфен кылынды»,– дип әйткән, ягъни, тагын бер изге кешенең кабере өстәлде, дигән.

Ул заманнарда «вәли зираты» дип хәзер «изгеләр зираты», «әүлия күмелгән җир» дип йөртелгән каберлекне әйткәннәр. Мәсәлән, Биектау районы Камай (Иске Казан) авылы каршында, Чагыл тау башында, Төньяк тарафта Изгеләр зираты бар, анда мәчет салганнар, чардуганнар корганнар, чишмәсе дә матур итеп эшләнгән. «Анда Мулла хаҗи күмелгән», – диләр. Иске заман Сәрдә имамнарының бу зират белән бәйле гаугалы гамәлләре хакында документлар аша безгә килеп ирешкән хәбәрләрдән күренгәнчә, анда Әремле хуҗа һәм аның кызы Гайшәнең гүрләре икән. Ерак түгел урнашкан Айшә авылы да шул Гайшә-бикәгә нисбәтле булса кирәк. Әмма Казан артында Гайшә каберләре берничә урында. Аларда чыннан да Гайшә исемле изге кеше күмелгәнме, әллә гомумән дә изге хатын-кызны Гайшә исеме белән атау тәртибе булганмы – бу мәсьәлә ачыкланыр. Күз тиюләрдән «Фатыйма кулы саклый», диләр. «Гайшә-бикә кабере» дигәннәре дә, халык уйлавынча, шундый бер ырым-күзаллауларга бәйле, хикмәткә ия түгелме икән?

Бу Әремле хуҗа бу яклар кешесе түгел. Хаҗданмы кайтышы икән, башкамы? Аның «хуҗа» дип аталуы бер-бер әүлия-ишан кебек бөек кеше булганлыгы хакында сөйли. Себер татарларыннан түгел идеме икән?

Арча ягының борынгы галимнәреннән тагын да берсе – Олы Мәңгәрнең имамы Кытый улы Сафкол хәзрәт. Төп чыгышы белән ул Кырым татары булган. XVI гасырда аның бабасы сугышта әсир төшеп, монда китерелгән, аны Килмәк исеме белән атаганнар. Оныгы Сафакол, гыйлемдә алай ук маһир саналмаса да, диндарлыгы, тәүфигы белән халыкның мәхәббәтен яулап алган. Коръән һәм догалар укыганда ясаган

хата һәм кимчелекләре өчен, дога артыннан өстәп, аерым бер гафу үтенү («укыганда ясаган хата һәм кимчелекләребез өчен гафу әйлә» дип сорау) гадәтен догачылар теленә ул керткән. Кыска төннәрдә ясигъ намазын ташламаска, витр намазларын да укып барырга халыкны өндәгән. Мөфти каршындагы «Җәмгыяте-шәргыя»да берничә тапкыр әгъза булып торган, Габдессәлам мөфтинең хөрмәтен казанган.

Сафкол хәзрәт озын буйлы, олы сакаллы, мәһабәт кешеләрдән икән. 1835 елда 78 яшендә вафат булган. Балалары да имамлык дәрәҗәләренә ирешкәннәр, ә икенче улы Мөхәммәт аның урынында муллалык иткән.

Бу якларның тагын бер галиме – Габденнасыйр Курсавиның олы абыйсы Габделхак. 1843 елда вафат була, Курсада җирләнгән. Шушы авылның таш мәчетендә имамлык хезмәтендә торган, мәдрәсә тоткан, анда мөдәррислек иткән.

Яшьлегендә үз авылларында һәм төрле зур мәдрәсәләрдә белем алгач, Бохарага китә һәм Ниязколый Төрекмәнинең мөрите хезмәтендә тора.

Хаҗ сәфәренә Габденнасыйр һәм Габделкәрим исемле туганнары белән бара. Әмма берникадәр вакытка Каһирәдә кала һәм монда тәҗвид гыйлеменнән дәресләр ала. Коръән укуда аның кебек оста кешеләр булмаган, диярлек. Шәкертләрен бу гыйлемгә өйрәтүгә күп көч куйган. Коръәнне дөрес уку серләрен Диәрбәкер[1] мөфтисе Әбү Сөгуттан өйрәнгән. Башка төрле рухани гыйлемнәрдә үзенең остазы дип энесе Габденнасыйрны санаган. Хәдисләр китабы төзеп, аны китапчылар бик еш бастырып тараткannар, алардан файда тапканнар.

Габделхак хәзрәт шәкертләренә Коръәнне хатасыз, камил рәвештә өйрәтеп, аятьләргә һәм хәдисләргә дөрес һәм тугры шәрехләр бирә, бу мәсьәләләрдә катгыйлыкны, җаваплылыкны таләп итә торган булган.

[1] Төркия шәһәре.

Вафатыннан соң имамлык эше Газизә исемле кызының ире Хәмит улы Хәсәнгә кала.

## VI

Мондый да зур һәм танылган галимнәре белән дан алган Арча якларында борынгы китаплар, кулъязмалар йорт саен очрарга, кешеләре дә үзләрен белемле, укымышлы итеп күрсәтергә тиеш иделәр. Мине ул өмет күп авылларда йөртте. Байкалдан Чурабашка, аннан Шурага, Шушмабашка, Сәрдәбашка барып чыктык. Авыл администрациясе башлыгы Вәзир Вазыйх улы Сәгыйтовка рәхмәт, ул мине «Яхъя угылы Болгари» каберенә алып килде. Аның кабер ташы Үгез-Елга авылыннан төньяктагы тауда иде. Тирә-ягы – киң басу. Бу урынны әүлия зираты дип йөртәләр икән. Ташына вафаты мең дә тугыз йөзенче елның июле буларак күрсәтелгән. Яхъя улы Болгари үз заманында шактый күп китаплар язган. Әмма фәндә алар әлегә Яхъя ишанга нисбәт ителә. Ә ул Шекә авылында яшәгән һәм кабере дә шунда. Аны да күреп китү мөмкинлеге бар.

Вәзир әфәнде безне Шекәгә алып китте. Яхъя бине Сәфәр бине Арыслан Әл-Бәрәзәвинең, ягъни Яхъя ишанның, кабере авыл зираты уртасында икән. Урам яктан ап-ак мәрмәр таш кебек күренә. Эчкә узып, янына барсак, гап-гади, измә белән катырып эшләнгән таш кына икән. Сөләйман пәйгамбәрнең йөзеге дә балчыктан булган, диләр...

Юлыбыз башка көннәрне Апаз, Каргалы, Пөшәнгәр, Хәсәншәех, Ташкичү, Мәмсә һәм башка авылларда булды. Әйе, тәрбияле, укымышлы яклар. Соклангыч халык икән бу арчалар!

Әмма күңелдә калган, аны тырнап торган нәрсәләр дә кала. Бу Оры авылы туфаны мәсьәләсе иде, аның чынлыкта булуы яки булмавы һәм нигә бу якларга аңа шушы кадәр игътибар бирүләре. Әллә ул халык уйдырмасы гынамы?

Моны аңлар өчен миңа Хәбибулла ишанга бәйле вакыйгаларны яңадан бер тикшереп чыгарга кирәктер, дип уйладым.

Оры авылында Хәбибулла ишанга каршы куелган, аның көндәшенә әверелгән Фәтхулла хәзрәт, – ә ул Хәбибулла ишанның бертуган энесе әле, җитмәсә, – гыйлемдә һәм дәрәҗәдә кечкенә кешеләрдән булмаган. Ул яшьлегендә Оренбургның Каргалысында шактый күп вакытлар дәресләр ала, аннан Бохарага китеп укый. Аннан кабат Оренбургка кайта. Монда байларның мәҗлесләрендә була, аларның күңеленә хуш килә. Бер елдан Оры авылына әти-әнисе белән күрешергә дип җибәрелә. Әмма ул монда, асылда, Мөхәммәдҗан мөфтинең кушуы буенча кайта. Аңа Оры авылы байлары күңеленә вәсвәсә салу, аларны Хәбибулла ишанга каршы котырту эше дә йөкләнелгән булса кирәк. Чөнки ул кайтып озак та үтмәгән, халык арасында төрле сүзләр тарала башлаган. Хәбибулла ишан үз туган энесе Фәтхуллага зур ышаныч белән караган, аның бәлаләр китерәсен башына да кертмәгән.

Мөфтинең эшен әлегә суд-мәхкәмә тикшергән арада, аның урынына Хәбибулла ишанны күтәрергә уйлаган татар байларының нияте мөфтияткә билгеле була. Шәхесенә дә, тәхетенә дә, дәрәҗәсенә дә куркыныч янаудан коты алынган Мөхәммәдҗан мөфти Хәбибулла ишанны юк итәргә карар кыла. Моның өчен вакытын да, байлыгын да кызганмый, һәртөрле мәкерле юлларны файдалана башлый. Ул бәддогаларын, каһәрләүләрен әйткән дә юк инде... Ә Хәбибулла ишан үз өстенә ябырылган бәлаләрнең, җәбер-золымнарның нинди көчләр белән тудырылганын уена да кертә алмый. Бертуган энесе Фәтхулла хәзрәткә ышанычы зур. Ә ул – мөфтинең кешесе.

Һәм менә Мөхәммәдҗан мөфти белән Хәбибулла ишан арасындагы каршылык зурайганнан-зурая. Оры байлары Фәтхулла хәзрәткә ияртә. Вакыйгалар озак көттерми, чишелеш тиз килә. Хәбибулла ишанны юк итүнең беренче нәтиҗәсе – аны имамлыктан төшерәләр. Аның урыны-

на 1799 елда Фәтхулла хәзрәтне Орының таш мәчетенә имам булырга мөфтинең указы кабул ителә. Шунда гына энесе Фәтхулланың кем булуын Хәбибулла ишан аңлап ала.

Фәтхулла хәзрәт, мөфтинең үз кешесе буларак, илдә сүзе үтә торган кешегә әверелә. 1814 елда ахун дәрәҗәсенә күтәрелә. 1819 елда указ белән Арча ягының бөек имамы («страший ахунд») ителә. Шулай итеп, рәсми нигездә ул җәмигъ мәчете имамы, мөдәррис (профессор), мөхтәсиб, өлкән ахун дәрәҗәләрен йөртә башлый. Хәбибулла ишанга, аңа тугры кешеләр табылып, агач мәчет төзеп бирәләр. Ул шунда, авылның ярлы өлешендә, мәчет мулласы ролен башкара. Элекеге туннары туза, чаналары, арбалары, атлары бетә. Аны кешеләрнең көнчелеге, махсус рәвештә бутавы юкка чыгара. Ә Фәтхулла хәзрәт көннән-көн чәчәк ата. Мөфтинең аңа карата мәхәббәте һәммә нәрсәдән өстен булып чыга.

Хәер, Фәтхулла хәзрәт үзе дә төшеп калганнардан түгел, ул, ни гаҗәп, матур телле, фикерләрен ачык белдерүче кешеләрдән була. Аның хәтта берничә әсәр һәм китап язуы билгеле. Шулардан берсе – «Рисаләте фи иттисафул-вәҗиб бил-вәхдәтүл-гаддийәт», ике сәхифәдән гыйбарәт, гарәп телендә, ачык аңлаешлы һәм төзек итеп язылган. Икенче хезмәте – «Рисаләте мөһиммәт», 1872 елдан бирле Казанда еш басылган 15 битле китап. Анда ураза мәсьәләләре тикшерелгән. Өченче китабы – «Мәҗмуг». Бу китап 25 бүлектән һәм 798 сәхифәдән гыйбарәт, күләмле хезмәтләрнең берсе. Ул төрле китапларның асыл нөсхәләреннән алынган җыелма хәбәрләрдән, хашия-аңлатмаларны киңәйтеп язудан гыйбарәт булып, анда хәтта Себер һәм Урта Азия ханнары Шәйбаниләр нәселеннән имам Хәсән улы Мөхәммәтнең «Җәмигуль-гараиб» китабыннан алынган материаллар да бар, алар барысы да күрсәтелеп барылганнар һәм урыны-урыны белән бәхәс тә ителгәннәр. Бу хезмәтендә ислам дине кануннары, Коръән һәм тәфсирләр, әхлак, медицина һәм башка мәсьәләр белән бәйле

хәбәрләр җитәрлек. Әмма алар берсе дә аерым бер ачык максатлы фикер нигезендә бәян ителмичә, җыелма хәбәрләр бирү юлы белән төзелгәннәр.

Фәтхула хәзрәтнең болардан тыш та шактый китаплар язуы билгеле. Алар һәммәсе дә шушы «Мәҗмуг» рәвешендә төзелеп, ислам динендә булган татар халкының гореф-гадәтләре яхшылыгын аңлатып бирүләрдән, ничек гамәл кылганда дөрес һәм күркәм икәнлеген ачыклап сөйләүләрдән гыйбарәт. Бер генә фикере дә мөселман кешенең иманына, әхлагына, табигатенә зыян итәрлек түгел. Башкача була да алмый. Мөфтинең мәрхәмәте кочагында, муллыкта һәм байлыкта яшәгән кеше түгелме ул?

1819 елда Диния нәзарәтенә Фәтхулла хәзрәтнең язган хатыннан аңлашылганча, Оры авылының таш мәчете халык акчасына салынган, кырык ел буена монда җомга һәм гает намазлары укылып киленгән. Хатта Хәбибулла ишанның агач мәчет төзетеп, шунда җәмәгать белән азансыз гына намазлар укуын, инде аның вафат булуын да хәбәр итә.

Һәм менә ул үз янәшәсендә һичкемне таныргa теләмәвен авылда таш мәчетне генә калдырырга кирәклеген дәгъвалавында сиздерә. Агач мәчеттә намазларның азансыз укылуын шәригатьне бозу буларак аңлата. Бу хакта ил халкына хәбәр итүне үтенә. Монысы – Хәбибулла ишанның рухын юк итү теләгеннән, әлбәттә.

Картайган көнендә Фәтхулла хәзрәт үз мәдрәсәсенә мөгаллим итеп Казан шәһәренең алтынчы мәчете каршындагы мәдрәсәдә хәлфә хезмәтендә торган Габделкадыйр имам улы Сибгатулланы чакырта. Ул Оры авылына күченеп килә. Үзен намуслы, гадел, тәртипле һәм галим зат буларак таныта. Фәтхулла хәзрәтнең вафатыннан соң, рәсми рәвештә имам һәм мөдәррис дәрәҗәләрен ала. 1873 елда 75 яшендә Орыда вафат була. Сәламәт вакытында ук үз урынына улы Вәлиулланы имам итә. Тирә-күрше авылларда болар нәселеннән муллалар тарала. Мәдрәсәсе яхшы, укымышлы, тәрбияле муллалар әзерләгән.

Оры авылын агызып киткән туфанның 1817 елда, Хәбибулла ишан вафатыннан соң булуын искә алсак, аның авыл халкын агызып алып китүенә дә игътибар итсәк – барысы да аңлашыла. Авылдагы байларның завод-фабрикалары да, буалары һәм биналары, җитештергән товарлары белән бергә аккан. Әмма ак бабайга эчәргә су биргән бер кыз гына исән калган, диләр.

Халык белеп һәм аңлап сөйли ул, без генә барысын да кирәгенчә төшенеп җитә алмыйбыз.

*Фәрит Яхин, профессор,*

*филология фәннәре докторы*

# Нәсыйхәт

# Юмартлар җәннәткә беренче керерләр

## Юмартлык нәрсә ул?

Юмартлык – Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтләргә шөкер итү, җәлләми бирү, биргән өчен берни көтмәү. Фәкыйрьлектә азга канәгать, бай хәлендә исә ихтыяҗы булганнарга ярдәм итү, Аллаһы Тәгаләгә һәм Аның колларына якын булу. «Юмартлык йөрәкләре иман нуры белән нурланган кешеләргә хас. Юмартлык ул җәлләмичә, ләкин кирәгеннән ашу булмаган күләмдә малыңны кирәк булган урыннарга, үзеңә, якыннарыңа вә мохтаҗларга сарыф кылудыр».[1]

Шулай ук, юмартлык ул – ачык күңеллелек, акча-малны хәерле җирләргә, шәригать кушканча сарыф итүдән ләззәт алу, сөенеп Аллаһ ризалыгы өчен ярдәм итү. Моңа каршы сыйфат – саранлык – мескенлек һәм фәкыйрьлектән куркып мал җыю, Аллаһтан һәм кешеләрдән ерагаю, җәһәннәмгә якынаю.

«Бел, акча билгеле бер максатларда кешеләрнең ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен яратылган. Сарыф итү кирәк булганда акчаны сарыф итмәү саранлык була, ә кирәк булмаганда сарыф итү исраф дип атала. Алар икесе арасындагы уртача юлны алып бару гына мактаулы санала».[2] Шул урта юл юмартлыкны аңлата. Юмарт булу өчен кулың белән биреп, йөрәгең-күңелеңнең шуңа риза булуы кирәктер.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә боера:

**«Кулыңны үз муеныңа бәйләмә (саран булма); кулларыңны җәеп тә җибәрмә (артыгын юмартланма да). Ахырда (саран дип)**

[1] Якупов В. Вәгазьләр. – Казан: Иман, 2011. – Б.70-71.

[2] Мөхәммәт Җамалетдин Әл-Касыйми. Мөэминнәргә нәсыйхәтләр. – Казан: «Матбуган йорты» нәшрияты, 2004. – Б.267.

**сине ачуланырлар, (малыңны туздырып) син бичара хәлдә калырсың».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:29

**«... алар сарыф иткәндә исраф кылмыйлар һәм саранланмыйлар, мондый чикләргә төшмичә уртача булалар...»**

«Фуркан / Аеручы», 25:67

## Сарыф итү төрләре

Саранлык һәм юмартлыкның нәрсә икәнен белү һәр мөселманга лаземдер. Чөнки кеше үзен юмарт дип уйлап, башкалар аны саран исәпләргә мөмкин. Моны аңлау өчен сарыф итү төрләрен карап үтәргә кирәк.

«Кешеләргә сарыф ителә торган нәрсәләр дүрт төркемгә бүленәләр: сәдака, юмартлык күрсәтү, намусны саклау, кеше хезмәтен кулланган өчен түләү.

Сәдакага килгәндә, мәгълүм булганча, кешегә аның өчен әҗер була.

Юмартлык күрсәтү дигәндә, без малны байларга һәм мәшһүр кешеләргә сарыф итүне, ягъни аларга карата кунакчыллык күрсәтүне, бүләкләр бирүне, ярдәм итүне күз алдында тотабыз. Боларны сәдака дип санап булмый, чөнки сәдака мохтаҗ кешеләргә генә бирелә. Шулай булса да, бу нәрсәләр ярдәмендә кеше дуслар, кардәшләр тапканга күрә, ул сарыф итүләр дингә файда китерәләр. Моннан тыш, болар ярдәмендә кеше үзендә юмартлык сыйфатын булдыра. Юмартлык күрсәткән өчен дә зур әҗер булачак. Бик күп хәдисләрдә бүләкләшү, кунакчыллык, кешеләрне сыйлау турында сөйләнә. Әмма мондый очракларда бары тик мохтаҗларга һәм ярлыларга гына сарыф итәргә кирәк дигән хәдисләр юк».[1]

[1] Мөхәммәт Җамалетдин Әл-Касыйми. Мөэминнәргә нәсыйхәтләр. – Казан: «Матбуган йорты» нәшрияты, 2004. – Б.258.

«Мәҗбүри сарыф итүләр ике төрдә булалар: шәригать буенча тиеш булган сарыф итү һәм юмартлык, гадәт сәбәпле сарыф итү. Бу ике төр сарыф итүне дә үтәүче юмарт була. Беренчесеннән яки икенчесеннән баш тартучы саран санала. Ә шәригать боерган җирләргә сарыф итүдән баш тартучыны, мәсәлән, зәкәт түләмәүче, гаиләсен тәэмин итмәүчене иң саран дип әйтеп була.»[1]

Кыямәт көнендә түбәндәге сарыф итү өчен хисап соралмас:

– әти-әнигә тоткан акча-мал өчен;

– ифтар үткәрүгә киткән акча өчен;

– сәхәр ашатырга тотылган мал өчен;

– гаилә әһеленә, өй кирәк-яракларына, балаларына сарыф ителгән мал өчен.

## Юмартлык күрсәтүнең әдәбе

Ризаэтдин Фәхреддин әйтүенчә: «Бер үк җәмгыятьтә төрле кешеләр яши. Алар арасында көчлеләр дә, зәгыйфьләр дә, байлар да һәм ярлылар да, кечкенәләр дә вә олылар да, галимнәр дә вә наданнар да бар. Кеше, дөньяда никадәр бай, никадәр көчле-куәтле булса да, бер үзе генә яши алмас иде. Ул башка кешеләрнең ярдәменә дә мохтаҗ. Шуның өчен динебез үзара ярдәмләшүне фарыз кылган».[2] Юмартлык һәм ярдәмләшү Коръән һәм хәдисләрдә дә мактала. Хәсән ибн Гали: «Киң күңеллелек – башкалар синнән сораганчы ук шәригать хуплаган нәрсәләрне үз теләгең белән кылу; уңайлы вакытта кешеләрне кунак итү; сораучыга карата мәрхәмәтле булу һәм бирүченең юмартлыгы ул», – дигән. Бу уңайдан, Имам Әш-Шәфигыйның әйткән сүзләре игътибарга лаек: «Өч иң яхшы гамәл: фәкыйрь чакта юмартлык күрсәтү, ялгыз чакта тәкъва булып калу һәм кешеләр куркып торган адәмгә хак-дөресен әйтү».

1 Шунда ук, Б.267.

2 Балаларга үгет-нәсыйхәт. – Казан: «Дом печати» нәшрияты, 2001. – Б.67.

Юмартлык әхлагының әдәб-этикетын кыскача түбәндәге рәвештә сурәтләргә мөмкин:

– ярдәм итү иң әүвәл Аллаһы Тәгалә өчен һәм Аның юлында булырга тиеш, фәкать Аллаһ ризалыгын алырга тырышкан өчен әҗер-савап бирелер; мөэминнәрне сыйфатлаганда Аллаһы Тәгалә алар турында әйтә:

> **«Алар күзгә күренмәгәннәргә ышана, намазларын дөрес итеп укый. Без биргән малларын Аллаһ юлында сарыф итә».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:3

– юмартлык «бөтен мал-мөлкәт Аллаһныкыдыр» дигән шигарь астында булырга тиеш, ягъни бирүче фәкать Аллаһы Тәгалә, ә юмарт – сарыф итүгә сәбәпче генә, шуңа күрә мөселман кешесенә: «Мин булмасам, син хәзер ач-ялангач йөрер идең», – дип әйтү килешмәс;

– малның яхшысыннан-сыйфатлысыннан өлеш чыгарылырга тиешле, бозык-кирәксезеннән түгел; биргән малың булса, шундый булсын: сиңа тәкъдим итсәләр, үзең риза булып алырлык;

> **«Әй, мөэминнәр, җыйган малларыгызның иң затлыларын гына вә сезнең өчен җирдән чыгарганнарыбыздан (сәдака, хәер, зәкәт биреп, Аллаһ юлында) сарыф итегез. Күз йомып (чырагызны сытып, җирәнеп кенә, теләр-теләмәс кенә) алырдай затсыз малны бүләккә бирмәгез (үзегезгә ошамаган, гамәлгә яраксыз мал хәергә бирелмәс). Белеп торыгыз, Аллаһ чиксез бай һәм мактауга лаек».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:267

– юмартлык – үзең яраткан әйберне биргәннән ләззәт алу. Шуңа күрә дә, миңа бу әйбер ошамый, бәлки кемгә дә булса ярап куяр әле, дип кенә нәрсәнедер бирү – бары тик исрафтан качу, ә чын юмартлык түгел; Аллаһы Тәгалә Коръәндә кисәтә:

**«Сез сөекле нәрсәләрегезне (мал-мөлкәт, сәдака, зәкәтләрегезне Аллаһ юлында) сарыф итмәсәгез, игелеккә ирешә алмассыз. Сез нәрсә сарыф иткәнегез-итмәгәнегезне дә Аллаһ белеп тора».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:92

– биргәндә ихлас күңелдән бирергә; күңелсезләнеп-кәефсезләнеп биргән очракта – бу юмартлык хисапланмас, савабы да шулкадәр булыр;

– халыкның дикъкатен алып, күрсәтеп сарыф итү – яхшы гамәлләрдән түгел, ул Аллаһы Тәгаләнең ризалыгыннан ерагайта; башкалар минем нинди юмарт икәнлегемне күрсеннәр дип кенә сәдака бирү рияга китерә; Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

**«Әй, мөэминнәр, кешеләргә күрсәтер өчен генә сәдака-мал бирмәгез. Аллаһка, Ахирәт көненә ышанмаган кәфер кебек, хөсетлек, рия белән, кешене рәнҗетеп сәдака бирмәгез...»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:264

– кайчакта үрнәк күрсәтү өчен ачык рәвештә бирү рөхсәт ителә, шулай да яшерен бирү хәерлерәк:

**«Сәдакаларыгызны ачык итеп бирсәгез, яхшы булыр. Сәдакаларыгызны фәкыйрьләргә яшертен бирсәгез, сезнең өчен тагын да хәерлерәк булыр. Шуңа күрә, Аллаһ гөнаһларыгызның бер өлешен ярлыкар. Сез ни генә эшләсәгез дә, Аллаһ барысыннан да хәбәрдар».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:271

– зәкәт чыгару, сәдака бирү, фәкыйрь-мескеннәрне, ярдәмчесе булмаганнарны кайгырту – байлыгы булган һәр мөселманга тиештер. Шул рәвешле җәмгыять бер-берсен яраткан, бер-беренә ярдәм иткән гаилә мисалында булып, Аллаһы Тәгалә рәхмәтенә ирешү дә шуның аша булыр иде.

## Юмартлыкның төрләре һәм дәрәҗәләре

Саранлыкның да, юмартлыкның да төрле дәрәҗәләре бар. «Юмартлыкның иң югары дәрәҗәсе – башкаларны үзеңә караганда өстенрәк күрү. Ягъни, үзең мохтаҗ булсаң да, үзеңнең малыңны башкаларга корбан итү. Гомумән алганда, юмартлык ул – үзең мохтаҗ булмаган нәрсәне икенче бер мохтаҗ яки мохтаҗ булмаган кешегә бирү. Әмма моның иң яхшы күренеше – мохтаҗ була торып та, юмартлык күрсәтү. Аллаһы Тәгалә әйткән:

**«...үзләре мохтаҗ булсалар да, үзләренә караганда башкаларны өстенрәк күрәләр».**

«Хәшер / Сөреп Чыгару», 59:9

Юмартлык Аллаһы Тәгаләнең сыйфатларының берсе, ә башкаларга үзеңә караганда өстенлек бирү – юмартлыкның иң бөек күренеше. Пәйгамбәребез ﷺ нәкъ шундый юмартлык күрсәтә торган булган. Шуңа күрә Аллаһ аның холкын «бөек» дип атаган.

Гомәр  сөйләгән: «Бервакыт сәхабәләрнең берсенә сарык башы бүләк иткәннәр. Ул: «Минем кардәшем моңа мохтаҗрак», – дип, бу башны икенче кешегә җибәргән. Ә икенчесе – өченчесенә. Шулай итеп, бу баш җиде кешедә булып, яңадан беренчесенә әйләнеп кайткан».

Хөзәйфә Әдәви сөйләгән: «Шамны яулап алганда Ярмүк янындагы сугышта мин үзем белән аз гына су алдым һәм кардәшемне эзләргә киттем. Үземә: «Әгәр дә аны үлем хәлендә тапсам, аңа эчерәм һәм йөзенә сөртәм», – дип әйттем. Аны тапкач: «Сиңа су эчеримме?» – дип сорадым. Ул ишарә белән моны теләгәнен белдерде. Шулвакыт икенче кешенең ыңгырашканы ишетелде, һәм минем кардәшем суны ул кешегә бирергә кирәк дип ишарә белән күрсәтте. Әлеге кеше янына килгәч, мин аны Һишам бин Гас икәнен күрдем. «Сиңа су эчеримме?» – дип сорадым. Бу сүзләрне яндагы икенче кеше ишетте дә ыңгырашты. Мин аның янына

киттем. Мин аның янына барганда ул үлгән иде инде. Шунда мин Һишам янына кайттым, ул үлгән иде. Аннары туганым янына килдем. Ул да үлгән иде. Аллаһ аларның барысына да мәрхәмәтле булсын!»[1]

«Күркәм әхлакның зарури нәтиҗәсе – үзара мәхәббәт, бердәмлек һәм килешү, ә начар әхлакныкы – үзара нәфрәт, көнчелек һәм мөнәсәбәтләрне бозу».[2] Юмартлык күрсәтүнең дә нәтиҗәсе, һичшиксез, яхшыдыр. Бердән, юмарт мөселман Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын ала, икенчедән, бу сыйфаты аңа кешеләр белән мөнәсәбәтләрен корырга, аларның хакларын үтәргә ярдәм итә. Мәсәлән, кардәшләр һәм дусларга матди ярдәм күрсәтү өч төрле була.

Беренче һәм иң түбән дәрәҗә – син кардәшеңнең мохтаҗ икәнен күрсәң, үзеңнең ихтыяҗларыңнан артык калган нәрсәләр белән аны тәэмин итәсең. Син аңа үзең бирәсең, аның килгәнен көтеп тормыйсың. Әгәр дә аны мондый адым ясарга мәҗбүр итсәң, син кардәшләр арасында була торган мөнәсәбәтләрдә зур игътибарсызлык җибәргәнсең дигән сүз.

Икенче дәрәҗә – син кардәшеңә үзеңә караган кебек карыйсың, хәтта ул малыңның яртысына хуҗа булса да, канәгать буласың.

Өченче дәрәҗә – монысы иң бөеге санала. Син кардәшеңне үзеңә караганда да югарырак бәялисең, аның мәнфәгатьләрен үзеңнекенә караганда күбрәк кайгыртасың. Бу – изгеләр дәрәҗәсе һәм бер-берсен яратучылар өчен иң югары дәрәҗә. Ә бу дәрәҗәгә җиткәннәрнең иң югары чиге үз-үзеңне корбан итү була».[3] Юмартлыкның дәрәҗәләре дә югарыда санап үтелгән хаклар белән тәңгәл килә. Тагын шуны да әйтергә кирәк: саранлык һәм юмартлыкның дәрәҗәсе кешесенә карап төрле булыр. Мәсәлән, кайбер нәрсәләр фәкыйрь кеше өчен гадәти саналса, бай кеше шул нәрсәләр өчен гаепләнер. Яшь кешегә яраган һәрнәрсә олы кешегә

1 Мөхәммәт Җамалетдин Әл-Касыйми. Мөэминнәргә нәсыйхәтләр. – Казан: «Матбуган йорты» нәшрияты, 2004. – Б.265-266.

2 Шунда ук, Б. 99.

3 Шунда ук, Б.106-107.

килешмәс. Хатыннарның кайбер гамәлләренә игътибар ителмәсә дә, ирләр өчен күркәм булмас. Шуңа күрә кемдер бер сум сәдака бирсә дә юмартлык күрсәткән булыр, ә кемнеңдер йөз мең бирүе дә бары кешеләр алдында үзен күрсәтү хисапланыр.

Ә инде юмартлыкны кемгә һәм ни рәвешле кылып була дигәндә, түбәндәге хәдискә игътибар бирү сорала: Әбү Һөрәйра ﵁ риваять итә: «Бер көн Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ янына бер сәхабә килә һәм үзендә бер алтын барлыгын әйтә һәм аның белән нәрсә эшлим икән дип сорый. Мөхәммәд ﷺ аңа үз ихтыяҗына сарыф итәргә куша. Тагын бер алтыным булса, нишлим, дип сорагач, Расүлебез балаларыңа кирәк-яракны ал дип боера. Тагын берәү бар дигәч, гаиләсенә тотарга куша. Янә тагын бер алтынын кая куярга дигәндә, Пәйгамбәребез аны хезмәтчесенең ихтыяҗларына кулланырга әмер итә. Тагын бер алтыным бар дигәч, Мөхәммәд ﷺ : «Анысын кая куячагыңны син миннән яхшырак беләсең», – дип җавап кайтара».

Күргәнебезчә, мөселман кешесе иң әүвәл үзенә һәм гаиләсенә карата юмарт булырга тиеш. «Үзе һәм бала-чагасы мохтаҗ булган хәлдә, яисә бурычы булганда бирелгән сәдака кабул булмас. Бурычны кайтару – сәдака бирү, кол азат итү һәм бүләк бирүдән тагын да мөһимрәк. Башка берәүнең малының, сәдака биреп, юкка чыгуына сәбәпче булмагыз».[1]

«Акчагыз булса, иң элек үз ихтыяҗларыгызны канәгатьләндерегез. Артып калса, бала-чагагызга сарыф итегез. Моннан да артса, туганнарыгызга ярдәм итегез»[2]. Мал белән дә шулай ук.

Кунакчыллык, бүләк бирү, күршеңне сыйлау – болар да юмартлык гамәлләренә керә. Чөнки саран-комсыз кеше өчен бу мәсьәләләр бик четерекле. Андыйлар үзләре дә кунакка йөрергә һәм бүләк бирергә яратмый, үзләренә бүләк бирелсә, үзен уңайсыз тоя, сөенер урында, саран кеше хафага төшә, чөнки үзе дә хәзер нindидер игелек күрсәтергә,

1 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан

2 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

бүләккә каршы бүләк бирергә тиеш була. «Башкаларны икрам вә ихсан кылу (ягъни аларны сыйлау һәм һәдия бирү) кеше табигатенә туганда ук хас булган. Бу тойгы адәм баласына күңел тынычлыгы, рух тигезлеге, милләттәш вә диндәшләренә файдалы булу сөенечен бирә. Карун, саран кешеләр еш кына рухи төшенкелек кичерәләр, тормышның мәгънәсен эзләп баш ваталар»[1].

Юмартлыкның өстен дәрәҗәләре булган кебек, саранлыкның да иң түбән дәрәҗәсен аерып чыгарырга мөмкин. Ул да булса, үзеңә кирәк булмаган нәрсәне бирмәү. Саран кеше җаны теләгән әйберен алырга көче җитсә дә, алмас, чөнки акчасын кызганыр, ягъни шул рәвешле, беренче чиратта, ул үзенә карата саранлык күрсәткән булыр. Хәтта авырып китсә дә, ул үзенә арзанлы яисә ташламалы дару эзләр, табалмаган очракта, дәваланудан баш тартыр.

1 Инсан һәм дин: Мәкаләләр һәм хикәяләр / Тәрҗ. Р.Кадыйров. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2006. – Б.164.

# «Шура»га – 110

# Журналны өйрәнү тарихы

«Шура» журналы XX йөз башы татар вакытлы матбугаты җәүһәрләренең иң затлыларыннан берсе булса да, хәзерге вакыткача монографик планда махсус тикшерелмәгән. Дөрес, совет хакимияте дәверендә бу мөмкин хәл түгел дә иде. Чөнки «Шура» журналына да, 1917 елга кадәр чыккан башка бик күп татар газета һәм журналлары кебек үк, «милләтче, буржуа органы» дигән кара мөһерләр сугылган иде. «Шура»га төрле елларда ниндирәк мөнәсәбәт булып, кайсы заманда ничегрәк бәяләнгәнлеген төгәлрәк күзаллау өчен аерым хезмәтләргә мөрәҗәгать итик.

«Шура» журналы үзе чыккан вакытында алдынгы фикерле замандашлары тарафыннан уңай бәяләнгән һәм хупланган. «Шура» чыга башлау турында хәбәр булу белән яисә беренче саннары чыккач та, татар газеталары һәм журналлары бу уңайдан үз фикерләрен, мөнәсәбәтләрен белдергәннәр. Татар вакытлы матбугаты галәменә яңа бер журналның өстәлүе, әлбәттә, хуплап каршыланган. Бигрәк тә, мөхәррире Риза казый булганга, төрле матбугат органнары сөенечләрен, яңа журналның җитди булачагына ышанычларын белдергәннәр. Мәсәлән, Уфада нәшер ителгән «Мәгълүмат» журналы «Шура» һәм аның мөхәррире турында «мөндәриҗәсе мөһим, теле әдәби вә татлыдыр... Ризаэддин хәзрәт мөхәррир булганнан соң артык тәгърифкә хаҗәт юктыр, кем идеке вә мәсләге вә ни нәрсәләр көтеләчәге Русия мөселманнарына гына дәгел, хәтта мөстәшрикъләрә дә мәгълүм бер заттыр» дип язган. Казан матбугатында да шуңа охшаш хәбәрләр чыккан.

Петербургта Фәннәр академиясе тарафыннан нәшер ителгән «Мир ислама» периодик басмасында, 1912-1913 елларда башка татар матбугаты органнары белән берлектә, даими рәвештә «Шура» журналына да күзәтү ясалган, кайбер мәкаләләре анализланып һәм русчага тәрҗемә

ителеп басылган. «Православный собеседник» журналының «Инородческое обозрение» исемле кушымтасында да «Шура» хакында язылган. Истанбулда чыккан «Төрк йорды» журналы да «Шура»ны татарлар арасында нәшер ителгән журналларның иң яхшысы, мөхәррире Р. Фәхреддинне «заманымызның иң мокътәдир» дин галиме дип атый.

Нәшер ителә башлавына биш ел тулгач, Җәмал Вәлиди «Шура» журналының татар халкын һәм журналны укучы башка төрки халыкларны гыйльми дәрәҗәдә Шәрык тарихы, әдәбияты һәм мәдәнияте белән таныштыруга зур өлеш кертүен билгеләгән.

1916 елда татар вакытлы матбугатының 10 еллыгы уңаеннан В. А. Гордлевский (1876-1956) «Шура» журналы һәм «Вакыт» газетасы турында уңай фикерен һәм җылы мөнәсәбәтен белдерә. «Шура»ны гыйльми-әдәби журнал дип атый. «Аң» журналы сәхифәләрендә дә «Шура» журналы «гыйльми журнал» дип тәкъдир ителгән.

Гата Исхакый үзенең әдәбият дәреслегендә Ризаэддин Фәхреддиннең тормышы һәм иҗаты турында язган вакытта «Шура» журналын уңай бәяләп, «Риза хәзрәт «Шура» журналында тәгълим вә тәрбия бабына зур урын биргән кебек, әдәбият вә тарихыбызга киң урын биреп, әдәбиятыбызга артык зур хезмәт күрсәтте», – дип язган.

1923 елларда «солтангалиевчелек»не фаш итү кампаниясе башлангач, журналга карата бәяләмәләр кискен үзгәрә. Шул вакыттан башлап аңа «буржуаз», «пантюркистик», «панисламистик» кебек бәяләмәләр тагыла башлый. Сәлах Атнагулов 1926 елда Исмәгыйль Рәмиев төзегән «Вакытлы татар матбугаты» альбомының кереш сүзендә «Шура»ны «Аң», «Мәктәп», «Сөембикә» һ.б. татар журналлары арасында санап китеп, аларның барысын да «үзләренә тормышның берәр тармакларын аларак, укучыларын буржуа идеологиясе белән сугарыштылар» дип бәяләгән. Мәгълүм булганча, «буржуа идеологиясе» гыйбарәсе – совет хакимияте дәвере өчен бик хәтәр бәяләмә.

Татар матбугаты альбомын төзүче И. Рәмиев исә «Шура» хакында «озак дәвамы вакытында тәртипле чыгып торуы аркасында бик күп таралды, күп укылды. Милли журналлар арасыннан материалга бае – шушы иде. Моның мәсләге турында сүзне озынга җибәрмичә, милли либераллык юлы белән динчелекне бергә алып барган һәм милли энциклопедия тибындагы журнал дисәк, шаять аңлашылыр... Техникасы ягыннан, һичшиксез, беренче урынны тотты дияргә мөмкин. Татар матбугатында эшләгән каләм ияләренең барысы да диярлек «Шура»да языштыралар», – дип язган. «Энциклопедик» дигән сыйфатламаны «Шура»га карата беренче буларак Исмәгыйль Рәмиев куллана һәм соңгырак истәлекләрендә дә бу гыйбарәне кабатлый. И. Рәмиев альбомы уңаеннан В. А. Гордлевский татар халкы тарафыннан зур игътибар һәм танылу тапкан «Вакыт» һәм «Шура»га анда аз урын бирелгәнлегенә ишарә итә.

Әдәбият галиме Габдрахман Сәгъди 1917 елга кадәрге журналлар турында язганда «Шура»ны «дини, милли, тарихи, иҗтимагый материалларга бик бай булу өстенә, татар дөньясында ул заманда иң беренче җитди бер журнал, татарның либераль тәрәккыйче буржуазиясенең дини-милли байрагын күтәргән» бер матбугат органы дип бәяли.

Фәкать татар тарихчысы, галим Газиз Гобәйдуллин хезмәтендә мондый ярлыклар тагылмаган. Бөтенсоюз Беренче тюркологик съездда сөйләгән нотыгында ул «Шура» журналы эшчәнлеген уңай яктан бәяләгән.

Совет дәверендә, сәяси-идеологик карашларга бәйле рәвештә, XX йөз башындагы татар матбугатының башка бик күп органнары кебек үк, «Шура» журналы да «милләтчел, буржуаз» һ.б. шундый тамгалар белән бәяләнгән. Гомумән, совет елларындагы гыйльми әдәбиятта «буржуаз» сүзе генә дә дошманый дигән мәгънәгә тәңгәл иде.

1950-1970 нче еллардагы хезмәтләрдә «Шура» журналының исеме «буржуаз», «милләтче», «панисламистик», «пантюркистик» һ. б. шундый кара сыйфатламалар белән бирелгән. Татарстан тарихы буенча язылган

хезмәтләрдә «Шура» буржуаз милләтчелек агуын тараткан һәм «үтә реакцион панисламизм һәм пантюркизм идеяләрен пропагандалаган» журнал дип бәяләнгән. К. Фәсиев бер хезмәтендә «Шура» журналын гаять тискәре бәяләп, аны монархиягә, панисламизм һәм пантюркизмга дан жырлаучы, рус мәдәниятенә һәм рус әдәбиятына каршы көрәшүче, халык ижатына каршы булган, әдәбияттагы реакцион идеяләрне яклаучы буржуаз, милләтче, реакцион журнал буларак тасвирлаган.

Татар иҗтимагый фикере тарихына багышланган хезмәтләрдән Р. Нәфыйгов китабында да «Шура» журналына татар буржуазиясе кулындагы «милләтче» һәм «расачыл, пантюркистик, панисламистик идеяләр таратучы», идея эчтәлеге буенча чуар журнал дигән бәя бирелгән.

Совет фәнендә «Шура» журналына карата урнашкан тискәре бәяне инкяр итмәгән хәлдә, журналның татар тарихы, әдәбияты һәм мәдәниятенә керткән өлешен берникадәр чикләнгән дәрәҗәдә таныган кайбер авторлар да булган. Мәсәлән, бер коллектив хезмәттә «Шура» журналы «милләтче буржуазия рупоры булса да, анда татар халкының этнографиясе, көнкүреше буенча басылып чыккан материаллар әһәмияткә ия» (Тәрҗемә безнеке – Р.М.) дип язылган юллар бар. Мондый тану, югарыда әйтелгәнчә, «чикләнгән дәрәҗәдә» икәнлеген онытмаска кирәк. Әйтик, шул ук китапның башка битләрендә «Шура»ның татар буржуазиясе органы буларак буржуаз милләтчелек идеяләрен таратучы, милли ызгышлар чыгарырга омтылучы пантюркистик журнал булганлыгы турында да сүз куертылган.

Кискен тискәре бәяләмәләргә аеруча басым ясамыйча, «Шура» журналының үз чорындагы киң укучылар катлавында актив иҗтимагый тормышка карата кызыксыну уятудагы ролен уңай бәяләгән мәкаләләр дә чыккан.

Татар әдәби теленең формалашуы процессларында хәреф-имля төзәтү мәсьәләсенә багышланган бәхәсләрне оештыруда да «Шура» журналы зур роль уйнады дип яза тел галиме Х. Курбатов.

Шагыйрь һәм журналист Зариф Бәшири истәлекләрендә дә «Шура» журналына бәйле күп кенә фактик хатирәләр язылган. Автор журналга, аның мөхәррире Р. Фәхреддингә, нәширләре Рәмиевләргә карата тискәре сыйфатламалар кулланмаган. Фәнни хезмәтләрдә «буржуаз-фәлән» дип сүгелеп килгән бер журнал турында болай язу, әлбәттә, үз чорына күрә, гайре табигый, кыю адымнарның берсе булган. З. Бәшири китабының иң әүвәлге битендә нәшрият исеменнән «бу истәлекләр һәммә очракта да авторның субъектив карашларыннан һәм кайбер кимчелекләрдән азат-тыр дип булмый» дигән аңлатма-истәлекләрдәге шуңа охшаш моментларны да күздә тота булса кирәк.

1950-1960 елларда совет дәүләтендәге сәяси-ижтимагый атмосфераның «Хрущев җепшеклеге» нәтиҗәсендә рухи җанлану һәм милли мираска булган игътибар шактый көчәя. Шул чорда, 1959-1962 елларда Казан дәүләт университетының ул вакыттагы студенты (хәзер исә танылган тарихчы-галим, академик) Миркасыйм Госманов тарафыннан «Шура» журналының тулы библиорафик күрсәткече төзелә. Ун ел дәвамында чыккан журналның барлык 240 санындагы һәр мәкалә һәм язма тасвирланып, тематика буенча бүленә һәм 2 томлы хезмәт төсен ала. Библиографик күрсәткечнең әдәбият, тел белеме һәм мәгариф темаларына караган I кисәге басмага әзерләнә, хәтта типографиядә корректура нөсхәләре җыела. Ләкин «Шура» хакында дистә еллар буе буржуаз, милләтчел, пантюркистик һәм… тагын әлләниләр, кыскасы, дошмани журнал дигән бәяләмә-мөһерләр тәэсирендә игелекле бу хезмәт дөньяга чыга алмыйча кала. Ә җыелган корректура нөсхәләре университет китапханәсе кысаларында эчке файдалану өчен генә рөхсәт ителә. «Шура» журналы библиографиясенең озак вакытлар нәшер ителмәве ту-

рында әдәбият галимнәре ачынып язганнар иде. Соңгы елларда илдәге сәяси-идеологик вәзгыять «Шура» журналының тулыландырылган соңгы вариантын нәшер итәргә мөмкинлек бирсә дә, һәр төрле матди-финанс авырлыклары аркасында олуг хезмәтнең дөньяга чыгуы тоткарланып килде. Ниһаять, «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең «Әлмәтнефть» идарәсе матди ярдәме белән 2000 елда «Шура» журналының библиографик күрсәткече нәшер ителде. Белешмәнең кереш мәкаләсендә М. Госманов күрсәткечнең 1960 нчы елларда чыкмый калуының гыйбрәтле тарихын да яза.

1960 нчы еллар башында М. Госманов тарафыннан библиографик күрсәткечкә кереш урынына күләмле гыйльми мәкалә язылган булган. Кызганыч, тирән эчтәлекле бу мәкалә дә, ул чагында күрсәткеч белән бергә, нәшер ителмичә калган. «Шура» журналы турында» дип исемләнгән ул мәкаләсендә М. Госманов журналда төп игътибар үзәгендә булган милләткүләм гомуми мәсьәләләрнең кайберләренә тукталган. Мәсәлән, халкыбызның атамасы (татармы, болгармы, төрекме), әдәби тел һ.б. катлаулы, бәхәсле мәсьәләләр анализланган. Шулай ук «Шура»ның әдәби эшчәнлеге, мәгариф өлкәсендәге позицияләре ачык билгеләнгән. «Милли, дини, фәлсәфи, мәдәни, әхлакый һ.б. мәсьәләләрдә шактый тырыш, эшлекле... Оештыру осталыгы белән «Шура» үрнәк булырлык югарылыкта.... Бик каршылыклы, катлаулы. Ләкин, җентекләп өйрәнгәндә, үзен тудырган киеренке чорның күп яклары турында бай мәгълүмат бирә ала... «Шура» журналы татар нәширләре, татар мөхәррирләре тарафыннан чыгарылса да, вакыты-вакыты белән татарлык рамкасына сыймый, милләтләрара бер органга әверелә... Заманына күрә энциклопедик гыйльми журнал» дип яза автор, «Шура» журналын гомуми бәяләп. Шулай ук галимнең «төрки халыклар тарихы «Шура»да... тулырак гәүдәләнгән,ербөтен цикл» дигән бәяләмәсе бик хак. Ул вакытта М. Госманов төзегән «Шура» журналы библиографик күрсәткече нәшер ителмичә калса да, аның тара-

фыннан «Шура» хакында башка мәкаләләрендә һәм хезмәтләрендә киң язылган.

Күренекле галим Мөхәммәт Гайнуллинның татар әдәбияты тарихына багышланган һәм 1966 елда дөнья күргән хезмәтендә «Шура» идеалистик дини фәлсәфәне пропагандалаган либераль-буржуаз» журнал дип саналса да, тулаем алганда, башка фәнни хезмәтләрдән аермалы буларак, объектив бәяләнгән. Дөрес, Рәмиевләр тарафыннан нәшер ителгән «Вакыт» газетасы белән «Шура» журналында татар әдәбиятына һәм культурасына караган гаять кыйммәтле материаллар урын алган» дип М. Гайнуллин элегрәк тә белдереп үткән була. М. Гайнуллинның журналга карата язылган объектив һәм әтрафлы язмасы кергән китап чыгу белән үк хуплау тапкан. Болар белән беррәттән, М. Гайнуллин, гомумән, журналның мөхәррире Р. Фәхреддин эшчәнлеген совет чорында яңача бәяләп, рухи аклаучыларның беренчеләреннән санала.

«Шура» журналы буенча киң һәм тәфсилле беренче тикшеренү һәм, кыскача булса да, әтрафлы мәгълүмат М. Гайнуллин китапларында чыккан. Ул «Шура» журналының мөхәррире һәм нәширләре турында кыскача мәгълүмат бирү өстенә, редакция составында эшләгән әдипләр һәм шәхесләргә дә туктала. Журналның колачлаган тематикасына күзәтү ясый. Автор «Шура»ның игътибар үзәгендә булган иң актуаль мәсьәләләр белән таныштыра. Журнал битләрендә барган бәхәсләр, дөнья фәлсәфәсе һәм әдәбияты, аеруча татар, шәрык һәм мөселман әдәбияты мәсьәләләренең журналда яктыртылу дәрәҗәсе югары һәм уңай бәяләнә. Шулай ук татар тарихының мәшһүр шәхесләренә һәм әдипләренә, демократик рус әдәбиятына багышланган мәкаләләр турында яза.

«Шура» журналына багышланган әтрафлы мәкаләләрнең берсе Ү. Гыймадиев тарафыннан язылып, мәкаләдә, нигездә, «Шура»ның әдәби эшчәнлеге тасвирланган.

Әдип һәм әдәбият галиме Мөхәммәт Мәһдиевнең «Татар журналлары» дип исемләнгән мәкаләсендә «Шура» журналы турында шактый әтрафлы язылган. Мәкаләдә кайбер төгәлсезлекләр булса да, журналның эшчәнлеге югары бәяләнгән. Аерым алганда, галимнең «Шура» – Октябрь революциясенә кадәрге татар әдәбияты, әдәби эстетик фикере үсешенең төп үзәге, ...барлык татар язучылары өчен дә осталыкка өйрәнү мәктәбе булды», – дигән фикерләре әһәмиятле.

Югарыда саналган авторлардан тыш М. Рәхимкулова, Ф. Баишев, М. Мәрдиева кебек тикшеренүчеләрнең мәкалә һәм хезмәтләрендә дә «Шура» журналы турында язылган һәм уңай бәяләнгән.

Соңгы вакытларда гына төрек галиме Исмаил Тюркоглуның Ризаэддин Фәхреддингә багышлап язылган гыйльми хезмәтендә дә «Шура» журналы эшчәнлеге шактый киң тикшерелгән.

Совет илендәге идеология һәм иҗтимагый тормышта 1985 елдан соң яңа үзгәрешләр башлангач та, дистә еллар буе фәндә «Шура»га карата урнашкан мөнәсәбәт һәм бәяләмәләрдән галимнәр тиз һәм җиңел генә арынып бетә алмыйлар. Мәсәлән, Мөхәммәт Мәһдиев «Реализмга таба» хезмәтендә «Шура»га карата, нигездә, симпатия белдерелсә дә, журнал адресына «либераль-буржуаз, пантюркистик, буржуаз мәгърифәтче» кебек, элекке хезмәтләрдәгечә, сыйфатламалар да бирелгән. Мондый матбугат органнарына «бәя биргәндә, сыйнфый күзлектән чыгып анализ ясарга кирәклекне онытырга ярамый» дип искәртелә.

Әмма шул ук автор бер мәкаләсендә «Шура»ны «Һич тә... буржуаз журнал түгел», – дип, үз фикерләренә каршы да килә. Ш. Бабичның соңгы җыентыгында да «Шура»га «либераль-буржуаз» мөһере сугылган. 1998 елда гына чыккан педагогика тарихына багышланган бер хезмәттә 1950-1960 еллардагыча бәяләмәләр бөтенләй таң калдыра. Анда Р. Фәхреддиннең «Шура» битләре аша пантюркизм һәм динне буржуаз рухта яңарту идеяләрен пропагандалавы турында әйтелә.

Гасыр башында чыккан «Шура»ның шан-шөһрәте заманыбызда башкача бер рәвештә дә чагылып алган иде. Радик Нуретдин мөхәррирлеге һәм наширлегендә Башкортстанның Бөре шәһәрендә 1994 елның августында татар телендә «Шура» исемле 5000 данә тиражлы бер журнал чыкты. Яңа «Шура» үзен элекке «Шура»ның турыдан-туры дәвамчысы дип белдереп, тышлыгында Р. Фәхреддиннең фоторәсеме бирелгән һәм матур гына мәкаләләре дә бар иде. Әмма, башка саннары чыкмадымы, әллә чыгып та Казанга килеп ирешмәдеме, һәрхәлдә, дәвамы күренмәде.

«Шура» журналында нәшер ителгән материалларны өйрәнүдә һәм пропагандалауда Яхъя Абдуллин, Равил Әмирханов, Зөфәр Рәмиев, Әнвәр Хәйриләр зур хезмәт куйдылар. Яхъя Абдуллин татарларда фәлсәфи фикер үсешенә багышланган хезмәтләрендә «Шура» сәхифәләрендә дөнья күргән материалларны актив файдаланды. Р. Әмирханов Р. Фәхреддиннең «Шура»дагы тарихи мәкаләләрен татар журналларында һәм китаплар итеп гамәлдәге татар графикасында бастырып чыгарды, З. Рәмиев «Шура»да нәшер ителгән шигъри әсәрләрне, авторлары турында белешмә биреп, журналларда бастырды, Ә. Хәйри дә Р. Фәхреддиннең «Шура»да дөнья күргән дини, иҗтимагый, тарихи мәкаләләрен хәзерге матбугатта чыгарды. Татар шагыйрьләренең «Шура»да басылган күп кенә әсәрләре татар поэзиясе антологияләренә дә кертелделәр.

# Журналның нәширләре

«Шура» журналы мәшһүр татар промышленниклары – бертуган Мөхәммәдшакир (1857-1912) һәм Мөхәммәдзакир (1859-1921) Рәмиевләр – тарафыннан нәшер ителгән. Бертуган Рәмиевләр – XX йөз башы татар иҗтимагый тормышында күренекле эз калдырган, татар дөньясының

тәрәккые, мәгарифе, мәдәнияте вә әдәбияты үсеше өчен җан аткан, абруйлы милләтпәрвәр шәхесләр.

Рәмиевләрнең матбугат, басмаханә эшләре белән кызыксынулары 1880 елларда ук башланган. «Милләтләрнең тәмәдден вә тәрәккыйләренә иң беренче васита әдәбият, матбугат икәнлегенә киткән саен аның (Шакир Рәмиевнең – Р.М.) иманы куәтләнә барды. Шуның өчен дә ул бер матбага ачып, газета-журнал чыгаруны, әдәбият вә фөнунгә гаид рисалә вә китаплар нәшер итүне үзенә иң беренче максат итеп тотты. Матбага вә матбугат хәлләрен дәхи дә дә якыннанрак үгрәнергә кереште. Мәрхүм Шакир әфәнде 1899 елда Яурупага сәфәр иткән вакытында да Петербургта матбага вә матбугат әхвален үгрәнүгә байтак зиһен сарыф иткән. Бораганский матбагасына вә рус матбагаларыннан һәм редакцияләреннән бәгъзеләрен кереп карап йөрегән вә ул дөнья берлән мөмкин кадәр якыннанрак танышырга тырышкан. Буңа аның шул вакыт Петербургтан бөрадәре Закир әфәндегә язган мәктүбләре шаһиттер... 1902-1903 елларда булса кирәк, бөрадәре Закир әфәнде илә бергә татар телендә бер газета чыгарыр өчен рөхсәт сорап Петербургка мөрәҗәгать итеп тә карадылар. Фәкать ул вакытлардагы идарәнең икътизасынча мөселманнарга үз телләрендә газета чыгарырга рөхсәт алу мөмкин түгел диярлек дәрәҗәдә мөшкел иде. Рөхсәт бирелмәячәге аңлашылды. Шул сәбәпле, эстәр-эстәмәс анлар үзләренең гаййәи хыялларын (хыялдагы максат) дәхи бер мөддәт кичектереп торырга мәҗбүр булдылар». Аларга изге хыялларын фәкать 1905 ел инкыйлабыннан соң гына тормышка ашыру мөмкинлекләре ачылган.

1906 елның 16 февралендә Рәмиевләр Оренбург каласында «Вакыт» исемле татар газетасы, 1907 елның 13 декабрендә «Шура» исемле татар журналы нәшер итүгә рөхсәт алалар.

Рәмиевләр 1909 елның 2 гыйнварында «Вакыт» исемендә үз матбагаларын ачарга Оренбург губерна идарәсеннән 4 нче номерлы таныклык

алып, «Вакыт» газетасын һәм «Шура» журналын үз басмаханәләрендә бастыра башлыйлар.

«Шура» журналының наширләре – бертуган Рәмиевләрнең әдәбият буенча белемнәре тирән булган. Р. Фәхреддиннең бер хатирәсендә Шакир Рәмиевнең «хакыйкый мәгънәсе илә әдәбият мөгаллиме улырга лаек» икәнлеге турында язылган. Наширләрнең икенчесе Закир Рәмиев (Дәрдмәнд) – үзе мәшһүр фәлсәфи, лирик шагыйрь, татар классик шигъриятенең иң күренекле вәкилләреннән берсе. З. Бәширинең 1968 елда чыккан «Замандашларым белән очрашулар» исемле китабына керми калган, ягъни автор кульязмасының редактор тарафыннан сызылган юллары Дәрдмәнднең әдәби эшчәнлеккә аеруча игътибарлылыгын һәм зур әһәмият бирүен күрсәтә. Гонорар мөнәсәбәте белән икесе арасында булган әңгәмәне З. Бәшири болай дип искә алган:

– Ничек соң, язган әсәрләрең өчен яхшы түлиләрме, гонорар белән тормышны тәэмин итеп буламы?

– Анысы инде аның, Закир абзый…

Мин шулай дип сүз башлаган гына идем, ул, минем нәрсә әйтергә теләгәнемне бердән аңлап алды булса кирәк, миңа әйтеп бетерүгә дә юл куймады:

– Алай карарга ярамый ул, – диде. – Язучы, шагыйрьнең тормышы тәэмин ителми икән, аның иҗаты дә тәэмин ителми!»

Закир Рәмиевнең «Дәрдмәнд» псевдонимы белән шагыйрь буларак шөһрәт казануы да «Шура» журналы сәхифәләре аша була. Мөхәммәдшакир Рәмиев 1912 елның 15 мартында фаҗигале төстә вафат булгач, агасы белән бергә башлаган барлык эшләр белән бергә «Шура» журналын нәшер итү дә Закир Рәмиевкә йөкләнә.

Рәмиевләр һәм «Шура»ның мөхәррире Р. Фәхреддин үзара зур ихтирам саклап килгәннәр. Алар арасындагы җылы мөгамәлә турында Әсма Шәрәф истәлекләрендә бик тәфсыйльле тасвирланган.

Журналның наширләре «Шура»га бик зур әһәмият биргәннәр, күп чыгымнар таләп итсә дә, акчаларын кызганмаганнар, даими кайгыртучанлык күрсәткәннәр. З. Бәшири хатирәләре моны бик яхшы дәлилли. Ул З. Рәмиевнең 1909 елдагы «Әлегә чаклы үткән елларда «Вакыт» газетасы белән «Шура» журналы, һәр елны, алтын хисабы белән ун мең сумга якын зарар күреп килделәр. Бу зарар аларны укучыларның, алдыручыларның аз булуыннан килгән эш түгел. Безнең газета белән журналның укучылары шактый зур табыш күргән башка газеталарныкына караганда ике өлеш диярлек күбрәк. Бу зарар безнең газета белән журналны эчтәлеге ягыннан да, техника ягыннан да матур, нәфис иттереп чыгару өчен акчаны кызганмавыбыздан килә… Моннан соң без бу юлда, ел саен, 15 мең сумга чаклы зарар күрергә дә хәзербез» дигән сүзләрен язган. Шул ук истәлекләрдәге мондый факт та наширләрнең журналга карата аеруча җитди мөнәсәбәт һәм ихласлыкларына мисал. «Закир Рәмиев редакция эшчеләренең тормыш ягыннан яхшы тәэмин ителүләре, тышкы күренештә дә культуралы яшәүләре ягына да нык күз сала, шуның өчен дә аларга ул чорларда һичбер җирдә күрелмәгән рәвештә зур жалование бирә иде. Мисал өчен шуны гына искә алып үтү дә житсә кирәк: ул чагында татар дөньясында түгел, хәтта Мәскәү, Петербург шәһәрләрендә чыга торган иң зур, популяр рус газеталарының редакторлары да аена 70-80 сумнан артык жалование алмыйлар иде. Закир Рәмиев «Вакыт» газетасы редакторы Фатыйх Кәримов белән «Шура» журналы редакторы Риза казыйга аена 130 сум жалование бирә иде. Моны күпләр «министрлар жалованиясе» дип йөртә торганнар иде».

Милли матбугат өчен жан аткан һәм ихластан тырышкан бертуган Рәмиевләрнең «Шура» журналын матди җәһәттән тәэмин итеп торулары сокландыргыч.

# Журналның мөхәррире

«Шура» журналының зур абруй казанып, югары гыйльми дәрәҗәгә ирешүе, һичшиксез, аның баш мөхәррире Ризаэддин Фәхреддин эшчәнлегенең, киң эрудициясенең, фидакяр тырышлыкларының нәтиҗәсе.

Журнал мөхәррире булганчы ук Р. Фәхреддин исеме төрки-татар һәм мөселман дөньясында танылган исемнәрнең берсе була. Җәмәгатьчелек аны, бер яктан, 1891-1906 елларда Мәхкәмәи Шәргыядә (Диния нәзарәтендә) казый буларак үз вазифаларын зур таләпчәнлек һәм намус белән башкарган тирән фәһемле мөхтәрәм бер зат буларак белсә, икенче тарафтан, аның матбугатта дөнья күргән хезмәтләре дан-шөһрәт китергәннәр.

Р. Фәхреддиннең беренче хезмәтләреннән булган, 1888 елда нәшер ителгән «Игътибар» исемле китабы белән танышкач, Шиһабеддин Мәрҗани «бу егет өмидле, мәсләгендә дәвам итсә, яхшы хезмәт итәр» дип хуплаганлыгы мәгълүм. Мәшһүр шагыйрь Акмулла да аның турында «Хөрмәтле Ризаэддин – бер камил зат» дип язган. Шакирҗан Хәмиди исә Р. Фәхреддинне «казыйларның йөзек кашы» дип бәһаләгән.

Ризаэддин Фәхреддиннең 1887-1907 елларда, ягъни «Шура»га кадәрге дәвердә барлыгы 29 исемдәге гыйльми-педагогик, дини, әдәби, тарихи хезмәтләре һәм әсәрләре басылып чыга. Алар арасында дүртәр-бишәр, хәтта алты мәртәбә басылганнары да була. Мәсәлән, «Нәсыйхәт», «Тәрбияле бала», «Шәкертлек әдәбе» һ.б. Р. Фәхреддиннең бу һәм башка күп кенә китаплары төрки татар мәктәп һәм мәдрәсәләрендә дәреслек сыйфатында кулланылганнар. Әдәби әсәрләреннән «Сәлимә, яки Гыйффәт» (1899), «Әсма, яки Гамәл вә җәза» (1903), зур әһәмияткә ия булган тарихи биобиблиографик хезмәтләреннән «Асар»ның 13 җөзъә-кисәге дә «Шура»дагы эшчәнлегенә кадәр үк басылып чыга һәм тарала. Болар исә

Р. Фәхреддиннең матбугат һәм гыйлем мәйданында җитди тәҗрибә туплавы белән беррәттән, аның шәхесе, әдиплек һәм галимлек куәсе хакында җәмәгатьчелектә ныклы җирлек хасил иткән. Р. Фәхреддиннең күп кенә хезмәтләре Төркиядә дә таралганлыгы һәм зур уңыш казанганлыгы мәгълүм.

Татар әдәбияты турында үз чорында ук язылган русча мәкаләләрдә дә Р. Фәхреддин тәрәккыйпәрвәр әдип буларак белдерелгән, Идел буе яңа татар әдәбиятының күренекле каләм әһелләренең берсе дип күрсәтелгән.

Р. Фәхреддин «Шура» мөхәррире булганчы журналистлык өлкәсендә дә үзен сынаган һәм үткен каләме белән танылган. Аның беренче мәкаләләре 1883-1918 елларда Бакчасарайда нәшер ителгән «Тәрҗеман» газетасында басылган. «Тәрҗеман» 1905 елга кадәр Россиядә бердәнбер төрки газета булып, аны бөтенроссия мөселманнары, бигрәк тә Идел-Урал төбәге татарлары актив укучы һәм язышучыларыннан булганнар. Күренекле мәгърифәтче Исмәгыйль Гаспралы мөхәррирлегендә нәшер ителгән бу газета Р. Фәхреддин турында зур ихтирам белән язып килгән.

1906 елда «Вакыт» газетасының наширләре – бертуган Рәмиевләр һәм мөхәррире Фатыйх Кәрими чакыруы буенча Р. Фәхреддин гаиләсе белән Оренбургка күчеп килә. Бу уңайдан «Вакыт» газетасының беренче битендә эре хәрефләр белән шатлыклы махсус хәбәр басылган. «Үзенең фәзаиле Гыйльмиясе, истикамәте фикриясе, куәи каләмиясе илә ялгыз Русия мөселманнары арасында гына дәгел, бәлки Шәрык вә Аурупа голәмасы арасында да исеме танылмыш вә бер чук әсәрләр сахибе улан әдибе мөхтәрәм Ризаэддин бине Фәхреддин әфәнде хәзрәтләренең Уфадагы Духовный Собрание әгъзалыгыннан истигъфа идәрәк, газетамызның даими мөхәррире сыйфатыйлә Оренбурга киләчәкене бөек бер сөенеч илә хәбәр вирәмез...»

Р. Фәхреддин 11 майда казыйлык вазифасыннан азат итүне сорап «прошение» бирүе һәм 21, 22 май числоларында Оренбургка сәфәр

чыгачагын белдереп, Фатыйх Кәримигә 1906 елның 12 маенда хат юллаган. «Вакыт» газетасының 24 май санында Р. Фәхреддиннең Уфадан 20 майда «Троян» исемле пароходта Оренбургка юнәлүе турында Уфадан килгән «хосусый телеграм» басылган. Телеграммада редакция тарафыннан гаиләсе белән аның 24 майда Оренбургка килеп ирешәчәге һәм «Вакыт» газетасында даими мөхәррирлек итәчәге белдерелгән. Шуннан берничә көн үткәч тә, Р. Фәхреддиннең газета мөхәррирләреннән берсе буларак язган «Уфа шәһәренә видагъ» мәкаләсе чыккан. «...Бундан соң милләтләрнең тәрәккыйләре, сәгадәт вә шәкауәтләре, һичшөбһәсез, матбугат вә «каләм»гә бәгланачактыр. Кавемнәрнең сәламәт вә хәстәлекләрене күстәрәчәк барометрулар – матбугат булачактыр...» дип, автор матбугатны җәмгыятьнең халәтен күрсәтүче барометрга тиңләгән. Моннан исә матбугатка аның никадәр зур әһәмият биргәнлеге ачык күренә.

Ризаэддин Фәхреддингә 1906 елның 30 ноябрендә «Вакыт» газетасының мөхәррире Ф. Кәрими булмаган вакытларда газета редакторы вазифаларын башкару хокукын белдергән 3200 нче номерлы рәсми таныклык бирелгән.

«Вакыт» газетасында аның «Р.Ф.», «Морад», «Дәрвиш», «Мөслим» имзалары белән төрле эчтәлектәге мәкаләләре дөнья күргән.

Әдәбият галиме Җәмал Вәлиди Р. Фәхреддинне иң беренче татар журналистларыннан санаган. Русиядәге 1905 елгы революцион үзгәрешләр уңаеннан язган бер мәкаләсендә ул «хөррият сәгате сугу илә фикер вә каләм хезмәтенә башлаган затларымызга бер карау йитсә кирәк. Габдеррәшид казый, Гатаулла Баязидов, Ризаэддин казый, Фатыйх Кәримев, Һади Максудов!.. Иштә безнең иң элекке журналистларымыз» дип язган. Икенче бер хезмәтендә Җ. Вәлиди «Шулай итеп, дин галиме журналистка әйләнде. Бу өлкәдә ул лаеклы һәм, беркадәр дәрәҗәдә, искиткеч хезмәткәр булып чыкты. Татар газеталары үзләренең башлангыч дәверләрендә нәкъ менә шундый, әдәби талантны мөселман гыйлемлеге

белән берләштерүче кешеләргә мохтаҗ иде. Бертуган апасының улы (ягъни Фатыйх Кәрими – Р.М.) белән ул «Вакыт» газетасын татар газеталары арасында беренче урынга куйды» дип үз фикерләрен ачыграк белдерә.

Югарыда бәйан ителгәннәрне җыеп әйткәндә, Р. Фәхреддин «Шура» журналындагы эшчәнлегенә кадәр үк бай иҗтимагый, гыйльми һәм әдәби, журналистлык тәҗрибәләренә ия булып, үзен абруйлы галим һәм каләм әһеле итеп таныткан.

Россиядә яшәүче төрки-татарлар арасында иң күп таралган газеталарның берсе – «Вакыт»ның наширләре бертуган Рәмиевләр 1907 елның 13 декабрендә татар телендә «Шура» исемле журнал чыгаруга рөхсәт алалар. Шул хактагы таныклыкта журналның җаваплы мөхәррире Ризаэддин Фәхреддин булачагы күрсәтелгән. Аңа бу вакытта 48 яшь булган.

Җ. Вәлиди «Шура»ны Р. Фәхреддин өчен махсус оештырылган журнал дип яза. Төгәлрәге, Җ. Вәлиди болай ди: «Ул (ягъни Р. Фәхреддин – Р.М.) газета тормышының мондый шау-шулы, тынгысыз мохитендә озак кала алмый иде. Инде чәчләре чаларган һәм үзе дә тыныч табигатьле булган галимгә җитдирәк һәм иҗади эшләргә бирелү өчен тынычрак бер урын кирәк иде. Һәм менә, 1908 елда, аның өчен «Вакыт» газетасы каршында ике атнага бер чыга торган «Шура» журналы оештырыла». (Тәрҗемә безнеке – Р.М.).

«Шура» журналының дистә ел буе тотрыклы чыгып килүе, эчтәлеге саекмавы һәм укучыларын югалтмавы, бер яктан, наәширләренең журналга зур әһәмият биреп, даими кайгыртучанлык күрсәтүләрендә һәм мөхәррир белән килешеп эш-гамәл киртүләрендә. Икенче яктан, Р. Фәхреддиннең, мөхәррир буларак, фидаиларча бөтен күңелен, белем вә сәләтен, вакытын һәм энергиясен журналга багышлавында. 1911 елда жандарм тентүе нәтиҗәсендә Р. Фәхреддин өеннән башка кулъязмалары белән бергә «Шура» өчен әзерләнгән үзенең һәм бүтән авторларның

мәкаләләре, язмалары конфискацияләнүгә карамастан, журналының тотрыклы чыгуын тәэмин иткән.

Журналда басылган аеруча әһәмиятле, гыйльми җәһәттән нигезле мәкаләләрнең күпчелеге Р. Фәхреддин каләменә бәйле.

Р. Фәхреддиннең «Шура» журналындагы мәкаләләре яшәешнең күп төрле мәсьәләләренә, ягъни фәлсәфә, тарих, дин, мәгариф, иҗтимагый, әдәбият, матбугат, сәнгать һ.б. мәсьәләләргә багышланганнар. Күләмле, тарихи һәм аерым шәхесләргә багышланган фәнни мәкаләләре «Мәшһүр адәмнәр вә олуг хадисәләр» бабы-рубрикасында басылып чыкканнар. Ризаэддин Фәхреддиннең «Шура»да дөнья күргән мәкаләләренең бер өлеше үз имзасы белән чыккан булса, күпчелеге имзасыз да басылганнар. «Шура» журналында Р. Фәхредциннең имза белән чыккан публикацияләре – барлыгы 146. Р. Фәхредциннең тормыш юлын һәм эшчәнлеген өйрәнүчеләрдән галим Миркасыйм Госманов «Шура» мөхәрриренең журналдагы мәкалә һәм язмаларының саны 700 гә якын дип белдерә. Равил Үтәбай-Кәрими дә шул санны атый. Мәдинә Рәхимкулова мәгълүматларына караганда, «Шура» журналында Р. Фәхредциннең барлыгы (имзалы һәм имзасызлары бергә) 312 публикациясе дөнья күргән.

Олуг галимнең «Шура» битләрендә төрки-татарлар тарихы буенча язылган күпсанлы мәкаләләреннән татарлардан гайре башка төрки халыклар да кыйммәтле мәгълүмат алганнар.

Ризаэддин Фәхреддин «Шура» журналының ябылган көненә (ягъни 1918 елның гыйнварына) кадәр мөхәррире булып калган. Журнал ябылуны бик авыр кичергән өлкән яшьтәге галим «шушы хезмәтемдә күп еллар дәвам итү өметем булса да, тәкъдир икенче төрле булды, кулыбыз тотылды, каләмнәребез сынды» дип, эшсез-чарасыз калудан һәм акчасызлыктан, гаиләсе белән, Оренбургтан китәргә мәҗбүр булган. Хушлашканда журнал нашире Закир Рәмиевнең «Дөньялар тынычланып, «Шура» жур-

налы чыгу ихтималы булса, кире кайтыр идегезме?» – дигән соравына: «Һичшиксез, кире кайтыр идем», – дип, зур өмет белән җавап биргән.190

Иҗтимагый тормышны әтрафлы колачлаган, мәгълүматка бай энциклопедик журнал булып «Шура»ның XX йөз башы татар матбугаты мәйданында үзен танытуы, беренче нәүбәттә, мөхәррире – олуг гыйлем иясе Риза казыйның эрудициясе һәм тырышлыгының гүзәл нәтиҗәсе.

Тарихчы галим Миркасыйм Госманов Р. Фәхреддиннең зур хезмәтләренә сокланып «...ул – дин тарихчысы, ислам философы, ул – «Сәлимә», «Әсма»ны биргән язучы, ул – монументаль «Асар»ны төзүче биограф-тарихчы («Мәшһүр ирләр» һәм «Мәшһүр хатыннар» циклын да шунда кертеп исәплик), ул – актив язышкан журналист, ул – заманына күрә энциклопедик гыйльми журнал булган «Шура»ны оештыручы редактор, ул – Шәрык буенча бик күп хезмәтләр биргән ориенталист, ул – ялыкмас педагог, ул – дини вәгазьче, ул – Европа культурасының пропагандисты, ул – тәнкыйтьче, ул – библиограф, ул – тәрҗемәче һ.б., һ.б. Бер кеше өчен бик күп, әмма Р. Фәхреддинов боларның барысын да эшләгән» дип, тәкъдир итеп язган сүзләрен искә төшерү бик урынлы булыр.

«Шура» журналы мөхәррире Р. Фәхреддин авырып яисә башка сәбәпләрдән булмаган очракларда журналның мөхәррирлек вазифалары икенче, ә икесе дә булмаганда, өченче мөхәрриргә тулаем йөкләнү мәсьәләсе дә каралган булган. Мәсәлән, Оренбург губерна идарәсеннән 1911 елның 7 июнендә бирелгән 3451 нче номерлы таныклык нигезендә Борһан Шәрәфкә «Шура»ның 2 нче, шул ук елның 2 июлендә 6911 нче номерлы таныклык буенча Фатыйх Кәримигә 3 нче мөхәррире вазифалары йөкләнгән. 1914 ел, 14 мартта бирелгән шәһадәтнамә буенча Габдрахман Ризаэддин улы Фәхреддиневнең 2 нче мөхәррир булып раслануы мәгълүм. Ә 1916 елның 16 ноябрендә 11666 номерлы таныклык «Шура» журналының 2 нче мөхәррире вазифаларының Җәмалетдин Җәлалетдиновка (Җәмал Вәлидигә) йөкләнүен белдерә.

Журналның мөхәррире Ризаэддин Фәхреддин XX гасыр башында ук каләм куәсе, үзенчәлекле өслүбе белән татарлар арасында киң танылган булган. Аның иҗат каләме «Сәлимә» һәм «Әсма» кебек әсәрләре белән матур әдәбият мәйданында сыналган. Болардан тыш Р. Фәхреддиннең төрки-татар газеталары, бигрәк тә, Оренбургта нәшер ителгән «Вакыт» газетасындагы 1906-1907 еллардагы фидакяр журналистик эшчәнлеге дә зур роль уйнаган. «Шура» журналының әдәбиятка мөнәсәбәте, әдәби зәвыгы да, нигездә, мөхәрриренең әдәбиятка карашларын чагылдыра. Ризаэддин Фәхреддиннең «Шура» эшчәнлеге дәверендә әдәбиятка, хосусан, шигърияткә беркадәр талымсыз булган, битарафлык күрсәткән дигәнрәк фикерләр белән ризалашасы килми. Чөнки «Шура»ның рухы һәм җаны булган Р.Фәхреддиннең журналда иң күп урын бирелгән әдәбият мәсьәләсенә битараф кала алу ихтималы һич мөмкин хәл түгел. Әйтик, әдәбият галиме М. Мәһдиев «Р. Фәхреддиновның шигырьдә талымсыз булуы – үзе бер кызыклы күренеш. Ул, журналында, яхшы шигырь белән начар шигырьне аерып тормаса да, чын шигырьнең нәрсә икәнен аңлаган булса кирәк» – дип язган иде. Яисә Зариф Бәшири хатирәләрендә «Үз вакытында «Сәлимә» шикелле шактый матур әдәби нәрсәләр язган Риза казый нәрсә өчендер: «Мин әдәби нәрсәләрне матур иттереп эшли дә, төзәтә дә алмыйм, әдәбияттан, бигрәк тә, шигырьдән хәбәрем дә аз!» – дип, әдәби нәрсәләргә кул салмый иде» дигән юллары бар. Р. Фәхреддин бу очракта үзе турында әдәбият өлкәсендә хәбәрсез дип әйтүенә нигезләнеп, аны талымсыз һәм битараф дип санау дөрес булып бетмәс. Бу сүзләрне ул гыйльми хезмәтләр белән күбрәк шөгыльләнү максатыннан, шигърияттә яшьләргә өстенлек биргәнлектән һәм тыйнаклыгы сәбәбеннән әйткән дип уйларга кирәк. З. Бәширинең үз сүзләре белән әйткәндә, Риза казыйның «үзе редактор, үзе секретарь, үзе әдәби сотрудник, хәтта редакциягә килгән хат һәм материалларны да күчереп чыгучы» булганлыгын һәм «Шура» журналының еш, ике атнага бер мәртәбә чык-

канлыгын искә алганда, әдәби, шигъри әсәрләрне журнал өчен әзерләүне редакциянең башка бер хезмәткәре, төгәлрәге, үзе дә шагыйрь булган З. Бәширигә тапшыруы мантыйкка сыешлы һәм табигый.

Ризаэддин Фәхреддин Шәрык әдәбияты һәм шигъриятеннән, шулай ук Европа, аеруча татар шигъриятеннән хәбәрдар булып кына калмыйча, татар әдәбияты тарихына мәртәбәле өлеш керткән галим дә. Р. Фәхреддин гарәп, фарсы, төрек, татар һ.б. төрки телләрдәге шигырьләрне искиткеч яхшы белгән һәм яраткан. «Без – шигырь сөючеләрдәнмез. Хәтта бәгъзе бер шигырьләр фикеремезгә рух, рухымызга куәт бирер» дип белдерә ул бер мәкаләсендә. Галимнең әдәбият тарихы буенча гына түгел, тарихи, фәлсәфи һ.б. темаларга язылган хезмәтләрендә һәм мәкаләләрендә дә, форсатына күрә, фикер-дәлилләрен бик оста һәм килешле итеп, гарәп, фарсы һ.б. телләрдәге шигъри юллар белән куәтләү гадәте булган. Р. Фәхреддиннең иҗади һәм гыйльми мирасы белән таныш затлар өчен бу, әлбәттә, яңалык түгел.

*Рәиф Мәрдановның*

*«Шура» журналы (1908-1917). Әдәбият мәсьәләләре» китабыннан,*

*«Рухият» нәшрияты, 2001*

# Әдәби сәхифә

# Күңел күзе

Сентябрь аеның ямьле, җылы көннәрендә, эшем белән бәйле берничә мәсьәләне хәл итү максатыннан, миңа ерак юлга сәфәр кылырга туры килде. Өйдән, инде ияләнгән җирдән чыгып китүне күңелем, бер яктан, авыр мәшәкать итеп кабул итсә, икенче яктан – ниндидер уңай нәтиҗәгә, яңа очрашуларга һәм эчке халәтемне үзгәртердәй тәэсирләргә өметләнде. «Сәфәр кылыгыз – тукланырсыз һәм сәламәтләнерсез» дигән хәдиснең мәгънәсен аңлатканда да дин галимнәре: «Тукланырсыз, димәк, гыйбрәтләнерсез; сәламәтләнерсез, димәк, уй-фикерегезне төзәтерсез», – дип шәрех кыла бит...

Юл чыннан да ерак, ә сәфәрем нәтиҗәле вә мәгънәле булып чыкты. Кайтыр юлым гына әүвәл бераз бимазалы булды: күпмедер вакыт дәвамында поезд купесында ике салмыш ир-егет белән барырга туры килде. Әмма аларны күзәтеп утыру да үзенә күрә бер гыйбрәт иде, чөнки шул егетләргә карап, шайтан кармагына эләккән, динсез, кыйбласыз яшәгән кешеләрнең халәте никадәр аяныч икәнлегенә тагын бер кат инандым.

Аллаһның рәхмәте, алар белән бик озак барырга туры килмәде: Чабаксар шәһәренә килеп җиткәч, сәрхуш ирләр, безнең якка әйләнеп тә карамыйча, шау-шу килеп, поезддан төшеп калдылар. Тавыш тынды һәм без, шулай итеп, купеда икәү генә калдык. Каршыдагы ханымны, әллә яулыгын артка бәйләп куйгангамы, әллә йөзендә ниндидер милли чалымнар чагылгангамы, гади татар апасы, дип кабул иттем мин. Ул беравык дәшмичә, олысымакланып утырды, соңыннан исә, нәрсәнедер исенә төшергәндәй, әйберләрендә актарына башлады. Йөзенә караганда, инде пенсия яшенә җиткән мөлаем, күзлекле бу татар апасы өстәлгә тышына «Бекон» дип язылган ярты таяк колбаса чыгарып куйгач, аптырап киттем. Йөрәгем шундук: «Бу бит дуңгыз итеннән ясалган колбаса!» – дип кычкырып җибәрсә дә, телем нигәдер апакайга дәшмәде. Эчтән генә: «Яшьләр

хәрам белән хәләлне аермый, дип зарланабыз, ә бу бит олы яшьтәге апа!» – дип ачынып уйлап куйдым.

Уф, наканис, котылдык бу исерекләрдән! – диде җиңел сулап апа, һәм кулына пычак алып, колбасасын турый башлады.

Купега таралган ис яманнарның яманы булып тоелды. Шулвакыт ханым колбасаның бер телемен ипи кисәге өстенә куйды да, йомшак тавыш белән дәшеп, «көчтәнәчен» миңа сузды:

Авыз итеп карагыз, ысвежий, бүген генә сатып алган идем...

Мондый форсатны кулдан ычкындырырга ярамый иде. Моңарчы күңелемдә бикләнеп торган сүзләр, атылып, тышка чыга башлады.

– Апа, исемегез ничек?

– Тәнзилә апаң булам...

– Ә сез, Тәнзилә апа, бу колбасаның дуңгыз итеннән ясалганын беләсезме?

– Бер дә игътибар итмәдем шул... Ә нәрсә – чучка ите дә ит бит инде, хәзер аны кем аерып торган...

– Мөселманнар ризыкның кайсы хәрам, ә кайсы хәләл икәнен, һичшиксез, аерырга тиеш, апа. Менә исерекләр белән бергә бару бер дә рәхәт түгел иде бит, ә Аллаһы Тәгалә аракыны тыйган кебек, дуңгыз итен ашауны да катгый рәвештә тыйды. Димәк, шушы колбасагыз – хәрам!

Ханым бераз югалып калгандай булды, аннары исә болай диде:

– Дуңгыз итен ашаудан мин исермим һәм беркемгә дә зыян салмыйм. Тәмле икән, нигә әле аны ашамаска?

– И, апа, – дидем мин, тәрәзәне ачарга дип басып, – динебез буенча ярамый икән, димәк, ашамаска кирәк. Исермәсәгез дә, ул бит күңелне каралта, Аллаһтан ерагайта торган нәрсә.

Тәнзилә апа бермәл дәшмичә утырды. Соңыннан, миңа игътибар белән текәлеп, сорау бирде:

– Башыңа түбәтәй дә кигәнсең – мулла түгелдер бит?

Дини уку йортында мөгаллим булып эшләвемне әйткәч, апаның йөзе яктырып киткәндәй булды:

– Дин үзе, чыннан да, начарлыкка өйрәтми инде ул. Шулай да, безнең әби-бабаларыбыз гел дә намаз укып яшәделәр, ә барыбер рәхәтне күрмәделәр, бил бөгеп, бер сынык икмәк өчен тырышып эшләделәр. Ә хәзер нәрсә? Кем әйтмешли, бар да бар, дин белән намаз гына юк.

Моның ише «мантыйк» белән инде таныш булганга күрә, мин, артык уйлап тормыйча, болай дидем:

– Безнең әби-бабаларыбыз, апа, намаз укып Аллаһ каршындагы бурычларын үтәделәр, чөнки намаз ул – фарыз, ягъни Аллаһы Тәгалә кушкан гамәл. Аллаһы Тәгалә бит адәм балаларын бу дөньяга сынау өчен җибәрә. Менә ул заманда безнең әби-бабаларыбыз юклык, нужа белән сыналды, һәм гыйбадәтләрен кылучылар бу сынауны лаеклы узды. Хәзерге буын исә муллык, байлык белән сынала. Ләкин, безнең өлкәннәребез әйткәнчә, кеше авырлыкка түзә, ә рәхәткә «чыдый алмый». Менә сез дә, базар хәләл колбаса белән тулып торган заманда, аны-моны уйлап тормыйча, «Бекон» дигәнен алгансыз. Бу – рәхәткә чыдый алмау була да инде.

Ханым тагын тынды. Кызарып киткән йөзен тәрәзәгә таба борып, ул нәрсәдер турында уйланып утырды. Перронда халык мәш килә иде: кемдер вагоннарга кереп урнаша торды, кемдер озатты... Сентябрьнең назлы, әмма инде сүрәнрәк кояшы безнең купе тәрәзәсен йомшак нурлары белән сыйпап алды да, болытлар артына качты. «Поезд кузгалып китүгә 5 минут калды. Пассажирларның үз урыннарына урнашуын, озатучыларның вагоннардан чыгуын үтенәбез», – дигән игълан яңгырап бетүгә, ишек ачылды һәм купебызга өлкәнрәк яшьтәге ир-ат белән 25 яшьләр тирәсендәге егет килеп керде. Сыйсыз көннең сүрәнлеген онытырып, егет киң итеп елмаеп җибәрде. Безнең белән исәнләшкәннән соң, абый аңа дәшеп әйтте:

– Улым, урының менә шушы өстәге киштәдә булыр, әйберләрне исә бирегә – аска урнаштырыйк.

Егет бер өскә, бер аска карап алды да, елмаюын йөзеннән югалтмыйча, сумкаларны урнаштырып куйды. Алар ыгы-зыгы килгән арада, поезд кузгалып китте һәм, тизлеген әкренләп арттыра төшеп, үз көенә алга таба юнәлде. Абзый минем яндагы урынга утырды, улы исә, шулай ук сәер елмаеп, ачык тәрәзә янына басты да, башын тышка чыгарып, кычкырырга тотынды:

– Әти! Әнә күпме кеше йөри! Әти! Әнә вокзал! Әти! Бөтен нәрсә артта калып бара, ә без алга таба барабыз! Әти!

Тәнзилә апа миңа шомлы караш ташлап, борын астына гына мыгырдап куйды:

– Булган икән, түти…

Егет үзен бераз сәеррәк тотса да, карап торышка акылга зәгыйфь кешегә охшамаган иде: нәзакәтле буй-сыны, чибәр йөзе, акыллы карашы аны сау-сәламәт, хәтта затлы, нәфис кыяфәтле бер бәндә итеп күрсәтте. Ләкин апа, хафаланып, хәвеф-хәтәр булмагае дип, инде куркуга төшкән иде.

– Әти! – дип, куллары белән күккә ишарә кылып, кычкыруын дәвам итте егет. – Ә күктәге болытлар артта калмый – безнең белән бергә бара! Әти! Әнә урман башланды! Ай, әти!!! Әнә күл, ә күлдә ике аккош йөзә! Әти!!!

Улы купены яңгыратып, ду килеп кычкырып торуга карамастан, абзый, бернәрсә дә булмагандай, тыныч кына утыруын дәвам итте. Күзләрен кысып, ирен читләре белән елмаюыннан, улының үзен шулай тотуына аның бер дә исе китмәгәне күренеп тора иде.

Күк йөзе болытлар белән тәмам капланып, тәрәзәдәге манзара тоныкланып китте. Әмма егетнең йөзе әле һаман балкып тора иде. Бар җиһанны сагыш-пошаманга уратып, әкрен генә моңсу яңгыр ява башлады. Купе тәрәзәсен чылата башлаган кыюсыз тамчылыр, табигатьнең моңзарларын белдергәндәй, пыяладан күз яшьләре сыман агып төшә барды.

Хәлнең хикмәтенә төшенеп бетә алмыйча, мин дә яшь сәфәрдәшемә карап: «Шулай да була икә–ән...» – дип күңелемнән генә аны нигәдер кызганып куйдым. Ләкин егет бер дә боекмады: ике кулын да алга таба сузып, яңгыр тамчылары аңа кагылуыннан ихлас шатланып, тагын сөйләнергә тотынды:

– Әти! Яңгыр ява, яңгыр! Аның тамчылыры минем кулга төшә! Кара, әти, менә ул тамчылар, менә!!!

Егетнең шушы кыланмышларына моңарчы әллә ни игътибар итмәгән әти кеше бу юлы торып басты да:

– Ярар, улым, бик хуп, болай яңгыр яуган чакта ачык тәрәзә белән бару бик килешмәс, әнә апага да суык тиюе бар, әйдә, утыр әле урыныңа, – диеп, тәрәзәнең ачылган өлешен ипләп кенә ябып куйды. Шуннан соң абзый, бәдрәфкә барып киләм, дип чыгып китте, егет исә  апа янындарак утырды да, ике кулын өскә чөеп алып, нәрсәдер пышылдый башлады. Бераздан алга таба иелеп, рөкугъ–сәҗдәне алыштыручы хәрәкәтләрне кыла башлагач, мин: «Сөбхәнәллаһ! Бу бит намаз укый...» – дип гаҗәпләнеп уйлап куйдым. Әмма Тәнзилә апа моны белми иде. Җилкәсе өстеннән генә шик вә куркуны чагылдыручы карашын егет тарафына төбәп, ул тавыш-тынсыз гына утыргычның почмагына шуышты.

Егет намазын укып бетерүгә, купега әтисе килеп керде.

– Әлхәмдүлилләһи, шөкер! Менә тәһарәтне дә яңарттым, – диде ул канәгать тавыш белән. Аннан соң безгә дәшеп, йомшак кына тавыш белән, гафу үтенгәндәй, әйтте:

– Инде ачуланмассыз, без намаз укучы кешеләр, мосафирлар буларак утырып кына икенде намазын укып алмакчы идек.

– Әти, ә мин инде укыдым, – диде егет, күзләрен сөенечле ялтыратып. – Тәһарәтем бар иде, шуңа күрә укып куйдым, әлхәмдүлилләһ...

– Ярый, улым, син, алайса, урыныңа менеп ят та, бераз ял итеп ал, бүген йокламадың да  диярлек... – дип, абзый өстәге киштәнең урын-

җирен рәтләп куйды. Улы өскә менеп урнашкач, абзый намаз укып алды, аннары тәсбих тартты. Ул арада егет инде йокыга талган иде.

Үзе өчен бик сәер тоелган шушы хәлләрдән агарынып беткән Тәнзилә апа, бармагы белән өстәге киштәгә күрсәтеп, каршысында утыручы абыйга әкрен генә, пышылдап диярлек, дәште:

– Күптән шулаймы?

– Ничек шулай? – диде абзый, ханымның соравын аңлап бетермичә.

Тәнзилә апа ике кулын баш турысына күтәреп, бишбармаклап чигәсе тирәсендә әйләндергәләп алды:

– Ну, тумыштан шундыймы, әллә соңрак берәр хәл булдымы?

– Ә–ә... Юк, тумыштан түгел. 14 яшеннән шулай булды.

– Харап икән... – дип ысылдавын дәвам итте апа. – Берәр чарасын күрдегезме соң? Дәвалап карауны әйтәм... Хәзер бит Мәскәү, Питербургларда яхшы белгечләр бар, диләр. Анда булмаса, хет чит илгә алып барасы иде...

– Башта Казанда, аннары Мәскәүдә консультацияләрдә булдык, бик зур белгечләр, профессорлар карады улымны, нәтиҗәдә, иң яхшысы – Чабаксардагы Фёдоров клиникасында операция ясату, дип киңәш бирделәр безгә табиблар, – диде абзый.

– Ә причум монда Фёдоров клиникасы? Ул бит күзне дәвалый торган бульнис, ә сезнең малай...

Тәнзилә апа әйтергә теләгәнне абзый аңлап бетердеме-юкмы – әйтүе кыен, ләкин бирелгән сорауга җавап шундый булды:

– Улыма хәзер 24 яшь. 14 яшендә, каты авырудан соң өзлегеп, аның күз күрүе бик начарайды. Ни генә эшләп карамадык – файдасы булмады, һәм улым тулысынча сукырайды. Тумыштан сукыр булу – бер хәл, ә бу очракта бит – әле күптән түгел иптәшләре белән футбол уйнап йөргән үсмер малай, дөнья матурлыгына сөенеп яшәгән чагы... Бу кайгыны ул үзе дә, әнисе белән мин дә бик авыр күтәрдек. Еллар уза торды, дәвалануның

бер нәтиҗәсе булмады. Шуннан соң мәчеткә йөри башладым, намазга бастым, төннәрен исә елый-елый дога кылып, Аллаһка ялвардым... Улым да намаз укый башлады, «зинһар, күз күрүемне кайтар», дип Аллаһтан ихлас күңелдән сорады. Баштарак мин дә чит илләрдәге клиникаларга зур өмет багладым, ә шифасы үзебезнең илдә, Чабаксарда табылды. Бер ай элек улыма операция ясадылар. Бик уңышлы булды ул операция. Хәзер уйлыйм: нигә шушы нәтиҗәгә элегрәк ирешә алмадык икән? Фикер йөрткәннән соң, үз-үземә җавап та бирәм: чөнки Аллаһы Тәгалә безне шулай сынаган һәм гыйбадәтләребез бәрабәренә безне бик сөендергән. Улымның үзен шулай тотуына сез аптырагансыздыр, ләкин аны гаеплисем килми: дәваханәдән бүген генә чыктык, һәм 10 ел якты дөньяны күрмәгәннән соң, ул шул дөнья белән әле яңа гына танышып килә...

Тәнзилә апа, күз карашын идәнгә төбәп, сүзсез калды. Ә мин исә, ирексездән, өске киштәдә йоклап яткан егеткә күз салдым: ирен читләрендәге елмаюыннан аның ниндидер матур, гаҗәеп төш күреп ятуын аңлап була иде. «Әнисе белән очрашканын күрәдер... Ә, бәлки, бүген купе тәрәзәсеннән күреп алган ике аккош төшенә кергәндер... Шуларны үзе һәм булачак хәләл җефете белән тиңләп, шушы киң, искиткеч гүзәл дөньяда бәхетле яшәүләрен күз алдына китергәндер... Йә, Аллаһ...».

Аннары почмакта посып утыручы ханымны исемә төшереп, шунысын да уйлап куйдым: инде гомер иткән шушы татар апасының күзе күрсә дә, ул әлегә кадәр үз Раббысын тапмаган, Аңа таба бер адым да ясамаган. Ә шушы яшь егет, күзе дөм сукыр хәлдә булуына карамастан, Раббысын таба алган. Чөнки аның маңгай күзе күрмәсә дә, күңел күзе ярдәмендә ул туры, дөрес юлны күргән һәм, Аллаһның җитәкчелеген кабул итеп, Аңа ихлас мөрәҗәгать итү бәрәкәтендә зур бәладән имин булган...

Поезд тизлеген әкренәйтеп, туктый башлады. «Бу нинди станция икән» дип, без өчәүләп башларыбызны тәрәзәгә таба бордык. Мин пер-

ронда кешеләрнең күп булмавына һәм, коерыкларын болгый-болгый, берничә этнең бер-берсе белән уйнавына игътибар иттем.

– Кая, энем, ач әле тәрәзәне! – дип кинәт дәште миңа Тәнзилә апа.

«Һава җитмидер» дип, мин, апаның гозерен үтәп, тәрәзәне ачып җибәрдем. Шул мәлдә Тәнзилә апа өстәлдә яткан колбасаны алды да, перронда бөтерелеп торган этләргә ыргытты. Шуннан соң башын тышка чыгарып, күтәренке тавыш белән кычкырып җибәрде:

– Мәгез, мәхлуклар, сыйланыгыз әле! Сезгә хәләл белән хәрамны аеру кушылмаган. Ә менә безгә, адәмнәргә, боларны аеру кирәк, чөнки Аллаһы Тәгалә шулай куша. Белдегезме, мәхлуклар? Ә? Аллаһы Тәгалә шулай куша!

## Җиде могҗиза

География дәресе тәмамланып килгәндә, мөгаллимә, укучыларга дәшеп, болай диде:

– Шулай итеп, балалар, без сезнең белән Кытай дәүләте турындагы гомуми мәгълүмат белән таныштык, ә Бөек Кытай дивары – хәзерге җиде могҗизаның берсе булуын билгеләп үттек.

– Ә ни өчен аны «могҗиза» дип атаганнар?

Укучыларның шушы беркатлы соравына җавап итеп мөгаллимә әйтте:

– Могҗиза – димәк, әлеге күренеш соклануга, гаҗәпләнүгә лаек. Кешеләр шушы күренешкә игътибарларын юнәлткәндә, аны барлыкка китерүченең осталыгына шакката, «ул моны ничек шулай эшли алган икән?» – дип бик аптырый.

– Апа, – дип мөрәҗәгать итте укытучыга бер малай, – ә шушы җиде могҗизаның калганнары нинди? Алар турында да сөйли алмассызмы безгә?

– Бик кызыксынсагыз, бу хакта мин сезгә киләсе дәрестә тәфсилләп сөйләрмен. Ә хәзер – дәреснең ахыргы ун минутында – бер кечкенә генә

бирем: һәрберегез, иптәшләрегез белән киңәшмичә, сөйләшмичә генә, үзегез өчен бу дөньядагы иң гаҗәп, могҗиза дип атарлык җиде галәмәтне дәфтәрләрегезгә язып куегыз. Бирем аңлашылдымы? Алайса, яза башлыйбыз!

Укучылар бер мәлгә тын калдылар. Әмма бераздан, кемдер әтиәнисе сөйләгәнен, кемдер интернетта укыганнарын исенә төшереп, дөньяның «җиде могҗизасы – шушы алар», дип уй-фикерләрен дәфтәр битенә төшерә башладылар.

Дәрес бетүен белдереп, кыңгырау тавышы ишетелде. Дәфтәрләрне җыя башлаган мөгаллимә, яулыклы бер кызның әле һаман язып утырганын күргәч, аның янына килеп:

– Әле әзер түгелмени? Сиңа, бәлки, ярдәм итәргәдер? – дип сорады.

Мөселман гаиләсендә тәрбияләнеп үскән шушы яулыклы кыз бик тырыш һәм сыйныф эшләрен, гадәттә, иң беренчеләрдән булып эшләп бетерә иде. Ә бу юлы, нишләптер, соңарды…

– Йә, ярдәм итимме? – дип кабат дәште аңа укытучы.

– Юк, апа, юк, кирәкми, – диде кыз бала, елмаеп.– Бу дөньяда могҗизалар шуның кадәр күп, кайсысын сайлап алып языйм икән, дип аптырап уйлап утырганым аркасында гына бераз тоткарландым. Шулай да, җавабым әзер, дәфтәремне алсагыз да була.

Ләкин мөгаллимә, кызның «бу дөньяда могҗизалар шуның кадәр күп!» дигән сүзләренә хәйран калып, болай диде:

– Синең җавабыңны сыйныфташларың да белсен, үзләренеке белән чагыштырсын. Әйдәле, торып, язганнарыңны кычкырып укы.

Яулыклы кыз бераз югалып калды, хәтта кызарып китте, ләкин укытучының кушканын үтәп, торып басты да, дулкынланып укый башлады:

– Бу дөньяда могҗизалар бик күп. Мин шулардан үземне бик тә гаҗәпләндергән, таң калдырган шушындый искиткеч җиде галәмәтне сайлап алдым. Минем өчен җиде могҗиза ул – сабый балаларның бу

дөньяга тууы, күрү, ишетү, йөрү, ризыкның тәмен тою, тән белән сизү, җан белән хис итү, ягъни моңая һәм бу дөньяның матурлыгына сөенә белү...

Сыйныфта тынлык урнашты. Мөгаллимәнең күзләре яшьләнгәнен күреп алган кыз ничектер каушап китте, шуңа күрә үзендә нindидер гаеп юк микән дип, аклангандай, әйтеп куйды:

– Апа, Сез бит үзегез: «Могҗиза ул – соклануга, гаҗәпләнүгә лаек күренеш һәм кешеләр аны барлыкка китерүченең осталыгына шакката, «ул моны ничек шулай эшли алган икән?» – дип бик аптырый» – дидегез. Менә мин дә: «Аллаһы Тәгалә ничек безне шулай бар иткән икән?» – дип сокланып, гаҗәпләнеп яздым. Әллә дөрес түгелме?

Укытучы дәшмәде. Бу мизгелдә ул үз тормышында булган фаҗигале һәм бәхетле вакыйгаларны исенә төшереп, укучысының фикерләре тәэсирендә, тирән уйга баткан иде. Хикмәт шунда: озак еллар дәвамында ул ана булу бәхетенә ирешә алмыйча яшәде. Табибларның «бала алып кайта алмыйсың» дигән кырыс хөкеменә карамастан, өметен өзмәде, сәдакалар биреп, башка изгелекләр эшләргә тырышып, Аллаһка ялварды ул. Гаилә корганнарына 7 ел тулганнан соң исә могҗиза булды: тупырдап торган сау-сәламәт матур малай алып кайтты... Могҗиза булмыйча ни булсын?.. Әй, шул «җиде» саны, диген... Әллә шөкер итә белмәгәннәрме, малае, 7 яше тулгач, зур бәхетсезлеккә юлыга: таудан чанада шуып уйнаганда, капланып, бик каты бәрелә. Шуннан соң кара кайгыга чумган көннәр башлана... Улы 4 ел урын өстендә ята. Табиблар «аягына басачак» дип ышандырмады, киресенчә – юк, булмастыр, дип тәкрарлады. Ул вакытта түгелгән күз яшьләре... Бала бит... Әле ничек көтеп алынган бердәнбер бала! Бөтен өмет Аллаһта иде. Файдасы булмыйча калмас дип, әни кеше үзенең улын бер хәзрәткә өшкертергә йөртә башлый һәм... тагын могҗиза була – 11 яшьлек малае аягына баса! И-и, шул вакытта сөенгәннәре! Ул көнне исенә төшерсә, аның әле дә йөрәге кысылып куя: хастаханә палатасына килеп кергәндә, газизкәе елый-елый аягында басып тора иде.

Улының: «Әнием, мин үзем басып тора алам!» – дип күз яшьләре аша елмаеп дәшүен ул гомергә онытмас. Юк-юк, мондый Могҗизаны онытырлык түгел! Мең шөкер, хәзер улы сәламәт, инде студент булды, әмма... Гаиләсенә тагын бер кайгы килде: өлкән яшьтәге әнкәсе сукырайды бит... Гомер буе әйбәт кенә күрә торган күзләре дөм күрми торганга әйләнде дә куйды. Аны-моны бер дә уйламаганда... Шуның кадәр читен аның изаланып яшәвенә карау, әйтеп бетерә торган түгел... Күрү – могҗиза, дигән бу кыз бала. Әнкәсе сукырайганчы, моның турында уйлап та караган булмады, ә хәзер... Чыннан да, кеше ничек күрә, ничек ишетә, йөри, уйлый, хис итә? Адәм баласының күңеле башка җан ияләренеке шикелле түгел бит: ул моңлана да, шатлана да, үкенә дә, шөкер дә итә ала... Ләкин бик кызганыч, аһ, бик тә, бик тә кызганыч – шөкер итүебез җитенкерәми шул, Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтләрнең чын могҗиза булуын аңлап шөкер итү бездә әле бик аз... Бу төшенчәнең чын асылын аңа 7 ел элек малаен өшкергән хәзрәт бик тә үтемле итеп аңлатып биргән иде: «Шөкер итү ул – тел белән генә рәхмәт әйтү түгел. Ул – сиңа ярдәм иткән Раббыңа күңелең белән ихластан рәхмәтле булу, ә иң мөһиме – Ул кушканнарны үтәү...». Шул вакытта хәзрәт намаз укуның да әһәмиятен, намаз – Аллаһы Тәгаләгә шөкер итүнең бик мөһим ысулы булуын бик әйбәтләп аңлаткан иде, ләкин 7 ел узуга карамастан, ул әле һаман намазда түгел...

Яшь пәрдәсе каплаган күзләрен алга, каядыр билгесезлеккә юнәлткән мөгаллимәнең шулай тып-тын, дәшмичә басып торуына аптырап, яулыклы кыз, кыяр-кыймас аның кулына кагылды да, әкрен генә әйтте:

– Апа, язганнарым әллә дөрес түгелме?

– Дөрес, балакаем, бик дөрес, – диде мөгаллимә ишетелер-ишетелмәс тавыш белән, һәм, яулыклы кызның дәфтәренә «бишле» куйды да, күз яшьләрен сөртә-сөртә сыйныфтан чыгып китте.

*Ришат хәзрәт Курамшин,*
*Кукмара мәдрәсәсе мөдире*

۲۰ ذوالحجه ۱۳۲۵
۱۰ غنوار ۱۹۰۸
1908

نومیر ۱

پنجشنبه

اون بیش کونده برچققان ادبی فنی سیاسی مجموعه در.

# شورا



اورنبورغده کاروان سرای مسجدی

# „ شورا “

## مجموعه نك بابلری اوشبو ترتیبده بولنور :

۱) **مشهور آدملر والوغ حادثه‌لر.** بو بابده ایسکی ویگیلردن برزبیوك آدمنك ترجمهٔ حالی درج اولنور ، پادشاهلردن بحث ایدلندیگی وقت مملکتلرینك قسقه چه جغرافیه وتاریخی سویله نور.

۲) **مقاله‌لر** . بو بابده ادبی ، تاریخی ، اجتماعی مقاله لر بولنور .

۳) **تربیه وتعلیم** . بو بابده حفظ صحت، تدبیر منزل ، تعلیم ، مکتب ومدرسه ، شاکرد ومعلملرگه دائر بندلر یازلنور .

۴) **کشفیات واختراعات.**

۵) **متنوعه** . مملکت ایچنده وطشنده اولان هر تورلی خبر ومعلومات یازلنور.

۶) **تقریظ وانتقاد** . یڭی چیقمش اثرلر (کتاب ، رساله وغزته هم ژورناللر) حقنده معلومات ویرلور .

۷) **اجمال سیاسی** . روسیه‌نك ایچنده وطشنده اولان ایکی هفته‌لك سیاسی حاللر قسقه‌لق ایله بیان ایدلنور .

۸) **مراسله ومخابره** . سؤال جوابلر وهر تورلی مکتوبلر یازلنور .

۹) **حکایات . اشعار . لطائف ومقاللر .**

ناشرلری : محمدشاکر ومحمد ذاکر رامییفلر. محرری: رضاءالدین بن فخرالدین.

آبونه بدلی : ییللق دورت روبله — ٦ آیلق ۲ روبله ۲۰ کاپك .

«وقت» ایله برگه آلوچیلرغه ییللق بدلی ۳ روبله، ٦ آیلق ۱ روبله ۸۰ کاپك.

اجنبی مملکتلر ایچون بر ییللغی ۱۰ فرانق .

آدرس : Оренбургъ , редакція «ШУРО»

1908

۲۰ ذوالحجه ۱۳۲٤ — پنجشنبه — ۱۰ غینوار ۱۹۰۸

# شورا

آبونه بدلی :
سنه‌لك ٤ ؛ آلتی آیلق ۲ روبله‌در.
« وقت » برلن برگه آلوچیلارغه :
سنه‌لك ۷، آلتی آیلق ۳ روبله ۸۰ کاپك‌در.

آدرس:
Редакція « ШУРО » Оренбургъ — Rédaction du «Chouro» Orenbourg

اورنبورغده اون بیش کونده بر چققان علمی وادبی مجموعه‌در. — نومر ۱ — № 1

## مسلك ومقصد

حق تعالانڭ یاردمی ایله اوشبو « شوری » مجموعه سنی یازارغه وترتیب ایدرگه کرشدك. « شوری » نڭ مسلکی ایسه کوچی یتدیکی‌قدر روسیه اسلاملرینڭ سعادتلری حقنده خدمت ایتمکدن عبارت اولوب، مقصدی‌ده اوقوچیلرنی‌رضا ایدر ایچون ثبات وغیرت کوسترمکدر.

«شوری » ملتنی علملی، معرفتلی ایتمك حقنده مشورت مجلسی اوله‌چقدر. ایستدیکی کمسه اوشبو مجلسده سویلر وایستدیکی آدم‌ده دڭلار. اگر برطرفدن محترم ادیبلر ، محررلر ادبی ، علمی ، فنی مقاله‌لر یازوب طورسه‌لر وایکنچی طرفدن‌ده استفاده‌گه محتاج ذاتلر کوڭللنوب اوقور اولسه‌لر «شوری» اوزینڭ مسلکی اوزرنده مقصدینه ایرشمش اولور.

شخصیاتدن وغرضلردن صاف اولمق شرطی ایله ، ملت منفعتی آرزوسیله یازلمش مقاله وفکرلر ایچون « شوری » بیتلری هر وقت آچیقدر. قاعده‌سی ایله اولان انتقادلرنی « شوری » تشکر ایله قبول ایدر وبویله حقوقدن کندیسی‌ده مستفید اولور.

ومن الله التوفق.

رضاءالدین بن فخرالدین

قارغالی شاعری مرحوم صبغت الله حاجی‌گه یازغان بر مکتوبیدن

## قطعه

( ترك لهجه سن تقلید قیلب ماتاشقان چاقلارنڭ یادکاری بولسون . )

. . . . . .

افندم حضرتنه عاجزانه
بو تقدیم ایتدیکم شو بر فسانه

تلاد کلك عبد عاجزیدر
حصول حرث فکر ناچیزیدر

نقوش علمدن خالی مثالی
خطا اولماز اگر دیرسهم مثالی

هنوز کلمش جهانه بر صبیدر
ادیبلر درکهنده برغبیدر .

حجابندن دوشوب افغان و زاره
قبول ایتمزدی کیم درگاهه واره

ولکن اولمادی اول رسمدن شاذ
که عادتدر صبیلر کورمك استاذ

عزیمت ایلدی سوز کدازله
سنڭ درگاهکه عجز و نیازله

صولار ایتمزسه درکه لطف عالی
صباوت مهدنه یتمش نهالی .

۱۸۸٤ سنه درد مند .

## ای محرر!

( اوز لهجه مزده )

قانچه طارتساڭ ای محرر سوزنی چیت تل سیبنه
تل یاصالماس گرطوغان سوز یانماسا اوز ایبنه !
آلساڭ آل «سوز» لرنی چیتدن «حرف» لرگه بیرمه یول
کرتمه بر چیت لهجه‌دن «حرف» لهجه‌مز ترتیبنه
«حرف» لر تبدیل ایتب چیت لهجه‌دن آلماق «ادات»
بل مساویدر بنای روحمز تخریبنه
تل وجود سوزلر بدندر صرفی وترکیبی — روح
مقصدڭ گر خیر ایسه قوی تیمه تل ترکیبنه !

---

سوت ایمشکان همده‌مدر قان انیسمدر تلم
جان بیرب کونمم حریم وصلدن تغریبنه
مدعیلر ردنه گر یتمسه سوزم دلیل
توککنم کوز یشلرم یتسون آلار تأدیبنه

---

کرشن اینلکلرده یافساڭ برقرا تن بولماس آق
انجی آلماسلاردا بولماس زشت روغا زیب رو
«بولسا آق بارماقلارڭ نچکه قولاغڭ آل قولاق
آلتون آلقاسزدا سین کورکم بوزوکسزده صلو» (*)

---

تل وانب «نیل» لرنی قاندڭ ، برطانب کورنیندی تم:
بیرگانڭ بر بولغانق صو صالغانڭ واتق سبو !
قوی طبیعت حکمن ایتسون — شول تکامل، شوندا یم !..
کوتکانڭ بلکم «دلیل» در ؟.. باق دلیل: آلدڭدا... بو !

**دردمند**

---

(*) ایکی مصراع شیخ سعدیدن آلنمشدر.

# مشهور آدملر وبیوك حادثه‌لر

## جعفر بن عبدالله (آلماس بن سالکی)
(٣٣٢ ه - ٩٣٣ م)

بو کیمسه بابالرمز واصلمز اولان بلغار خلقینك پادشاهلرندن اولوب، الك ایلك مرتبه اوله‌رق مملکتمزده رسمی صورتده اسلام دینی نشر ایله‌مشدر. آتاسی سلکی، مجوسیت اوزرنده یاشاب وفات اولدیغی حالده آنك یرینه بلغار تختنه چیقدیغنده آلماس، مسلمان اولدش واسه‌ینی‌ده «جعفر» دیه آتامشدر.

تاریخ ضبط ایده باشلادیغی کوندن بیرو اوشبو مملکتده ترك قومی طورور ایدی. فقط اوشبو ترکلر قوم وقبیله‌لری ویا که‌سیاست جهتلری ایله فین، اسکیت، سارمات وغیری بو کبی مختلف اسملر ایله یوررلر ایدی. دورتنچی قرن میلادیده اوشبو قوملر نك اوستلرینه آتیلا اسمنده اولان قهرمان پادشاه قوماندا سنده اوله‌رق (١) مشرق طرفندن هونلر کلدیلر وبتون مملکتنی ضبط ایتدیلر. بوندن صوك هونلر ترك اسمیله وآنلردن ایلك اولان ترك قوملری ترکیچه «صاقلق» سوزندن آلنمش اواسه کرك «صاقلاب» دیه معروف اولدیلر (عربلر بونی — صقلب — صورتنده یازارلر وکندی لسانلری قاعده‌سیله — صقالبه — دیه جمع هم ایلرلر). هر بری ترك قومی اولدیغی مناسبتله یرلی قوملر ایله‌چیتدن‌کلمشلردن کوبلری بر بریله اختلاط ایدوب بولغانوب بتمشلردر. یرلی خلقلر اعتباریله بو قوملره «صاقلاب» وهونلر اعتباریله «ترك» دیدیکلری کبی بر بریله قاتشدقلری جهتدن «بلغار» دیه یورتور اولمشلردر. ایشته آلماس بن سلکی یاخود جعفر بن عبدالله اوشبو «صاقلاب» یاخود «بلغار» خلقلرینك بیوك حکمدارلرندن ایدی.

ایسکی بابالرمز اولان بلغار قومی آراسنه نه سبب ایله وقانغی تاریخده اسلام ظاهر اولدیغی حقنده قولمزده آچیق معلومات یوقدر. فقط اصحاب کرام عصرنده ایران دولتی ضبط ایدلدیکندن صوك ترکلر اسلاملره کورشی اولدقلرندن اسلام عالمی ایله اختلاط ایتدیکلری وبوسببدن ده اسلام قبول ایتدیکلری معلومدر. ترکلرنك مسلمانلر ایله قاتشمقلری واسلام قبول ایتدیکلری پك مقدم اولدیغندن ترکلر آراسنده پك بیوك عالملر، سیاسی آدملر یتشمشدر. ٣٥٦ تاریخنده وفات اولان ابوالفرج الاصبهانی‌نك «اغانی» سنده معروف شاعرلردن بر خیلیسی ترك قومینه منسوب اولدقلری آڭلاشلور. ٢٥٥ تاریخنده وفات وعرب عالملرینك الك بیوكلرندن اولان جاحظ، ترکلرنڭ فضیلتلرینی سویلاب مطبوع نسخه‌سی ٥٣ بیتدن عبارت، بر رساله یازوب وزیر فتح بن خاقان اوزرینه هدیه ایلمشدر. اگرده عراق وخصوصا «بغداد» و «بصره» ارده

---

(١) محیط المعارف، بونك اصل اسمی «اتل» اولدیغنی بیان ایلر. «اتل» ییلغه‌سی اسمیله مناسبتی وارلغی آشکاردر.

ترکلر بیوك اورنلر اشغال ایتمیه‌لر ایدی ، جاحظ کبی علم دکیزی بو طوغروده حرکت ایتماز ایدی. ایشته «بلغار» خلقینك دین‌مبین اسلامنی قبول ایتمکلرینه اوشبو یرلرده اولان ترك اکابری سبب اولمشدر. زیرا بونلرنڭ بلغار وخزرلر ایله قاتشوب وخطلر یازشوب طوردقلرنده شبهه اولنماز.

هر حالده جعفر اسلامنی قبول ایتدیکی صوڭ اوشبو وقتنڭ خلیفه‌سی اولان المقتدر بالله ابوالفضل جعفر بن المعتضد بن الموفـق بن المتوکل بلغارغه بر ایلچی‌هیئتی‌ییبارمشدر. اوشبو ایلچی هیئتنده کاتبلك خدمتنده اولان احمد بن فضلان بن العباس بن اسد بن حماد اوشبو طوغروده بر سیاحت نامه یازمشدر. بو کونده اوشبو سیاحت نامه نسخه‌سی تابلماز ایسده‌ده یاقوت حموی چوق یرلرینی اوزینڭ «معجم البلدان» نام کتابنه درج ایلامشدر.

بنا علیه ابن فضلان خبرلرینڭ جعفرگه منا سبتلی اولان قسمنی «معجم‌البلدان» دن آلوب بو یرده ترجمه ایتدك. ابن فضلان دیبور :

« صاقلاب » پادشاهی اولان آلماس بن سلکی (شلکی) بیلـکوار طرفندن دین اوگره توچیلر، مملکتنه مسجدلر ومنبرلر بناایدوچیلر، دشمانندن صاقلانورلق ایدوب قلعه صالوچیلر کوندررکه صوراب یازمش‌مکتوب امیرالمؤمنین المقتدر بالله اوزینه تابشرلدی. مکتوبنی کتوروچی وپادشاه ایچون ایلچیلك خدمتنی ایدوچی کیمسه نذیر الحرمی ایدی (بوکیمسه یاسودا ایله یاکه بالقصد اوشبو اش آرد‌ندن بغداددن بلغارغه وارمش کیمسه اولسه کرك ) بن پادشاهنك مکتوبنی اوقودم. همده پادشاه طرفندن خلیفه‌ومعتبرذاتلر، فقها ومعلملرگه دیه ییبارلمش هدیه‌لر تابشرلدی. خلیفه، پادشاهنك رجاسینی‌قبول‌ایدوب نذیر الحرمی‌نك آزادلیسی اولان سوسن الرسی نام‌ذات ریاستنده بلغارغه بر ایلچی هیئتی کوندردی .

بز ( ایلچی‌هیئتی ) ۳۰۹ تاریخی ۱۲نچی صفرده ( میلادی ایله ۹۲۱نچی ییل ۸ نچی ایون) بغداددن سفر ایدوب ، بخارا وخوارزم آرقلی بلغارغه واردق. برتاولك قدر مسافه قالدیغنده بلغار پادشاهی بزگه اوز قول آستونده اولان دورت پادشاهسنی، اوغلی وقارنداشلرینی قارشو ییباردی. بونلر بزنی ایکمك ، ایت، تاری ایله قارشو آلدیلر وبزنڭ‌ایله برابر بوردیلر. ایکی فرسخ مقداری یر قالدیغنده پادشاه اوزی هم بزگه قارشو کلدی وبزنی کوردیکی ایله آتندن توشوب شکر سجده‌سی قیلدی ( بوبله اشلرنی اوگرتوب طورو چیلر اولدیغی‌بیلنه‌در ) وبیگنده اولان کموش تنکه‌لرینی اوستمزگه ساچدی .

بلغارغه یتومز ۳۱۰ تاریخی ۱۲ نچی محرم (۹۲۲ میلادی ۸ نچی مای یکشنبه کون ) ده اولدی. خوارزمدن بلغارغه یتمش‌کون یوردك. ( بغداددن بلغارغه تمام اونبرآی یورکان اوله لر ) . حاضرلنمش چادرلرده چهارشنبه کون‌گه قدر ( ١٥ نچی محرم اولسه کرك ) طوردق ، بلغار مملکتنده اولان پادشاهلر وبیوك آدملر ، خلیفه‌نك‌مکتوبنی دکلار ایچون‌جیولدیلر. پنجشنبه کون اولدیغنده تیونلرمزنی چیشدك ، خلیفه طرفندن هدیه ایدوب ییبارلمش ایار ایله آتنی ایارلاب، پادشاه باشینه چالمه اورادق، اوستنه‌ده خلیفه‌لر دستوری بوینچه قاره کیوم کیدردك . شوندن صوڭ بن خلیفه‌نڭ مکتوبنی چیقاروب اوقورغه باشلادم. حرمت یوزندن پادشاه‌آیاق اوزره باصوب طوردی. بوندن صوڭ وزیر

حامد بن العباس مکتوبنی اوقودم، پادشاه همیشه آیاق اوستونده طوردی، حالبوکه کندیسی زور وآغر گوده‌لی آدم ایدی. پادشاه آدملری بزلرگه کمش تنکه‌لر ساچدیلر. بوندن صوڭ بز اولاشور ایچون هدیه‌لرمزنی چیقاردق. اوزلرینڭ عادتلری موجبنچه خاتونی پادشاه یاننده اوطورمشیدی، بز آڭاده خلعت کیورتدك. صوڭره چاقرولرینه کوره بز پادشاه قبه‌سینه واردق، اوڭ طرفنده پادشاهلر اوطورمشلر ایدی، امری بوینچه صول طرفینه بزلر اوطوردق. بالالری، قارشوسنده اوطوردیلر. اوزی بر یالڭزی رومی اطلس ایله پرده لنمش اوطورغچ اوزرنده ایدی. صوراوی بوینچه قزدرمش ایت کتوردیلر. پادشاه پچاق آلوب اوچ مرتبه کیسوب آلوب اوزی آشادی، بوندن صوڭ کیسوب ایلچی اولان سوسن گه ویردی. وهر کیم گه برر برر کیسوب ویردی. پادشاه طرفندن لقمه ویرلگان بر کشی گه کچکنه مائده کتوروب طوررلر ایدی. پادشاه طرفندن لقمه ویرلمای طوروب هیچ کیم طعام گه قول صوزمادی، رسملری شویله ایمش. هر کیم اوز مائده سندن اوزی گنه آشادی، آرتوب قالغان نعمتلرنی اورنلرمزغه آلوب قایتدق. آش تمام اولدیغی صوڭ پادشاه ایچارگه صورادی. سچو دیدیکلری ایچملکنی کتوردیلر. (قمز یاکه آیران اولسه کرك).

بز کلمازدن مقدم خطبه‌ده «اللهم اصلح الملك بیلکوار ملك بلغار» دیه دعا ایته‌لر ایکان. بز: «ملك دیه الله تعالا گه گنه آیتولنه در، بویله سوزنی خصوصا منبردن طوروب غیرلرگه آیتورگه یارامی، سنڭ مولاڭ امیر المؤمنین خطبه‌ده: اللهم اصلح عبدك وخلیفتك جعفر الامام المقتدر بالله امیر المؤمنین دیه اوقومق حقنده مشرق ومغرب گه امر تاراندی!» دیدم. خان: «اویله ایسه نیچوك دعا قیلورغه یارار؟» دیدی. بن اوز اسمك وآناڭ اسمینی آیتوب دعا قیلورلر» دیدم. پادشاه: «بنم آتام کافر ایدی، کافر وقتنده قوشلغان اوز اسممنڭ‌ده آیتولنوینی ایسته مم، مولام امیر المؤمنین اسمی نیچوك؟ وآنڭ اسمی ایله اوزمنی آتاسام یارارمی؟» دیدی. بن: امیر المؤمنین اسمی جعفردر، شول اسمنی اوزگه ویرسه‌ڭ یاریدر» دیدم. پادشاه. «اویله ایسه بنم اسمم جعفر وآتام اسمی عبد الله اولسون!» دیدی. بوندن صوڭ خطبه‌ده: «اللهم اصلح عبدك جعفر بن عبد الله امیر بلغار مولی امیر المؤمنین» دیه دعا قیلنور بولدی.

ابن فضلان سوزلرندن بو وقتده بلغار مملکتنده بو کونکی گرمانیه روشنده کوب پادشاهلقلر اولوب، جمله‌سینڭ اوستونده بلغار پادشاهی اولدیغی هم ده خیلی مدنیتلی وتربیه‌لی بر قوم اولدقلری آڭلاشلور. جعفرنڭ یاشی وقیافتی، خاتونلری وبالالری حقنده‌ده احتمال که ابن فضلان بر قدر معلومات ویرمشدر، فقط اصل سیاحت نامه الده بولنمادیغی سببلی بو طوغروده حبر آلورغه منبع یوقدر.

جعفرنڭ قانغی یلده وفات اولدیغی معلوم اولماسه‌ده مورخلرنڭ استاذلری اولان مسعودی اوزینڭ «مروج الذهب» نام تاریخنده (ج۲ بیت۱۲) هجری ایله ۳۳۲ نچی یلده سلامت ایدیکنی واوغلینڭ‌ده حج گه واروب «بغداد»غه

کلدیکنی خلیفه المقتدر طرفندن مذکور شهزاده‌گه طبل ایله علم ویرلدیکنی بیان ایلامشدر.

اوشبو بیوك حادثه‌که ۱۳۱۰ــ۱۸۹۲نچی یل ۱۲نچی محرم ۲۵نچی ایبولده هجری حساب ایــله بر بیك یــل تمام بولدی. روسلر اوز آرالرینه رسمی صورتده خرستیانلق کردیکینه طوقز یوز یل طولدیغی وقت، بونك یادکاری ایچون زور بایراملر ایتدیلر وبتون ملتلرینك حسلری قوزغالوب، برجان وبر تن اوله‌رق شادلقلر کوستردیلر، ٭ ۋلادیمیرگه دعالر ایتدیلر واسمینه نشانلر قویدیلر. امابزلر جعفر حقنده نه کبی مکافاتده اولندق؟ باشقه قوملرده اولسه ایدی هر بر شهرده جعفر اسمینه تاغلر مثالنده مکتب ومدرسه‌لر بنا ایدرلر ایدی، فقط بزده بویله بر حالنك ازومنی وعلم روح جهتنچه اوله‌جق فائده‌سنی‌ده بیلوچیلر آزدر.

اوشبو سببدن آرامزغه رسمی صورتده اســلام دینی کروب تارالدیغینه بیك یل تمام اولدیغنی بزلر بیلماینچه‌ده قالدق.

کیله‌چکده، بلغار خلقی، وبلغار مملکتی حقنده، وعموما بومملکتده‌گی ایسکی زمان مسلمانلری، حقنده ابن بطوطه سیاحت نامه‌سی وغیرلردن مهم شیلر ترجمه ایدلنوب یازلنه‌چقدر.

## روس ادبیاتی:

وطنداشلرمز اولان روسلرنــك ادبیاتی حاضرنده پك کیك، روس تیلنده یازامش ادبیات و فن کتابلری پك کوبدر. بو تیلده ادبیات، فن و درس کتابلری وجوده کیترمك ایچون باشده‌غی وقتده الك یکُل طریق، ادبیاتی مکمل اولان باشقه تیللردن ترجمه ایتمك اولدیغندن، بزگه ده روس ادبیاتی حقنده فکر و معلومات حاصل ایتمك لازمدر. مثلا: روسچه‌دن اوز تیلمزگه نیندای کتابلر و کیم اثرلرینی ترجمه ایتمك فائده‌لی واول محررلرنك مسلکلری نه‌دن عبارت اولدیغنی بیلمك ایچون هیچ اولمازسه روس محررلرینك الك مشهورلرینی طانیمق، اثرلری و مسلکلری حقنده معلومات صاحبی اوله‌ق لازمدر.

بو خصوصده مجموعه مزده، اولدقچه نصقه، لکن ترتیبلی بر روشده معلومات بیره بارر ایچون مستشرقهٔ فاضله گلنار خانم نك «روس ادبیاتی» اسملی رساله‌سنی رهبر طوتونی موافق کوردك. بناءعلیه مجموعه مزنی ترتیب ایله اوقوچیلر روس ادبیاتنده اهمیتلی خدمتلری کوریلوب، اسملری مشهور اولان: قانته میر، لومونوسف، درژاوین، فون ویزین، قارامز

بن، دیمیتریبه‌ف، هراسقوف وپتروف، ژوقوفسکی، باتیوشقوف، قریلوف، پوشکین، غریبویه‌دف، ارمونتوف، قولتسوف، غوغل، غونچاروف، ثورگه‌نییف، استروفسکی، تولستوی، (چه‌خوف، غورکی) کبی محررلر، شاعرلر وادیبلر حقنده، اجمالا اولسه‌ده، بر فکر حاصل ایده جکلردر.

§

مدنیت و ترقی جهتنچه یـڭی روسیه‌نی اسکیسندن قطعی صورتده آیرغان زمـان، بیوك پترنك حکومتی (۱۶۸۹ــ۱۷۲۴) زمانیدر. روس مـدنیتی‌نك تاریخنده بو زمان «دور جدید اصلاحات» دیب آتـالمقده‌در. فقط هر نه قدر تدریجی اولسه‌ده بو اصلاحات دورینك مقدمه‌لری اولدن حاضرلنوب کلمکده ایدی. روسیه اوچنچی «ایـوان» زماننده غربی یاوروپاغه یقینلاشورغـه باشـلادی. دوردنجی «ایوان» نك حکومتی زماننك (۱۵۶۴) کتابلر باصلورغه باشلاندی. دوردنجی «ایوان» نك و باخصوص «بوریس غودونوف» نـك سراینده بر چوق انکلیز، فرانسوز و نیمسلر وار ایـدی. ایلچیلر، طبیبلر و سائر هنر اربابی مسکاوده حکمدارنـك حمایـه سینه نائل بولالر ایدی. تسار «میخایل» نک حکومتی وقتنده چیتدن کیلـگان هنر و صنعت ایه‌لری هم اشچیلرنک عددلری دخیده آرتدی.

تسار «آلـکسی» زماننده یالڭز کتابلر باصوغه دوام اینوگنه دگل، حتی «نیقون» اسملی بر پاپاس کلیسا کتابلرینی توزه‌تورگه باشلادی. مسکاوده تورلی اجنبی اشـچیلری هم اهل صنعت وفن هندسه اربابندن مرکب اوز آلدینه بر محله یاصالمشدر. تسار بالذات اوزی یڭی چغارلغان نرسه‌لرنی آلغه یباروب، مدنیت طاراتور ایچون «کییف» شهرندن برنیچه عالم راهبلرنی مسکاوگه آلدرتدی. یاوروپاغـه امتثالا عسکرگه، حکومت اداره‌سینه، صنعتلرگه و تجارتکه دائر یڭی نظاملر قویوب، طاش باصمه ایله برنجی مرتبه غزته چغارورغه اذن ویردی. بوندن باشقه «قریژانیچ» اسملی بر مؤلفنك تقدیم ایتمش اولدیغی «پولیتیقه» اسملی اثرینی حسن قبول ایدوب، بو صنعت و بصیرت صاحبی مؤلفنك نصیحتلرندن فائده‌لنرگه باشلادی.

۱۶۶۴نجیییلده تسار آلـکسی کییف‌دن «سیمیون پولوتسکی» نامنك بر راهبنی آلدروب اوغلی تسار «فیودر» نـك تربیه‌سنی شوکارغه طاپشردی. اول وقتغه قـدر بوندای حالنك هیچ ایشتلگانی یوق ایدی.

---

(بو «سیمیون پولوتسکی» حقنك کله‌جك نومرده یازیله‌جقدر.)

« قلم »

# حج حقنده معلومات

(فتح الباری، فتح القدیر، العقد الفرید، دائرة المعارف، قاموس الاعلام، ابن خلدون، صفوة الاعتبار و باشقه معتبر اثرلردن، رسالهٔ موقوته و مجموعه‌لردن مقتبس.)

اوشبو کچمش کونلر، اهل اسلام قاشنده‌اڭ محترم اولان حج کونلری ایدی. دنیانڭ هر طرفندن واڭ یراق اولان چیتلرندن یوزلر و بیڭلر ایله مسلمانلر، یورت یرلرینی، کسب و کارلرینی قویوب اسلامیت بیشگی اولان مکهٔ مکرمه‌گه کلوب حج عمللرینی ادا ایتدیلر. اوشبو جهتدن بزلر بو یرده حج عملینڭ اصلی و تاریخی هم ده روشی حقنده بر قدر معلومات ویرورگه لزوم کوردك.

اوز قاشلرنده معتبر اولان آدملرنڭ قبرلرینه، یا که حرمتلو اولان بنالرغه یوروب زیارت ایتمك بیك بورنغی و ایسکی قوملردن قالمش بر عادتدر. ایسکی مصریلر، آثوریلر، فارسیلر، فینیکه‌لولر، یونانلولر، روماللولر، هندیلر، یهود و نصارالرنڭ اوزلرینه کوره حجلری بولنور ایدی. فقط بونلرنڭ حجلری و روشلری ایله آشنا اولورغه بزم ایچون لزوم یوقدر. اوشبو سببدن بو یرده آنچق اسلاملر قاشنده محترم اولان حج مراسمی حقنده یازلنه چقدر. اهل اسلامنڭ حجلری مکه شهرنده و آنده اولان اورنلرغه مخصوص اولدیغندن شونلر حقنده تفصیلات ویرله‌در.

## مکه

مکه، حجاز مملکتنده و شاب دیڭزی یاقاسنده اولان «جده» شهرندن ۹۵ چاقرم مشرقده مشهور بر شهردر. کعبهٔ شریفنی حاوی اولمغله اسلامنڭ بیشگی و بتون اهل اسلامنڭ مرکزی حساب ایدلنور. تون و مشرق طرفلرنده «أبو قبیس» و توشلك هم مغرب طرفلرنده «قعیقعان» تاغلری اوراب آلدیغندن جوانبی قورو و طاشلق ایسه‌ده تجارتی واسعدر، هر دائم اهالیسی ۸۰،۰۰۰ مقدارنده حساب ایدلنور.

شهر، توندن توشلك طرفینه صوزلمش بر چوقرده بنا ایدلنوب بویی ۳ و ایڭی بر چاقرم مقدارنده، بنالری ده طاشدن اوچ و دورت قاتلیدرلر. صفا ایله مروه توبه‌لری، مسجد حرامنڭ ایکی جهتنده اولوب، آرالرنده مکهٔ مکرمه‌نڭ، ایکی طرفنده کیبتلر واڭ کیڭ اولان اورامی اوزانور.

مسجد حرامدن باشقه مکهٔ مکرمه‌ده ٦ مناره‌لی جامع شریف ایله ٦٧ مسجد، ٦ مدرسه، ۲ کتبخانه، بر رشدیه و ٤۳ ابتدائی مکتبلر، ۲ مونچه، ۲۵ مغازه، ۳،۰۰۰ کیبت، ۱ غربا خسته خانه‌سی و غیرلر واردر. صوکغی وقتلرده شهرنڭ طشنده حاجیلره مخصوص اولمق اوزره مسافر خانه‌لر بنا اولنمشدر.

صو قحطلغی اولدیغی سببدن هارون الرشید خاتونی زبیده طرفندن اوچ کونلك یردن «عین زبیده» اسمنده بر چیشمه کتورلمشیدی. فقط چیشمه‌نی کتورمك، زبیده‌نڭ وفاتی وقتنه تصادف ایتدیکی سببدن «عین زبیده» آنچق عرفانه

قدر کلوب، آندن بوطرفه چیقمامشیدی. صوڭره دن قانونی سلطان سلیمان قزی اولان مهروماه سلطان (*) مذکور چیشمه‌نی عرفاتدن مکه‌یه کتورتدی. ۱۳۲٤ تاریخنده اهل اسلامدن جیولمش اعانت ایله، بوزولمش اولان یرلری تکرار تعمیر اولندی.

مکهٔ مکرمه نڭ جوانبنی بیوك تاغلر احاطه ایدوب، یالڭز اوشبو تاغلرنڭ آرالری اور ایله محکم ایدلنمش واوچ قپو آچلمش ایدی. شمدی اور بتمش ایسه‌ده قپولرنڭ اسملری همیشه باقیدر. «شعب بنوهاشم» اسملی اورن فخر الانبیا افندمزنڭ بنوهاشم ایله برلکده محصور صورتنده طوردیغی، «زقاق الحجر» ده حضرت خدیجه اوننده عمر کچردیکی وبونڭ قارشوسنده حضرت ابوبکر خانه‌سی اورنلری معلوم اولوب، اهل اسلام زیارت ایلرلر. «جنت المعلا» نام مزارستاننده ام المؤمنین حضرت خدیجه ایله پیغمبرمزنڭ والدهٔ محترمه‌لری حضرت آمنه قبرلری بولنور.

مکه‌نڭ هواسی جایلکده اسسی ایسه‌ده قوری اولدیغندن ضررسزدر وقش کوننده معتدل وملایمدر. آوغوست آیلرنده حرارت ۳۹ درجه‌لر و ینوارلرده ۱۸ درجه‌لر اولور. مکه، قرآن شریفده براورنده «مکه» وایکنچی براورنده «بکه» دیه تعبیر ایدلمشدر. ام القری، وادی القری، البلد الامین، البلد الحرام، البطحا وغیرلر بوشهرنڭ لقبلرندن اولور.

مکه، پك ایسکی بر شهر اولوب، نه وقت وکیملر طرفندن بنا اولندیغی حقنده تاریخده معلومات یوقدر. فخر کائنات افندمز اوشبو شهرده دنیایه کلوب قرق یاشلرنده رسالت ایله مشرف اولمش واون اوچ ییل صوڭنده «مدینه» گه هجرت ایلمشدر. بوکونده اوشبو شهر ترکیا دولتی تصرفنده اولوب، حجاز ولایتینڭ مرکزیدر.

## کعبه

مکه شهرینڭ اورتاسنده «مسجد حرام» ومسجد حرام اورتاسنده‌ده «کعبهٔ شریف» (بیت الله الحرام) بولنور. حضرت ابراهیم، حضرت هاجر ایله اوغلی اسماعیلنی مکه‌گه کتوروب قویدیغی صوڭ حق سبحانه وتعالانڭ امریله کعبهٔ شریفنی بنا ایتمشیدی. شول وقتدن بیرو کعبه، مؤمنلرنڭ زیارتگاهلری اولمشدر. حق دین اونودلوب، عربلر کعبه‌نڭ ایچینه پوتلر قویوب پوتخانه روشنه قویمشلر ایسه‌ده حج عمللرینڭ کوبلری اولکی حالنده قالمشیدی.

ایلك وقتلرده کعبه‌نڭ اوستی آچیق اولوب، اڭ الك حمیر پادشاهلرندن «تبع» نام کیمسه بونڭ اوستنی اورتمشدر. کعبه‌نڭ محافظه‌سی قریش قبیله‌سی النده اولوب، التجا ایدنلر ایچون امینلك اورنی اولنور ایدی. ابرهة الاشرم، «صنعا» شهرنده بیوك ومزین بر عبادتخانه بنا ایدوب، حج ایتمك ایچون عربلرنی شونده دعوت ایلمش ایسه‌ده کیمسه اجابت ایتمدی وکعبه‌دن یوز دوندرمادیلر، بوندن ایسه مذکور پادشاه آچیغلانوب، کعبه‌نی

(*) مشهور خاتونلر، ۹۷۳ نچی بیت.

خراب ایتمك قصدیله عسكر وفیللرنی برابر آلوب مكه‌گه كلدی. قریشلر اوزلرینك قارشو طوره آلمیه چقلرینی بیلدیكلرندن تاغلرغه قاچدیلر. فیل سوره‌سنده اشارت ایدلدیكی اوزره جناب الله بونگ عسكرینه عذاب قوشلری ییباروب هلاك ایتدی. (بو كونكی عالملر بو قوشلردن مراد وبامیقر وبی‌ایدی، قرآن شریف میقر وبدن قوش ایله كنایه ایلمش اولسه كرك دیورلر). بوندن صوك فخر الانبیاء افندمز ۳۵ یاشلرنده ایكان وقتده كوچلی بر سیل كلوب كعبه‌نی تخریب ایلدی. جده شهرنده قوری‌غه اوطورمش بیوك بر كیمه‌نك آغاچلرینی مكه‌گه تاشوب عربلر كعبه‌نی تكرار بنا ایتدیلر وبوندن صوك تكرار سیل ضرر ویرماسون واوچراغان بر كشی ایچینه كره آلماسون ایچون قپوسنی بیوك ایدوب توزودیلر، بایلقلری یتشمادیكی سببلی‌تون طرفنك اولان حجر وحطیم اسملی اورننی كعبه‌نك طشنك قالدردیلر. ایشته رسول اكرم زماننده كعبه اوشبو حالنده ایدی. هجرتدن ۱۰ نچی ییلده رسول اكرم مكه‌نی فتح ایتدی واهالیسی عموما اسلامه كردیلر وشول كونده كعبه ایچنده اولان صنم وپوتلردن تطهیر اولندی. عبدالله بن زبیر اوزینگ خلیفه‌لگی وقتنده حضرت عائشه طرفندن فخر الانبیا افندمزدن روایت ایله: «عمرم اولسه كعبه‌نك قپوسنی یردن ایدوب، حجر (حطیم)نی ایچكه كرگزوب بنا ایلر ایدم» مضموننك اولان حدیث شریفنی ایشتدیكندن رسول اكرم مرادینی برینه كتورمك ایچون كعبه‌نی یگیدن تعمیر ایتدی. ویردن اوله‌رق ایكی قپو آچدی.

امویلر اسمندن عسكر ایله كلوب حجاج بن یوسف مكه‌نی محاصره ایتدیكی وقت حجاج منجنیق ایله كعبهٔ شریف اوزرینه آتدروب كوب یرلرینی یمردی ومكه ایچینه كروب، عبدالله بن زبیرنی اوتردیكی صوك كعبه‌نی تكرار عربلر بناسی شكلنده بنا ایتدردی ومغرب طرفنده اولان قپوسنی پایدردی. كعبه‌نگ بو كونگی روشی حجاج طرفندن ودورتنچی مرتبه اوله‌رق ایدلمش بنادر.

كعبهٔ شریف تقریبا مربع صورتده بر بنا اولوب بویی ۲۴ آرشین ایگی ۲۳ آرشین وبرقارش؛ بیوكلكیده ۲۷ آرشیندر. دورت جهت كه كعبهٔ شریفنگ دیوارلرندن زیاده ركن (پوچماق) لری قارشو طورر. اوشبونگ ایچون قپو اولان دیواری مشرق ایله شمال طرفنده، اوك طرفده اولان دیواری شمال ایله مغرب جانبنده در.

كعبهٔ شریفنگ ركنلری (پوچماقلری) نگ اسملری واردر.

مثلا قپوغه قارشو طوروچینگ اوك طرفنده اولان ركنی شامی، عراقی، ركن حجر اسماعیل دیه وصوك طرفده اولان ركنی ده حجر اسود ركنی دیه، ركن شامی یاننده اولان ركن «ركن غربی» وحجر اسود ركنی طرفنده اولان ركن ده «ركن یمنی» دیه آتالمشدر. نمازلرنده روسیه‌لیلر كعبه نگ «ركن غربی» سینه قارشو اولورلر. بناسی یونمغان كوك توسده اولان الوغ تاشلردندر. كعبهٔ شریفنگ قپوسی مشرق طرفندن اولان دیوارده ویردن آیاقده طورمش آدمنگ باشی طوغروسنده

اوچ آرشندر. بوساغاسى كموش وايكى ياڭاغى كموش ايله قاپلانوب آلتنلانمش ساج آغاچيدر. بونى كموش ايله ۹۵۹ تاريخنده سلطان سليمان قانونى قاپلاتمشدى. قپونڭ اوزينه مخصوص غايت زينتلى وقيمتلى پردەسى اولوب مصردن اشلانوب يبارلور. قپودن كرر ايچون آلتون ايله بويالمش آغاج باسقچى واردر. ايچينه كروچيلر اوشبو باسقچ ايله بنوب كررلر. كعبهٔ شريفنڭ ايچنده شمال طرفندن جنوبكه قاراتوب برصفده تزلمش اوچ باغانه واردر. توبەسنده خليفه لر طرفندن يبارلمش قيمتلى هديەلر آصلمشدر. كعبه نڭ ايچ طرفى اوستينه، آق يفاك ايله «الله جل جلاله» يازلمش قزل آطلس پرده ايله اورتلمشدر. بونى ايسه سلطان عبدالعزيز هديه ايتمشدر. ايشكدن كرگاچ اوڭ طرفده كعبەنڭ اوستينه چيغا طورغان باسقچ اولوب بونى «باب توبه» ديورلر. توبەسنى مرمرتاشى ايله اورتلوب كولمك آسوب قويار ايچون هرطرفينه آلقه لرقويلمشدر.

(صوڭى وار)

## تلسزلرنك سويلاشولرى

ايلك زمانلرده تيلسـزلرنك سويلاشـه بيلولرينى، يازو اوقورغه قدرتلرى يتونى ممكن دگل حساب ايلرلر ايدى. فقط كوب تجربه واوزون اجتهادلر ايله بو كونده معلوم اولدى كه بونلر ايچون علم تحصيـل ايتمك، اوقورغه ويازارغه اوگرنمك ويازو واسطەسيله سويلاشه بيلمك ممكندر.

خلقلر اوستونده آغر يوك اولوب يورمكده اولان تيلسزلر شمدى مدنيت دنياسينه وخلق آراسـينه كرديلر، خطلر يازشوب طوررلر، مقصودلرنى آڭلاتو وآڭلاوده مشقت چكمازلر، اوز آرالرنده جمعيتلر تأسيس ايتديلر، تجارت خانەلر وباشقه يرلرده يازو خدمتنده بولنورلر. خلاصه: باشقه خلقلر ايله برابر تربيه كسب ايتەكدەدرلر. تيلسـزلك اصل صاڭغراولق سببندن اولور. بالالرنڭ تيل اوگرنمكلرى كشى گه ايارمك سببندن اولديغندن، صاڭغراو بالالر باشقەلرنڭ سوزلرينى ايشوتە آلمازلر واوشـبونڭ ايچون باشـقەلرغه ايارە آلماى سويلاشه بيلمى قالورلر. تيلسزلك اوشبوندن باشقه دگلدر.

تيلسزلـكنڭ بر قاچ سببلرى اولسه ده الڭ بيلـكوليسى ياقين قارداشـلر ايله اولغان نكاحلردر. آنكليه دەبوخصوصده بر تجربه اولوب هر ايـكييوز تيلسزدن آتا وآنالرينڭ ياقينلقلرى واوزلرينڭ صانلرى اوشبو روشده كورلدى:

| آتا وآنا | تيلسزلر صانى |
| --- | --- |
| اوزلرى بر طوغمه بالالرى | ۸۵ |
| آتالرى برطوغمه بالالرى | ۶۳ |
| بابالرى بر طوغمه بالالرى | ۳۲ |

آتا یا که آنالرینك بابالری بر طوغمه بالالری ۷
بوندن یراقلر ۱۳
۲۰۰

یاقین قارنداشلر آراسنده اولان نکاحلرنك ضرری بالالرنك تیلسزلکلری گنه دگل، بلکه عموما نسل ایچون ضررلیدر. بالالر خسته وضعیف اوله‌لر. بوطوغروده آمریقاده ۸۳۳ عدد نکاح طوغروسنده بر تجربه وحساب یورتلدی. اوشبو نکاحلردن بولغان ۳,۹۴۲ دانه بالادن ۲,۸۰۸ دانه‌سی سلامت بولوب باشقه‌لری تیلسزلك، صوقرلق، جنونلك وباشقه خسته‌لکلر ایله مبتلا اولمشلردر.

هر نه ایسه اوشبو کونده، تیلسزلرنی اوقوتمق نظامی دنیاغه تارالدی وهر یرده بونلر ایچون درسخانه‌لر آچلدی.

تیلسزلرنی اوقوتور ایچون ایکی تورلی اصول اولوب، بری قول اشارتی، ایکنچسی‌ده حرف آڭلاتمقدر. آنگلیه، آمریقاده اولگی اصول؛ گرمانیا وباشقه‌لرده صوڭغی اصول معتبردر. اشارت ایله کوڭلگه کلگان شیلرنك جمله‌سینی بیلدرمك ممکن اوله‌در. ۱۹۰۲ نچیییلده یورتلمش بر حسابغه کوره بتون یر یوزنده اولان تیلسزلر مکتبی ۴۲۹ عدد اولمشدر. کچن ییللرده مصرده تیلسزلر مکتبی آچلوب، عربی وانگلیز لسانلرینی اوقورغه وبازارغه اوگره‌ته باشلامشلردر.

## احمد بای وقفی

بر آز غنه انصافی بولغان هیچ بر کشی انکار ایده‌مزکه صوڭ زمانلرده، قافقاسیادن غیری بوتون روسیه‌ده مسلمانلر آراسنده، آقچه‌سی برلن مسلمانلرغه اڭ زور، اڭ فائده‌لی، اڭ چن خدمت تیکدیرگان کشی مرحوم احمد بای حسینوفدر. معرفت ومدنیتلی وبناء علیه قدر بیلوچی ملتلر بونداین الوغ همتلی ملت آتالرینك طوغدیغی کوننك اللنجی ویوزنجی ییللرنده بایرام ایده‌لر، اولدیکی کوننك سنه دوریه‌لرنده عمومی دعالر قیلالر، قبرلرینه تربه‌لر یاصایلر، اول طورغان شهرلرگه نشان طاشلری قویالر. حاضرده بزنك ملت، ملت کوینچه اوزینه ایتلکان خدمتلرنی آڭلارلق اوسوب یتمه‌مش ایسه‌ده، یگرمی اوتوز ییلدن شاید سن رشده ایرشوب، بو خدمتلرنی تقدیر ایدر واحمد بای‌نك یوزنجی سنهٔ دوریهٔ ولادتنی لایق اولدیغی درجه‌ده قوطلار.

بر یاقدن خیر صاحبلرینی قدرلمك لازم اولدیغی کبی ایکنجی یاقدن‌ده آنلرنك باشلاغان زور ایشلرینی اتمام ایتمك الزمدر. مرحوم مکمل بر مدرسه ایله بای بر وقف قالدیردی. لکن اوشبو وقفنك قانونی (یوریدیچسکی) حالی هنوز تعین ایتمه مشدر. وقفنك قانونلشه آلماسنه یالگز متولیلر دکل، بوتون ملت افرادی

قولندن کیلگان خدمتنی دریغ ایتمزگه مجبوردر؛ زیرا بونلردن ایدیلهجك فائده بوتون ملتکه شاملدر.

بنم بو وقف ایشی ایله اوچ دورت ییلدنبرلی بلیشلگم وار. اولزمانلر دوق، مکالمه ومذاکره لریمزده، واقفنك «مدرسهء حسینیه» یی معارف نظارتی قولنده قالدیرماینچه، اورنبورغ ادارهء روحانیهسنه یعنی داخلیه نظارتنه ویرمك ایستهمهسی، وقف نك قانونلشمهسنی مشکللندیرهجگی کوریله ایدی.

احمد بای نك وفاتندن صوگره قرنداشی محمود بای اوز طرفندن زور همت کورستوب، باشقه دوشاپریقازچیقلر ایله برابر، ایشنگ تیزدن فعلیتکه چقووی ایچون چندن طریشرغه طوتندی، وبو خصوصده قزاننگ یخشی دعوی وکیللرندن (آدواقاتلرندن) ب. افندینی یاللادی. ب. افندی ایله دوشاپریقازچیقلرنگ مجالسهلرنده دخی مسئلهنك چیتن جهتی وقف موءسسهسنه معین بر شکل قانونی وبر مکتده ومدرسهنی معارف نظارتندن چقارمقده اولدیغی کوریله ایدی. اگر مسلمانلر طرفندن کوبدن بیرلی ایستهنیلان ادارهء روحانیه نظارتنه طابشریلمهسی مطلبی حاصل بولسه، ایکنجی مسئله یگیللهنهجك، لکن بونی خیلی زمان کوترگهگه طوغری کیله ایدی.

رضاءالدین وخیرالله حضرتلرنك، بوکونلرده «وقت» صحیفهلرنده باصیلغان «بیان حال» لرندن آگلاشیلهدر کیم: احمد بای وقفی ایشی ایله پتربورغه بارغان ذاتلرنك معارف ماءمورلری برلن سویلشولرنده دخی مکامله شول ایکی مسئلهنی جامع بولغان بر سؤالگه بهریلوب طوقتهمشدر: — مؤسسهگه نیندایین بر طریق ایله، نیندایین بر شکل قانونی بیریلورگه تیوش؟ یعنی آیروجه بر قانون لایحهسی صورتنده مینیستر مجلسندن، دومادن، صاویتدن اوزدیریلوب پادشاهنك تصدیقنه عرض قیلنوب، واقفنك آرزوسی اوزره، اوز آلدینه مستقل (آفطونوم) بر مؤسسه یاصارغهمی؟ یاکه عمومی قانونغه بنچه کیدیلوب دیگر مدرسهلر شکللی معارف نظارتی قولنده بر مدرسه ایله داخلیه نظارتنه تابع بر مؤسسهء خیریهگنه یاصارغهمی؟

وکیللر واقفنك ارادهسنه خلاف گیلماز ایچون، بلکه باشقه سببلرنیك اویلاب ایکنچیسنه راضی بولماغانلر؛ راضی بولماولری، ظنمچه، غایت معقولدر. اکر عمومی قانون بوینچه حرکت ایدیلسه بوزور ایشنك فائدهلرندن کوبیسی یوغالوب، فقط موجود اسلام جمعیت خیریهلرینه بر جمعیت دها، موجود اسلام مدرسهلرینه یر مدرسه دها علاوه قیلنمش غنه بولوب قالیر ایدی.

علم وخیر ایشلرینی قاری طورغان مستقل (آفطونوم) واوز آلدینه بر قانون ایله متشکل موءسسهلرنك روسیهده موجود اولوب اولمادیغنی بیلمیور ایسهمده، اوروپاده وارلغی معلومدر. اوورپا مدارس عالیهسینك همان جملهسی خصوصی «برات» لر ایله مستقل اولهرق

توره‌مشـلردر؛ بونلرنڭ کوبیسی طریقتلر (اوردنلر) طرفندن یاصالغانغه علم ایله برابر خیر وشفقت طاراتونی‌ده اوستلرینه آلالر ایدی.

بو کونلرده ، روسیه‌ده دخی خصوصی وشخصی معاونت سایه‌سنده بر عالی مدرسه مستقل اوله‌رق، او زینه مخصوص بر قانون ایله وجودکه چیقمق اوزره‌در : اوزغان ییل آ . ل . شانیافسکی (А. Л. Шанявскій) اسمنده بر پالقوونیك موسقواده عوام ایچون بر دارالفنون یاصارغه زور آقچـه ایله بر بناوقف ایتمش ایدی. بو مدرسهٔ عالیه‌نك اداره‌سی طوغریسـنده واقف شانیافسکی ، بزنك احمد بای وقفی نظامه‌سـنه (اوستافنه) غایت اوخشاشلی برنظامنامه‌توزدیردی. موسقوا مدرسهٔ عالیه‌سینی‌ده، «مدرسهٔ حسینیه» کبی « متولیلر مجلسی » ( پوپیچیتلنی صاویت ) اداره ایله جکدر .(۱) اوشبو نظامنامه‌مینستررلر مجلسنده قارالوب ، ایکنجی دیکابرده ، معارف ناظری طرفندن ، دوماغه لایحهٔ قانونیه حالنده کیرتلدی. دوما معارف قامیسیه‌سنه طابشروب، مذکور قامیسیه سکزنجی دیکابرده قبول ایتدی . تیزدن دومانك عمومی مجلسنه عرض ایدیله‌جکدر .

بو واقعه احمد بای وقفی ایچون غـایت قیمتلی بر مثال (پره‌سیدنت) در. متولیلر، دوشا پریقازچیقلر ووکیللر بو امثال گه دقت ایدب شانیافسکی وقفی ایشنی کرکلی اورنلرندن بیك یخشی تیکشروب ، انشـاء الله تیزدن روسیه مسلمانلربنی تماما قانونلشـکان مستقـل وعالی بر اسـلام مدرسه سی « مدرسهٔ حسینیه » ایله شادلاندررلر .

ی . آ.

(۱) بو طوغریده تفصیلا معلومات آلمق ایسته‌ین ذاتلر ۲ نجی دیکابر تاریخلی پتربورغ، یا که ٤ نجی دیکابر تاریخلی موسقوا غزته‌لرینه کوز صالسینلر.

## روسیه مسلمانلرنده

### مکتب، معارف، وادبیات.

ملتمزنڭ بتون حیات واستقبالی اوشبواوچ نرسه‌گه باغلانمش اولدیغندن ، بو مسئله‌لرگـه «شورا» ده البته اهمیتلی اورن ویربله‌جکدر .

حاضرگه بو خصوصلرده، شرق ومسلمانلق دنیاسی حقنده فکر یورتـوب بعض بر اثرلر یازوچی، پروفیسور« قریمسکی » نڭ بعض برفکرلرینی درج ایده جگز . صڭره تدریجا مکتب ، معارف وادبیاتمزنك حاضرگی احوالی حقنده اوز طرفمزدن معلومات ویریلوب ، اوز نقطهٔ نظرمز بیان اولنه جقدر .

پروفیسور «قریمسکی» اوزینڭ بر مقاله سنده دییور :

۱۷ میلیون قدر خلقدن عبارت اولان روسیه مسلمانلرینڭ یالڭز ۳ میلیون قدریسی خالص قفقاز نسلندن اولوب قالغان ۱٤ میلیونی یعنی بتون روسیه مسلمانلرینڭ آلتی‌دن بش الوشی اول قدر قابلیتلی ومستعد بولماغان ترك

تاتارلردر . بوصوڭغیلرنڭ الڭ کوبسی خالص قانلی ترك ـ تاتار اولوب، فقط بعض یرلرده گنه باشقه جنسلر ایله ،مثلا :ترکستان وقفقازده غی ترك ـ تاتارلر ایران جنسی وقریمده گیلری مالاروس ، ایتالیان وروم خلقلری ایله قاتنا شمشلردر . (بو اورنده‌غی قاتناشودن مقصود قان قاتناشوویدر . )

روسیه‌ده گی مسلمانلرنڭ روسیه قول آستینه توشولری وبناءً علیـه آنڭ مدنیتـی تأثیرنده یاشارغه باشلاولریده‌بارسیده بروقتده دکل ، بلکه تورلیسی تورلی زمانده در.

مثلا : قازان ، آستراخان ، آلتون اوردا وسبر خانلقلرندن قالوب ، بوکونگی کونده ژولغا هم آنڭ شمال شرقی طارماقلری بوینده وسبریاده یاشی طورغان ترك ـ تاتارلرنڭ روسیه قول آستینه توشولرینـه کوبدندر . اورال واورنبورغ اطرافنده‌گی‌ترك ـ تاتارلر واستیپلرده گی کوچبه خلقلر روسیـه قول آستینه بایتاق صوڭ توشدیلر . قریم‌تاتارلرینی روسیه حکومتی ١٨ نجی عصرنڭ آخرلرنده ضبط ایتدی. قفقاز خلقلرینڭ بعضیلری بوندن یوز ییل ، بعضیلری ایللی ودها آز ییللر مقدم، ترکستان خلقلری ایسه بوندن ٣٠ ییللر مقدم گنه روسیه قول آستینه توشدیلر.

بو حسابلرغه قاراغانده روسیه قول‌آستینه الڭ آلدن کرگان‌تاتارلرنڭ الڭ کوب‌مدنیتلی،والڭ صوڭندن کرگانلرینڭ الڭ آزمدنیتلی بولولری تیوشلی کبی‌کورینسه‌ده،حقیقتده‌ایش‌بالعکس‌در.

روسیه قول آستنده ٤٠٠ ییلدن بیرلو طوروچی ژولغا بویی هم سبریا تاتارلری مدنیتده الڭ آرتده اولوب ، روسیه قول‌آستینه آنلردن صوڭ کرگان ترکستان ، قفقاز وقسما قریم تاتارلری مدنیتده آلده‌رقدرلر . عجبا بونڭ سببی نه‌در؟

احتمالکه بونڭ سببی : نسل وقانده اولوب خالص ترك ـ تاتار نسلنده قابلیت واستعداد آزراق ، باشقه قانلر ایله قاتناشمش اولانلرنده قابلیت واستعداد کوبره‌کدر . بوندن باشقه ، بوخصوصده روسیه حکومتی‌نڭ اوزینڭده عیبی یوق دگلدر . روسیه قول آستینه ایلك توشکان تاتارلر آنڭ تحت اداره‌سنده کوب طوروسببلی بواشلانوب اطاعتلی‌لندیکلرندن‌و آنلرنڭ حکو- متدن سیاسة آیریلوب هیچ بر یاقفه کیتو احتماللری اولمدیغندن حکومت ودها طوغروسی حکومتنڭ ایش یورتوچی مأمورلری بونلرنی اوقتوب مدنیتکه کرترگه اصلا اهمیت ویرما مشلردر . حالبوکه حکومت طرفندن اونتولغان بو ژولغا وسبریا تاتارلرینڭ ترقی ومدنیتلرینه خدمت ایدر ایچون اوزلرینڭ ضیالی آدملری بولماغان . گرچه بونلر آره‌سنده پك سیره‌ك کنه یتشوب قازان ، اوفا ، سمبر ، قاسیموف کبی شهرلرده یاشی طورغان بعض بر مسلمان ضیا لیلری بولسه‌ده آنلر تماما روسلاشوب اوز ملتلرینڭ آره‌سندن چقغانفه کوره ، بز آنلرنی تاتاردن حسابلاب یوروته آلمی‌مز .

ترکستان وقفقاز مسلمانلری ایسه بتونلای

باشقه بر حالده‌در : بوندەغی عوام خلقی اوزلرینڭ کوبدن توگل بولغان استقلال و حکومتلرینی اونوتمغانلر .

بونلرنك ضیالیلرنده حریت محبتی اوستینه، بایتاقغنه حسیات ملیه‌ده وار. درستنی ایتکانده، بونلرده‌غی حسیات ملیه سیاسی و دینی بر فکردن عبارت اولوب عوام خلقینه حکومتدن آیریلو فکرینی کرترگه تأثیر ایته‌در .

کوبدن توگل ضبط ایدلمش اولان بو مسلمانلرده آیریلو واستقلال فکرینی بترو ایچون حکومت، احتمالکه بردنبر چاره اولمق اوزره، بونلرنی روس روحنده‌گی اشقولاده روس تلی ایله ، اوقتو دیب طابادر. روس روحنده‌گی اشقولا ایله روسیه مسلمانلرینی روسلاشدرمق حقیقة ممکندر. بو طوغری. فقط بونڭ ایچون اشقولانی پك کوب آچارغه ، پروسیه حکومتینڭ اوز قول آستنده‌غی اصلاویانلرغه ایندیگی کبی، مسلمانلرنی اشقولا ایله کوموب قویارغه کرك.

حالبوکه بزده گرچه بر طرفدن ، روسلاشدرو ایچون اشقولانڭ فائده‌سنی آڭلابسه‌لرده، ایکنچی طرفدن، اشقولانی کوبایتورگه قورقالر. حتی روسیه‌نڭ توب خلقی اولان ۋیلیکوروسلرنڭ اوزلری قرون وسطا درجه‌سنده‌گی بر جهالت ووحشتده طوتیله‌در. ظلمت ونادانلق طرفداری اولان بزنك بعض آدملرمز (مأمورلر) «اوقو ایکی یاغیده اوتکون قلچدر» دیه قورقالر. شول سببلی، هر نه قدر روس غزته لری: حکومت چیت ولایتلرده‌گی خلقلرنی، روسیه‌نك اوز خلقندان‌ده آرتغراق اوقوته‌در، دیه شکایت ایتسه‌لرده وآفرایننده‌غی اوقتو ومکتب اشلرینه روسلاشدرو اهمیتی ویرلسه‌ده، بو ایش آفریننده‌غی مسلمانلرنی وخصوصا آنلرنك عوام خلقنی حقیقة روسلاشدررلق بر درجه‌ده قویلغانی یوقدر.

نیچك ونه مقصود ایله اولسه اولسون، مسلمانلرنی مدنیتکه کرتر ایچون روسیه حکومتی طرفندن آزمی کوبمی غیرت ایدلمکده اولوب آفراینده بولغان مسلمانلر ایچون وآزده بولسه آفراینده بولماغانلری ایچونده حکومت اشقولالری آچلمقده‌در .

مسلمانلرنڭ اوزلرینڭ قرون وسطاغه مخصوص نظام وترتیبسز مکتبلری، محلی مأمورلر یاکه حکومت طرفندن آچلغان ابتدائی، اورته وبعضا عالی مکتبلردن طارالمش فن ومعارف جدید ایله چولغانورغه باشلامش اولدیغندن وبو چولغانونڭ مقداری بعض یرده آز وبعض یرده کوب اولدیغندن، حاضرگی حالده روسیه مسلمانلرینڭ معارفی چوبار بر منظره حالنده کوریلمکده در .

روسیه نڭ دارالفنون وعالی مکتبلری مسلمانلر طوره طورغان چیت ولایتلرده بولنمدقلرندن وآنلرده اوقور ایچون یاورو پای روسیه‌گه بارورغه حاجت اولدیغندن دارالفنونلرده اوقوچی مسلمانلر پك آزدر. بتون روسیه‌نك دارالفنون وعالی مکتبلرنده احتمالکه بار کبگی یوزدن آرتق مسلمان استودینتی بولنماز . مسلمانلرنڭ الڭ باشلیجه فن ومعارف آلغان اورنلری

روسلرنك اورته مكتبلريدر. اورته مكتبلر روسيه نك هر طرفنده وار. گرچه روسيه نك اورته مكتبلرنده اوقتو وتربيه اصولی مطلوب درجه‌ده توگل ايسه‌ده بو مكتبلرده مسلمانلر اوزلرينك وطنداشلری اولان روسلردن قالشماينچه، آنلر بيلگاننی بيله‌لر.

معارف مينيسترستواسی طرفندن مسلمانلرغه مخصوص آچيلمش ابتدائی مكتبلرگه كلەچك اولورسه‌ق: بونلرغه مسلمانلر محبت ايتميلر، هم ايتارلكده دگل. چونكه بويله ابتدائی مكتبلرده، درسلرنی بالالرنڭ اوز تللری ايله آڭلاتورغه تيوش ايديكی پك معلوم اولديغی حالده مينيسترسكی اشقولالرده، بلميم نيچوندر اوقتو اصولنی «طبيعی اوقتو» تسميه ايده‌رك، هيچنرسه آڭلاماغان بالالرغه روس تيلی ايله آڭلاتورغه ماتاشقان بولالر. باشداغی وقتده بالالرنڭ اوز تيللرينه ترجمه ايدوب آڭلاته‌رق اوقتو، هم شويله اوقتونی «طبيعی اوقتو اصولی» ديب تسميه ايتارگه تيوش ايكن، ايناروديسلرنی روسلاشدررغه طريشو چيلرمز، اوزلری طوتقان اوشبو يولنڭ فائده سزلگنی كوره طوروب حاضرگه قدر هميشه شولای دوام ايته‌لر. روسلاشدرو مسلكينه خدمت ايدوچيلرمز اوشبو خصوصده اوزلرينڭ قصورلرينی اعتراف ايته‌چك اورنده، مينيسترسكی اشقولالرنڭ مسلمانلر آره‌سنده آلغه كيتماولرينه سبب: مسلمانلرنڭ اوز مكتب ومدرسه‌لرينڭ اوزلری آره‌سنده پك اعتبارده بولنه‌رق، اولگيلرنڭ بو صوڭغيلرغه رقابت ايده آلماولرندندر، ديه عيبنی اوز جيلكه‌لرندن مسلمانلر اوستينه آودارررغه طريشه‌لر.

فن وتجربه بو اصولنڭ يعنی، آناتيلی قاتناشدروب اوقتماونڭ اشكه يارامديغنی وحتی روسلاشدرو مسلكينه خدمت ايدوچيلر ايچونده بونڭ مقصودغه يتكره طورغان بر طريق اولماديغنی بو صوڭ يللرده بالفعل كورساتدی. مونه شونی آڭلی باشلاغانغه كوره تركستانده، سبرنڭ صحرا طرفلرنده وحتی بر درجه‌گه قدر قفقازده آناتيلن قاتناشدروب روسچه اوقتو مسلكی قبول ايتله باشلادی. (بوصوڭ وقتده ۳۱ مارت پراويلاسی چغوب روسيه‌نڭ شرق وجنوب شرقی طرفلرنده‌غی بار اينا روديسلرغه وشونلر جمله‌سندن مسلمانلرغه‌ده اوشبو اصول ايله اشقولالر آچو حكومت طرفندن نظام ايدلدی) قفقاز پاپوچيتل اوقروغنده مسلمانلرغه روسچه اوقتور ايچون نيندای اصول ايله بولووينه كوب اهميت بيرلمی، بلكه نتيجه‌سينه اهميت بيريله، يعنی تلاسه نيندای اصول، ايله اولسه‌ده اوقتلسون لكن مسلمانلر مكتبدن روسچه اوقورغه يازارغه اوگره‌نوب چيقسونلر ديب قارالا. شول قدر واركه: معلملرنڭ، اوقوچی بالالرنڭ تيللرينی بيلولرينه بر درجه اهميت بيريله واينارودیس مكتبلرنده‌گی معلملرگه رهبرلك ايچون بعض بر رساله‌لر حكومتنك اوزی طرفندن نشر اولنه‌در. چونكه روسلاوشدرمسلگينه خدمت ايچون اوشبو يول دخيده فائده‌ليره‌ك طابلمقده‌در.

مملکتنڭ اورته لرنده بولنوبده آیرلو وفوزغالولرندن خوف ایدلمگان مسلمانلرنی یخشی روسچه اوقتور ایچون هیچ براهمیت بیرلمی‌در . شولای بولسه‌ده بومینیسترسکی اشقولالرده‌غی اوقتوترتیبی نڭ کوبکه‌دوامی ممکن توگلدر همده توبان درجه مینیسترسکی اشقولالرنڭ یالڭز روس تیلی اوگره‌ترگه خدمت ایدوب، فن وباشقه هیچ‌برتورلی‌معلومات بیرماوی، اینارودیسلرفاشنده بونلرنڭ اهمیتنی بیگره‌ك کیمته‌در .

ف. ك.

( آخری وار)

## یاپونیاده تعلیم

⟶⋙⋘⟵

یاپونیا اوزینڭ اوزون اویقوسندن کوزینی آچدیغی ایله الڭ آلغه کتمش اولان انکلیز قوملری ایله امریقالولردن عبرت آلورغه وهر ایشینی آنلرغه موافق یورتورگه‌باشلادی. دکیز عسکرینی ترتیب‌که صالدی، قوری عسکرینی توزاتدی ملت مجلسی‌ایله اعیان مجلسی آچدی، هر تورلی نظاملر وریفورمه‌لر ویردی . توبان، اورتا وبیوك‌مدرسه‌لرتأسیس ایدوب اوقونی اجباری ایلادی وبتون خلقلرینه فرنکلر فورمه‌سنده کیوملر کیدردی . بوشی ایسکی عادتمزگه خلاف ویاکه بوشینی قارتلرمز یاراتماز دیه طورمای ملت ایچون نه کبی فائده‌لی بر یول کورلسه شونی هیچ‌ترددسز قبول‌ایتدی .

خلاصه : یاپونیا ایسکی بنانی سیپلاب صالوچی روشنده دگل، بلکه یکی‌بربناصالوچی قبیلندن حرکت ایتدی وبونڭ سببندن باشقه لرنڭ بریبل یورگان‌یوللرینی برآی، بلکه برهفته‌ده یوررگه موفق اولدی. اوشبو سببدندرکه بوندن‌یکرمی بیش ییل مقدم فرنکلرگه تقلید ایدوب یورمکده اولان یاپونیاغه بوکون فرنکلر کندیلری تقلید ایدرگه مجبور اولورلر.

فرنکلر بیك‌کوب‌عادتلرده‌یاپونلرغه‌ایاره‌لر. فرنڭ خاتونلری یاپونیا خاتونلری کبی کیونه وتوزانه‌لر. یاپونلرغه تقلید ایتمك شویله معتبر اولدی‌که حتی تعلیم طوغروسنده ده آنلرغه ایاررگه باشلادیلر .

تعلیم، مکتب ومدرسه لر طوغروسنده الڭ‌معتبر اولان نظام، یاپونلر نظامیدر. یاپونلر مرتبه سنده مکتب وشاگردلر احوالنه دقت‌ایدن مملکت هیچ یوقدر.

یاپونیاده هر قریه‌ده الڭ مکمل صورتده ابتدائی مکتب وحاجت یرلرده اورته مکتبلر، بیوك شهرلرده جامعه ودارالفنونلر اولنور.

٦ یاشنی تمام ایتدیکی صوڭ بالالرنی عموما مکتبلرگه یبارمك لازمدر . ایروقز بالالر اوشبو یاشلرنده‌ابتدائی‌مکتبلرگه‌یوررلر، بومکتبلر ابتدائی‌مکتبلرنڭ برنچی قسملری اعتبار ایدلنور. برنچی‌قسمنی‌تمام ایتکان بالالر ابتدائی مکتبلرنڭ عالی‌اولان قسمینه کررلر. بونده ایسه ۱۰ یاشدن ۱۳یاش قدر اوقورلر. بوندن چیقمش شاگردلر اورتا مکتبلرکه‌کروب بیش ییل اوقورلر. بوقدن

صوڭ عـالیه ده اوچ ییل وآنی تمام ایـدوچیلر دخی اوچ ییل جامعه‌ده تحصیل ایلرلر.

ابتدائی مکتبلرنـڭ بـرنچی قسمی مجبوری اولـوب، آنـدن صوڭـلری ایسه اختیاریدر. فقط هرمدرسه گه مسابقه (یارشو) امتحانی ایله کرمك لازم اوله‌در.

یاپون مکتبلرنڭ درسلر قسقه‌در. ابتدائی مکتبلرده اولان بالالر ایرته ۹دن باشلاب اویله دن صوڭ ۲ ده، باشقه مکتب شاگردلری ۳ ده تمام ایدرلر. اوشبو مدتنڭ دورتدن بری اوین اوینار وکوڭل آچار ایچون تعیین ایدلمشدر. یکشنبه بتون کون، شنبه اویله‌دن صوڭ درس اوقولماز.

۱۹۰۵ نچی ییـل آلنمش مسابقه کوره: ٦ یاش ایله ۱٤ یاش آراسنده اولغان شاگردلر نڭ صانلری یدی میلیون یاروم ایدی. اما بوکونده سکز طوقز میلیونلر اولور. طوغرو سی بتون یاپونیا نـڭ بیشدن بـری ابتدائی مکتبلرده اوقومقده لردر.

یاپونیا شاگردلری آراسنده بایلق، منصب فلان ایـله آیروملق یوقدر. کنوچی بـالاسی کناز بالاسی ایـله قوخارقـه قزی وزیر قزی یان یانه طوروب اوقورلر.

یاپونیامکتبلرینڭ‌هر برنده‌عسکرلك‌حرکتلری اوگرتلنور، وطن محبتی وبهادرلـق بیتلری یرلانورلر. شاگردلر مکتبلردن عسکر، بهادر ووطن صاقلاوچی آرسلانلر بولوب چیقارلر. اگرده بونلر اوشبو حاللرنده دوام ایدر اولسه لر، دنیاغه مالك اوله‌چقلرنده شبهه یوقدر.

# متنوعه

◆◆ آمریقاده «چیقاغو» شهرنده «جیلاك» اسمنده بر دوقتور، بالالرنڭ آنالرندن طو غان ساعتلرندن باشلاب اوزلرینڭ کرکلرینی بیلدرر قدر سویلاشه آلولری ممکن ایدیکن دعوی ایته‌در. بونڭ سوزینه کوره یدی یاشنده اولان بالالر شـعرلر سویلی وگوزل رومانلر یازا آلاچقلر، رسملر توشره بیله‌چکلر حتی بو کونکی دار الفنونلرده تحصیل ایدوب چیقمش کیمسه‌لردن آرتق علملر تحصیل ایده چکلر، زور بنالر وکوپرلر صالدررغه ذهنلری وکوچلری یته‌چکدر. دوقتور بو یکی عجیب نرسه‌نڭ بعض سببلرینی بیان ایدوب، بعض بر سببلرینی یاشروب صاقلامقده‌در.

◆◆ ریاضت بدنیه (ژیمناستیک) نڭ تن سلا مت اولمقینه فائده‌سـی وار ایدیکی کوب زمانلردن بیرلی معلومدر. شمدی ایسه بونڭ عقل سلامتلگینه وعقل آرتوینه‌ده فائده‌سی وار ایدیکی معلوم اولمشدر. صبی وقتنده ایرکنلك وحریت اوزرنده اویناب اوسـکان بالالرنڭ عقللی اولـدقلرینی بعض طبیبلرنڭ تجربـه وحسابلری کوسترمشدر.

◆◆ فرانسـز ایله گرمانیا، هوافلونی ترتیب

ایدوب شغللندیکلری معلومدر، شمدی ایسه بو اشگه آنکلیه دولتی ده کرشمشدر .

•• فرانسزلر پاریژ شهرنك «سان مرتبن» اورامینه تاش وآسفلت اورنینه تجربه ایچون تیمر توشامشلردر. اگر دهفائدهلی کورلسه باشقه اورامارغهده توشایهچکلردر .

•• آنکلیهنك، هر ییل : بویی اوچ میل وآر قلیسی بر میل قدر اولان یرینه دڭیز صوی کروب باصوب طورادر.

•• یرنڭ عنصرینی کیمیا قاعدهسی ایله تفتیش ایدوچی عالملر ،عمرینڭ مدتی یکرمی ملیون ییلدن آرتق اولدیغنی دعوی ایتهلر.

•• اوزاق وقت اوتمای «اسکندریه» شهری ایله «امید بورنی» آراسی تیمر یول ایله طوتا شاچاق وبو یول آفریقانڭ ایکنچی بر چیتنه واروب چیقاچقدر .

•• دنیانڭ الڭ الوغ شهرلری لوندن، نیو یورق، پاریژ، برلین ؤیانهدر .

•• روسیه مملکتی بتون آوروپا مملکتلر ندن دورت ملیون مربع کیلومتر قدر بیوکدر.

•• چیقاغو دارالفنونی طرفندن یبارلمش کیمسهلر «دجله» ایله «فرات» یلغهلری آراسنده آثار قدیمه قازدقلرندن بوندن یدی بیڭ ییل مقدم یازلمش کیرپچ وبالچق تاقتهلر تابمشلردر .

•• آوروپاده أت ایتی آشامق مودهسی تارالادر . اوتکان ۱۹۰۶نچی ییل یالکز گرما نیاده اون مڭ قدر أت صویلمشدر .

•• دنیاده الڭ بیوك سوداسی اولان شهر، چین مملکتنده «هونغ قونغ» شهریدر.

•• دنیاده اولان نرسهلرنڭ هر برنڭ حیات اولوب، هر بری اوزینه کوره جانلی وعقللی ابدیکنده علم اهللرینڭ شبههلری قالمامشیدی. شمدی ایسه بعض بر اوانلر چبن وقورتلر آولامقده ایدیکی معلوم اولمشدر. شوبله که بعض یافراقلر اوستلرینه چبن یاکه باشقه بر حشرات کلوب قوندی ایسه کیساکدن وسیزدرمازدن اوزینه قسوب آلوب صوینی صورادر وتمام کیبدروب بترکان صوڭ یرگه توشروب یبارهدر .

•• بیك زیراك اولغان صبیلر صوڭندن آڭغرا لانوب کیتهلر، شونڭ ایچون اگر دهسبق اوقورغه باشلاغان بالاعادتدن آرتق زیراك اولسه، اوقو ایله گنهشغللندرمای بلکه ذهننی اوبن وباشقه نرسهلرگه دوندروب طوررغه تیوشلی دییورلر .

•• اوڭ قول روشنده صول قولنی هم اشکه اوگرتورگه تیوشلی بووقتدهاوڭ قول بررتورلی خستهلك گه اوچرار اولسه آنڭ خدمتنی صول قول ایته بیلور .

•• انکلیزلر صوده باتمی طورغان کیمه یاصا مشلردر. بو کیمه یوز توبان آیلانسهده صوغه غرق اولمیدر .

•• فرانسهده «لیون» شهرنده هیچ بر بناسز یالان یرده شاکردلر اوقوتمق یولی تجربه ایدلنه چکدر . بنالرده هوالر بوزولوب شاکردلرنڭ سلامتلکلری بتدیکندن اوشبو روشده مکتبلر

ترنیب ایدوب تجربه ایته‌لر. بویله مکتبلر گرمانیاده کوبدن واردر.

◆◆ پاریژ نڭ «ایفل» قله سی ایله «مراکش» ده اولان «داربیضا» آره‌سینه چبقسز تلیغرام یاصالاچقدر.

◆◆ آمریقاده آستی قاتی پیالادن اوله‌رق بر کیمه ایشلانمشدر. برنده اوطوروب یورو چیلر صو ایچینده بالق وباشقه حشراتارنی کوروب یوریلر.

◆◆

## یاپونیا وآمریقا نڭ فلوتلری

| | یاپونلرنڭ | آمریقانڭ |
|---|---|---|
| ۱ نچی درجه برونینوسیلسلر | ۱۲ | ۲۶ |
| ۲ نچی درجه » | ۳ | ۱۱ |
| زرهلی قره یسرلر | ۱۳ | ۱۵ |
| پالوباسی تیمر » | ۱۹ | ۲۵ |
| کچکنه قربسرلر | ۸ | ۲۹ |
| قونتر مینانوسیسی | ۵۱ | ۲۰ |
| مینانوسکه | ٤٤ | ۳۵ |
| صو آستنده‌غی کیمه‌لر | ۱۲ | ۱۲ |

بو حسابدن کورینه درکه: زور صوغش کیمه لر بویونچه آمریقا، یاپونیادن ایکی دفعه قوتلیدر.

## پاریژغه کوبمو سیاح کیله ؟

فرانسیه جمهوریتنك پایتختی اولغان پاریژ شهرینه ۱۹۰۶ نچی یلده ۱ ملیون ۸۰۲ مك سیاح کیلوب بونڭ ٤۵۳ مڭی چیت مملکتلر دندر. بو اجنبیلر پاریژده آز دیگانده ۱۸۰ ملیون صوم آقچه قالدرغانلر؛ بوشهر نیچک بایوماسون ؟

◆◆

## روسیه‌ده نهر وپاراخودلر.

آوروپای روسی‌ده بارژا وپاراخودلر یوررلك صولر بتونسی ۲۰۰ مڭ، ترکستان ایله سبرده ایسه ۶۰۰ مڭ چاقرمدر. حالبوکه بتون آوروپاده (روسیه دن باشقه مملکتلرده) پاراخود یوررلك نهرلر فقط ۵۰ مڭ چاقرمدر. پاراخود ایله یورتو تیمر یولغه قاراغانده ارزان واوڭغایلی بولغانلقدن روسیه طوپراغی تجارت وحرکت ایچون آوروپاغه قاراغانده دفعه‌لرچه اوڭغایلی ایدیکی کوریلور.

روسیه‌ده حاضرنده ۳ مڭ ۶۰۰ پاراخود و۲۵ مڭ قدر بارژا یوری. بونلرنڭ همه‌سینه ۸۱۹ میلیون پود مال صیا. حالبوکه: فرانسیه‌نڭ نهرلرده‌گی پاراخود وبارژالری ۲۱۰ ملیون؛ گیرمانیانقی ۱۶۵ ملیون وانگلتره‌نڭ بتون دیگز پاراخودلری ۶۲۰ ملیون پود مال صیدره لر. لکن روسیه‌ده پاراخودلر آوروپاده‌غی کبی توگل، واق هم ناچارلر. آوروپاده بارژا آز بولغانده روسیه‌ده بارژالر پاراخودلردن ۷ مرتبه کوب هم دفعه‌لرچه زوردرلر.

◆◆

## روسیه ده مناسترلر.

روسیه‌ده ۸۳۲ مناستر بولوب بونڭ ۵۰۰ زی ایرلرنکی و ۳۳۲ سی خاتونلرنقی‌در. روسیه‌ده مناسترلرنڭ الڭ نق آرتووی ایمپراطور آلیکساندر اوچنچی زماننده بولوب

آنك پادشاهلغی وقتنده ۱٦٠ یگی مناستر آچلغان ایدی . صوڭغی یللرده کوبرك خاتونلر مناستری صالالر . مثلا صوڭغی ۲٠ یل اچنده ایرلرگه مخصوص ٤٥ یگی مناستر صالنغانده ، خاتونلر ایچون ۲٥۹ مناستر آچلمشدر .

روسیه‌ده ۱۹٠۲نچی‌یلده ۸٤٥٥ ماناخ ایله ٦٦۹۱ پاسلوشنیق و ۱٠۹٦۳ ماناشقا ایله ۳۲٠۲۹ پاسلوشنیتسا بولمشدر . دیمك اورطه حساب ایله هر ایرلر مناسترینه ۳٠ وخاتونلر مناسترینه ۱۱۸ کشی طوغری کله‌در .

مناسترلر پك بایلردر . مثلا : صالاڤینسکی مناسترینك ٦٦ مك ، قوڤیازورسکی مناسترینڭ ۲٤۸۳٦ ، طرویسکی زیلینیتسکی مناسترینڭ ۳٦ مك دیساتینه یری بار . برار ، بیشار واونار مڭ دیساتینه یرلیلری‌ده کوب بولوب جمله‌سینڭ یری تخمینا ۷ ملیون دیساتینه صانالادر .

معلومدرکه : ایرلر مناسترنده یاللانوب خدمت ایتوچیلرنك کوبسی خاتون ، خصوصا طول خاتونلردر . مناسترلر قولنده داخود کیتره طورغان یورتلرده کوب بولوب هر یل مناسترلر بونلردن یوز مڭلرچه جیالر ؛ خزینه دن‌ده مناسترلرگه الوش چغا .

مناسترلرنڭ نه قدر بای ایدیکلرن کورساتو ایچون مثلا ، پیتربورغداغی آلیکساندرانیفسکی مناسترینڭ باشاغی یلغه ۲٥٠ مك صوم ژالونیه آلغانلقنی کورساتو شاید کافیدر .

## صغر آصراوچیلرنك دقتینه .

( صغرنك جیلوننی نه روشده تمیزلرگه )

---

سوتنك وسوندن بولغان نرسه‌لرنك بوزلماوینی و یخشی تملی بولوینی تله‌گان کشیلر اوشبو نرسه‌لرنی اعتبارغه آلورغه تیوشدر :

صغر صاوغانده جیلونگه یابوشقان چوپلر هم باشقه نرسه‌لر سوتکه توشماسون ایچون اوّل جیلوننی تازارتمق کرکدر . صغرنك جیلوننی هر صاوغان صاین صو ایله یوارغه تیوش توگلدر ، آنك ایچون صغرنڭ جیلونینه صورق نیووی هم یوغان نچار صو ، سوتکه توشویده احتمالدر . اك یخشی‌سی صغرنی بتونلای تازارتقانده جیلوننیده یومشاق قوری چوپره‌ك ایله ، قوری تازا صالام ایله یا خود یومشاق شچوتکه ایله تازارتمقدر . تازارتقانده قوباتورغان تیری ، یونلر برده قالمازغه تیوش . اگرده پچراق نرسه‌لر بیك کوب یابشوب یوقاریده ایتولگان نرسه‌لر ایله تازارتو ممکن بولماسه یلیراق صو ایله یوارغه ممکن ، هم یوغاچ قوری سولگی یاکه باشقه بر چوپراك ایله بیك یخشی قورتوب ، صغرنی جیل یوری تورغان اورنده توتمازغه تیوش ، بوندن صوڭره هر صاوغانده جیلوننی هم آنڭ جیرچق قانلاولرینی یومشاق قوری چوپراك ایله سورتو تیوشدر . اوشبولرنی رعایه قیلغانلر شکسز

ایك یخشی سوت هم تیز بوزولمای تورغان سوتــدن بولا طورغان نرسه‌لرنی حـاضرلی آلاچاقلر در.

## تقریظ و انتقاد

تقریظ وتقریض . مدح ، طعن وانتقاد. اللزومیات . موسی افندینك ترجمه وشرحی . حسن بك ملیکوف . معری ' فرید وجدی . طرویسکی مکتوبی . شهر وحسن افندیلر .

عرب ، ترك ، فارس مجله لرنده آیروم بر باب قویلوب یکی باصلوب چیقمش اثرلـر حقنده بحث ایدلمك بر عادتدر. ایشته بونلرغه اوخشامق نیتی ایله بزده «شوری» ده آنلر روشنده وباب باشینی‌ده آنلردن آلوب«تقریظ وانتقاد» دیه بر باب آچدق .

دنیاده اولان بر کیمسه‌نی کرك حق وکرك باطل یول ایله اولسون مدح ایتمك « تقریـظ » اولور. کرك دنیاده اولسون، کرك اولماسـون بر آدمنی مدح یا که ذم ایتمك «تقریض»در.

مدح ایله طعن هر کیمه معلوم اولســه ده «انتقاد» هر کیمه معلوم دگلدر. بر، کتاب ورساله‌نی دقت ایله اوقـوب ده یازو چیسنــدن بتونلای قطع نظر ایتمکله خصوصی صورتده اولان آنك دوستلق یاکه دشمنلغنی کوکلدن تمام چیقاروب کتابنی تفتیش ایتمك ، اوزون وتیره‌ن تدقیقلر صوکنده کورلدکچه یخشی یرلرینی یخشی ویمان یرلرینی یمان دیمك «انتقاد»در.

کوزل سیرتلی ، کوب معلوماتلی محررلر ویا که کوچلانوب اولسه‌ده آنلرغه اوخشارغه طرشوچیلر اثرلرینك انتقاد ایدلدیکنی غایت راحتلك اوزرنده سیر ایدوب طوررلر. زیرا اثرلرینك انتقاد ایدلمسندن آنلر استفاده‌ایدرلر وکندیلرینك مسلکلرنده اولان تـوزوکلك وبوزوقلقنی آچلاب اوزینه کوره اصلاح چاره‌لرینه کررلر. عصردشلرمزدن برکیمسه‌گه: «شول اثرلرگزگه اسمگزنی‌نیچون قویمادکز؟» دیمش ایدك . اول‌ده بزلرگه :« انتقادایدلدیگنی کورمك وشوگا کوره‌ده بر مسلك انتخاب ایتماکلکم ایچون! اسمم ذکر ایدلسه ایدی دوستلرم مدح، دشمنلرم ذم ایدرلر، اما بگا نه فائده اولور؟ » دیدی .

انتقاد ایده بیلمك بیوك بر کمالتدر. فقط آدم اوغلی‌نه‌قدرعالم اولسه‌ده‌اولسون‌عصبی‌مزاجلی اولورایسه‌انتقادطوغرولرینه‌کرشمازسزلکی‌اوزی ایچون‌ده‌باشقه‌لر ایچون‌ده خیرلیدر . انتقاداسمیله بر کیمسه‌نك اثرینی مدح وذم‌ایتمك حقسزلق، اما اثرندن محررینك شخصینه کـوچمك بتون بتونه فضیلتدن محروملق علامتیدر.

سوریه ومصر ، بغداد وتونس ،هندستان واستانبول مطبعه‌لرنده هر کون صانسز اوله‌رق یکی وایسکی اثرلر نشر ایدلنور. وبونلرده کروان وتیمر یول ، پاراخود وپوچته ایله

دنیا نڭ هر طرفینه ، یلغه لر مثا لنده آغوب طورر. حالبوکه بونلر آراسنده بعض وقتلر مسلمانلرغه واسلام دینینه قارشو یازلمش شیلرده بولنور .

محیط دڭیزی روشنده جایلوب یاتمقده اولان جریده ومجله لر، رساله موقوته ومجموعه لر بونلر حقنده سکوت ایله کچر ، باشنی اوستون کوتاروب باقماز . شول آراده بعض بر کوچك رساله لر میدانه کلور ، فقط بونلرنڭ حتی مطبعه دن چیقوب یتدیکلرینی ده کوتمای اونه گی مطبوعات قارشو آلوب انتقاد ایلر ، بتون دنیا افکارینی دولقنلا تورلر ، اوشبو دولقونلرده حتی یر آستونده اولان اویلرگه قدر باروب کروب اثرینی کوسترر .

بونچه بیوك وکوچك اثرلرگه کوز صالمامش کونلك ، وآیلق مطبوعات ، نه اولورده آرادن برینه بو درجه ده اهمیت ویرر واتفاق اوزرنده تفتیش ایلر؟ شمدیلك بز بوڭا جواب ویرمیه چکمز . زیرا بونی یازمقدن بزم مقصودمز بونڭ فلسفه سنی تیکشرمك اولمای بلکه اوزمزده بوڭا اوخشامش بر حادثه نی کوسترمکدر .

موسی افندی طرفندن انتخاب ، ترجمه وشرح ایدلمش « اللزومیات» روسیه ده چیقمقده اولان معتبر غزته لرنڭ هر برنده کوبمی آزمی بحث ایدلنوب کچدی. باشقه لره کوره صوڭغه قالوب یازوچیلر قزانده «الاصلاح» وتاشکندده « تجار» در . اولگیسنده شهر افندینڭ وصوڭغیسنده ده سمرقند مفتیسی محمود خواجه جنابلرینڭ مقاله لری نشر اولندی.

شهر افندی، معری ولزومیاتنی ترجمه واسلوبینی مدح ایتدیکی صوڭ ، فرید وجدی سوزلرینه اسناد ایدرك موسی افندینڭ معری گه طرفدارلق ایتدیکینه تعجب ایلر. بونڭ جوابی ایسه موسی نڭ اوز اوستنده در . بزم ایشمز یوق، فقط اشعری سوزیله جبائیدن، ابن حزم سوزیله اشعریدن ، سبکی سوزیله ابن حزمدن، باشقه برینڭ سوزیله سبکیدن محبت آلنور اولسه دنیاده طرفدارلق ایدرگه لیاقتلی کیم قالور ؟ احتمالکه بتون خلقغه بایقوت ایتمك لازم کلور .

شهر افندینڭ ابن خلدوندن نقل ایتدیکی سوزینی بزلر ابن خلدوندن تابا آلمادق ، کوزمز کورمادیمی؟ یوقسه نسخه مزده عبارت توشوب قالمشمی؟

سمرقند مفتیسی جنابلری کندینڭ سیاحتی اثناسنده « قزان» شهرنده موسی نی ایزلب تابوب، دقیقه لر ایله حجره سنده اولدیغنی افتخار مقامنده سویلر وجناب اللهدن بویله بر شرافتنڭ تکرار نصیب اولنمه سینی رجا ایلر. سبحان الله ! بونه دیمکدر؟ سمرقند مفتیسی قزانه وارورده کناز دگل، میرزاد گل، پاتومستؤبننی دووراندگل، اوکازی یوق، پریکازی یوق، چاپانی یوق، چالماسی یوق، (اوستنده یوق! ) صدقه ویرمی ، پلاو آشاتمی؛ باشنده قوراژقه واوستنده قورتقه، قول باشینه قدر توشکان اوزون ساچلی الحاصل « موسی » لقدن باشقه هیچ

بر دنیاوی درجه‌سی و منصبی یوق بر کیمسه‌نی ایزلب طابمش و صحبتندن کوکلی خشنود اولمش. تکرار ایلرم که بو نه دیمکدر؟

بو شی امیدسزلکلرمز و یأسلرمز رغمینه اوله رق بزلرده‌ده علم حرمتی طانلمیه باشلادیغینه علامتدر. بویله حاللره بز شویله بر معنا ویررگه مجبور اولدق و علم بازاری رواجلانه چغینه براعت استهلال ایلادك. اوشبو روشده فکر ایدومزگه باعث اولان شی مفتی واقعه‌سی گنه اولمای، باشقه‌لرده واردر:

طرویسکی شهرندن آلدیغمز بر مکتوبده، قاضی صایلامق طوغروسنده مفتی حضرتنك بالکز قزان ملالرینه غنه مشورت ایدوب باشقه‌لرنك التفاتسز قالدقلرینه اوپکه ایتدیکی صوك: «سیبریادن قاضی تعیین ایتمك لازم اولسه، قاضیلق ایچون ده گوزل اخلاق ایله حقیقی علم صاحبی اولمق کرك اولسه «قزیلجار» شهرنك حسن افندی بونك کشیسیدر» دیورلر. بو آدمنك ده «حسن» لگندن باشقه دنیاوی منصبی اولماسه کرك.

«باکو»ده حسن بك ملیکوف وفات ایتدی. کوکره‌کی نشانلر و اوردینلر ایله طولمادیغی حالده بونك وفاتی سببندن بتون قفقاز قزان اورننده قایناذی. کیمی ترجمهٔ حال یازار، کیمی تعزیه ایلر، کیمی مرثیه سویلر و هکذا. ملالر، سوداگرلر، جمعیتلر، شاگردلر و عواملره قدر بونی صاغنورلر، احترام ایلرلر. «بر شهر قاضیسنك ایشاگی وفات اولدیغنده بتون شهر خلقی جنازه‌سینه کلمش اما کندیسی وفات اولدیغنده بر کیمسه ده کلمامش!» دیه بر حکایت سویلرلر. ایشته بونك عکسنچه اولدیغی ایچون حسن بك ملیکوف بختیاردر. الله تعالی مظهر عفو ایلاسون! اوشبو ایکی واقعه هم مفتی واقعه‌سی کبی شیلردر.

## « اسلاملر حقنده حکومت تدبیرلری »

اوشبو اثرنک ۳۴ بیتدن عبارت اولان برنچی جزئی اورنبورغ شهرنده «وقت» کتبخانه‌سی طرفندن «کریموف — حسینوف و شرکاسی» مطبعه‌سنده باصلوب چیقدی. بتون مندرجه‌سی رسمی کاغدلردن آلندیغی جهتله هر وقت مراجعت ایدلنه چك بر اثردر.

## اجمال سیاسی و باشقه‌لر:

### (داخلی)

**۱۹۰۷** نچی ییل ایچنده اولان سیاسی و غیر سیاسی حاللر اوز وقتلرنده غزته‌لرده یازلنوب طوردی و خلقلرده اوقودی ایسه‌ده بوندن صوك مجموعه‌ده یازلنه‌چق حاللرگه نیگز اولسون ایچون قسقه‌لق اوزرنده بو یرده سویلب اوتارگه لازم کورلدی.

**۲۰** نچی فیبرالده ایکنچی دوما آچلدی.

بونده اولان مسلمان اعضالر اوشبونلر ایدی.

۱) شاه‌مردان قوشچیغواوف (آقمولّا)
۲) مخدوم قلی خان (آصخاباد)
۳) عبدالواحد قاری قارییف (تاشکند)
٤) تیمر علی نورکایف (سیمی)
۵) بخت جان قاراتایوف (اورالسکی)
٦) احمد بیر مجانف (تورغای)
۷) تیلاولی الله بیرگانف (سیر دریا)
۸) تاشبولاد عبدالخلیلوف (سمرقند)
۹) صالح جان محمد جانوف (مرغیلان)
۱۰) محمد صابر حسنوف (اوفا)
۱۱) محمد شاکر توقایوف ( » )
۱۲) شرف‌الدین قولباقف ( » )
۱۳) محمد اکرم میرزا بیغلوف ( » )
۱٤) قطلغ محمد میرزا تفکیلوف ( » )
۱۵) شاه حیدر سرطلانوف ( » )
۱٦) خیر الله عثمانف (اورنبورغ)
۱۷) شاهبال سیف‌الدینوف ( » )
۱۸) صدرالدین مقصودف (قزان)
۱۹) عمر موسین ( » )
۲۰) صفی‌الله مقصودف ( » )
۲۱) رشید بك مهدییف (قریم)
۲۲) آرسلان بك قرداشف (داغستان)
۲۳) بی بالابك سلطانوف ( » )
۲٤) فتح علی خان خایسکی (یلزاویتوپول)
۲۵) خاصممدوف ( » )
۲٦) مصطفی محمودوف (باکو)
۲۷) تاشتمیر ایلدر خانوف (تیوسکی)
۲۸) محمد آغا شاه تختینسکی (ایریوان)
۲۹) کلیم‌الله حسنوف (اوفا)
۳۰) هادی آطلاسوف (سامار)
۳۱) عبدالله نجم‌الدینوف (سمبر)
۳۲) عارف بادامشین (قزان)
۳۳) حبیب‌الرحمن مسعودوف (ۋانقه)
۳٤) زینال زینالوف (باکو)

اوشبونلردن **۲۹**نچی نومیرغه‌قدر اولانلری مسلمان فراقسیه‌سینه منسوب اولوب، **۲۹** دن باشلاب آخرینه قدر اولانلری اوزلرینه «ترودا ویك» اسمنی ویرمشلر.

**۱۰**نچی **۱٦**نچی، **۲۰**نچی **۳۰**نچی **۳۳** نچی نومیرلر اوکازلی ملالر، قالانلری سوداگر، ضیالی، عوام، علما صنفنه منسوبدرلر.

**۱**نچی اییونده اولان مجلس‌گه مینیسترلر حاضر اولوب، دوما مجلسینی یابق یاصاتدیلر و اعضالردن ایللی بیش کمسه‌نڭ سیاست جهتنچه عیبلی ایدیکنی و بونلردن اون آلطیسی بو ساعتدن حبس ایدیلرگه تیوشلی ایدیکنی سویلب دومادن بونی طلب ایتدیلر وبو حقده اوزون بر تهمت نامه اوقودیلر. بو اعضالر جمله‌سی‌ده سوسیال دیموقرات فراقسیه‌سینه منسوب آدملر ایدی.

**۲٤** ساعتده تمام ایتمك شرطیله دوما، بو مسئله‌نی کامیسیه‌گه ویرمش فقط مذکور کامیسیه اشنده دوام ایتدیکندن صوڭ **۲٤** ساعت ایچنده تمام ایته آلمادیغنی بلکه **٤**نچی اییون مجلسنه دوقلاد ایده چکنی **۲**نچی اییون مجلسنده بیان ایلمشدر.

۳ نچی ایبونده مانفیست ویـکی نـظام چیقوب، اوشبو ۳نچی دوما قوولدی. بو دوما ۱۰۲ کون دوام ایدوب ۵۳ دفعه مجلس اولمش و۸۷نچی ماده گه موافق ایـکی دوما آراسنده چیقـارلمش بعض نظاملرنی بوزمشدر. صایـلاو طوغروسنده یڭی نظام هر بر خلق وحزبلردن بیـگراك یهودیلر ایله مسلمانلر ایچون ضررلی اولمشدر : بوڭا کوره بیوك ترکستان ایله بیوك قرغز وقزاقستان صایلاو حقندن محروم قالدیلر وباشقه گوبیرنالرده اولان مسلمانلرغه‌ده اثری بولدی.

۲۰ نچی نویابرده ۳ نچی دوما آچلدی. بونده ایسه ایکنچی دومانڭ ۳۴ اعضاسینه قارشو آنچق اوشبو ۱۰ عدد مسلمان بولنور:

۱) اسماعیل میرزا مفتی زاده (قریم)
۲) خاصمحمدوف (قفقاز)
۳) حیدروف (داغستان)
۴) جهانگیر بایبورین (اورنبورغ)
۵) صدرالدین مقصودوف (قزان)
۶) عیسی میرزا ینکیبف ( » )
۷) قطلغ میرزا تفکیلوف (اوفا)
۸) علی اصغر صرتلانوف ( » )
۹) محمد شاکر توقایف ( » )
۱۰) شرف‌الدین محمودوف ( » )

اوشبو ییل ایچنده سیاسی اشلر ایله تورمه لرگه یابلو ، چیتلرگه سورلو ، الوغ وکچك مأمورلرنڭ اوترلوی کبی اشلرنی تفصیل ایله سویلرگه حاجت یوقدر.

برنچی دوما تاراتلدیغی صوڭ اعضالرندن ۱۸۰ عدد کیمسه فینلاندیه‌ده «ۋیبورغ» شهرینه واروب «عسکر ویرمه‌گز، نالوغ تولامه‌گز!» دیه خلقلرغه خطاب نـامه ترتیب ایندیکلری ایچون اولاژینیه ـ نا قازانیه‌نـگ ۱۲۹ نچی استاتیه‌سی بوینچه حکومت طرفندن حکم‌گه ویرلمشلر ایدی. دکابر آینده شونلرغه حکم بولوب، هر برینه اوچار آی تورمه وبوندن صوڭ سیاسی صایلاو حقلرندن محروم ایتمک ایله جزا ویرلدی. بو حکمدن یالـگز ایکی دانـه اعضا خلاص ایدلمشدر.

خصوصی مسلمانلر حاللرینه کلنچه: ۱۸۹۶نچی ییلدن بیرلی خلق آراسنده بحثی دوام ایدوب طورغان ۳۱ نچی مارت نظامی، اوکـتابر آینده پیتربورغڭ معارف ناظری ریاستنده اولان کامیسیه‌ده قارالدی واوکتابر نظامی اسمی ایله ۱۵ ماده‌دن عبارت ایکـنچی بر نظام توزولدی.

مسلمان اتفاقینڭ نظامی حکومت طرفندن تصدیق ایدلمادی وحکومت رخصت ایتـمادیکی سببندن مکاریه‌ده اسیبزد هم اولمادی. آقچه‌سی بوقلغندن پیتربورغده روسچه غزته چیقارمق فکرلری میدانه چیقمای یولده قالدی.

مکتب ومدرسه‌لرنی اصلاح حقنده بر آدوم اولسون آدلانمادی، درسلری ترتیبکه قویمق طوغروسنده حرکت فلان کورلمادی. خلقلر همیشه زکات آقچه‌سنی مدرسه‌لر وشـاکردلر فائده‌سینه صرف ایدرگه یاریمی یا خود ایلـکار

گی روشده توگولوب ساچلوب طورسنمی ؟ زیمستوالردن (اگر ویرسه‌لر) مکتب ومدرسه لر ایچون اعانت آلورغه یاریمی یوقمی؟ بالا - لرنی قارا ناقته‌غه یازدروب اوقو شریعت قاشنك درسنمی؟ نزاعلری ایله اولگیسی کبی دوام ایتمکده لردر. مسجد صالنور ایچون پیتربورغ شهرنده اورون آلندی.

ییل آخرنده مسلمانلر طرفندن ترکی لساننك ۱۵ دانه غزته وژورنال نشر اولنور ایدی، مسلك اعتبارنچه بونلر بویله آیرلورلر:

۱) دینی، ادبی.
۱) نا معلوم.
۱) مکتب ومدرسه‌لر اصلاحی حقنده.
۱) حکومت طرفداری.
۲) هزلی، انتقادی.
۱) اعلانات.
۸) ملی، اجتماعی حریت طرفداری.

مارتنگ ۱۱ نچی کوننك پابیدانوسف وفات ایتدی. بو آدم مسلمان دگل ایسه‌ده اوزلرینگ شیخ الاسلام ومفتیلرندن آرتق روشك مسلمانلرغه معلوم ایدی. مسلمانلر وعموما چیت خلقلر حقنده ایلمینسکی ایله پابیدانوسفنگ طوتمش مسلکلری اونودلنه‌چق شیلردن دگلدر. روسیه نگ سیاستی بتون بتونه پابیدانوسف تعلیمی ایله یوررگه باشلامشیدی. پابیدانوسف ایسه اوشبو ایگونلگینگ نه کبی اورلق ویردیکنی کوروب دنیادن اوتدی. مسلمانلر، پابیدانوسفنگ وفات اولدیغی ایچون دگل بلکه وفات اولمازندن مقدم، اوز عملینگ نتیجه سنی کوردیکی ایچون خشنود اولمشلردر.

(خارجی)

آنکلیه ایله روسیه اوزارالرنك ایران مملکتنی بولوب قویدیلر، بوندن صوك ایران حقنك اولاچق سیاستلری اوشبو بولوگه کوره اوله‌چقدر.

فرانسیه، تورلی حیله‌لر ووحشتلر اجرا ایدوب، برنچه عصرلردن بیرلی دوام ایتمکده اولان فاس حکومتنی بوزدی ومسلمانلری همیشه مسلمانلر سونگولری ایله اوتر توب قردروب طوررلر، رسمی صورتك اوله‌رق دیننی حکومتدن وحکومتنی دیندن آیردی.

گرمانیا اوزینك اولگی مسلکی اوزرنك ترکیانك سوداسنی وخیلی امتیازلرنی قولینه آلوب طورادر، اشلاتدیکی قدر بغداد تیمر بولی بوینه نمسه‌لرینی یرلشدره، دوست بولغان بولب ترکیانك سوتنی صاووب ایچه وبوکا قارشولق یالگز یالاغایلانودن باشقه بر فائده‌ده کوسترمی.

قطای حکومتی حریت ویروب، پارلامینتو آچاچاغنی خلقینه وعك ایدوب، اوشبونك ایچون حاضرلك کوررگه کرشدی.

آمریقا ایله یاپونیا آراسنك دعوی علامتلری همیشه دوام ایته‌در، کوب کمسه‌لر بونلرنك آراسنك محاربه اوله‌چغنی ظن ایلرلر، آمریقا فلوتلری فیلیپین طرفلرینه ویاپونیاغه کورشی اورنلرغه سفرگه چیقمشدر. بو ایشی ایله یا یاپونیانی قورقوتر، یاکه یاپونیانی صوغشقه چاقرر.

ایران ایله ترکیا آراسنده حدود نزاعلری

اولگیچه دوام ایته‌در ، ترکیا عسکری (کوب خبرلرگه کوره) ایران ملکینه ڪکرمشدر . ماکیدونیانڭ بوکونده اولان حاللری ، کریدنڭ صوڭغی کونلرینه اوخشامقده‌در . حجاز تیمریولی آز آز اولسه‌ده آلغه واره‌در.

هندستانده، مجوسیلر طرفندن انکلیز حکومتنه قارشو چقارلمش اختلالنڭ تمام سونوب بتدیکی یوقدر . اگرده حکومت ضعیفلنسه ، مجوسیلر قول آستنده قالورمز، اویله ایسه: « أت آشاغانچی بوری آشاسون : » مثلنچه مسلمانلر حکومت طرفنده قالدیلر* وآڭا یاردم ویردیلر .

مصرده اسلام جریده‌لرینك هجوم وانتقاد لرینه توزه آلماینچه لوردقرومیر «سلامتلکم یوق» دیه استعفا ایتدی ، پارلامینتو آچمق حقنده حکومتلرندن وانکلیز حکومتندن مسلمانلر جریده‌لری واسطه‌سیله طلب ایته‌لر . «الجامعه» اسمنده بیوك بر عمومی مدرسه آچار ایچون ایکی ییلدن بیرلی اجتهاد ایدوب آقچه جیسه‌لرده همیشه تمام اولدیغی یوقدر . مصر مسلمانلری روسیه اسلاملرینڭ آچلق ایله مبتلا اولدقلرینی ایشتدیکلرنده ، اوچ مڭ صومدن آرتق اعانت جیوب اورنبورغ شهرنده «وقت» اداره‌سینه یباردیلر وتیوشلی کورلمش یرلرگه تاراتورغه قوشدیلر .

ایرانده ملت مجلسی دوام ایته‌در وهیچ کیمنڭ فکر ایتمادیکی صورت ایله کوندن کون کوچلی واشلکلی اولوب بارادر ، شاه وبیورفراتیه طرفندن کورلمش هر تورلی حیله ومکرلرگه مقا ت ایدب، ملت مجلسی اوز مرادینه موافق صورنده شاهدن آند ایتدردی .

أفغان خانی هندستانده سیاحت ایدوب قایتدی، مکتب ومدرسه اشلری ایله مشغول اولدیغی روایت ایدلنور .

ایشته کچردیکمز ۱۹۰۷ نچی ییلده اولان سیاسی وغیر احوالنڭ اجمالی بوندن عبارتدر. بوندن صوڭ اوله‌چقلر آلده‌در، عمری اولان کورر وبیلور .

## مراسله ومخابره:

« بلبای » اویازنده ملالر :

عسکرلکده یوروب قایتمش یکتلرنڭ نکاح وطوی وقتلرنده عموماملالر یکتنڭ پاچپورتینی صوریلر وبتون خلق حضورنده « سلامت قایتقانمی ؟ پاچپورتنده — محمدانسکی — دیه یازلغانمی ؟ » دیه تفتیش ایته‌لر . بو سببدن هر ایکی طرف پك اویالالر ، قزارالر ، حتی پاچپورتی یوغالغان یاکه ژاینسکی ناچالنیك قولنده قالغان بولسه نکاحنی اوقومی طوینی طاراتالر. بونڭ سببنی صوردیغمزده تنظیمات ده شویله یازلغان، دیلر . بو کونده قولمزده وتیره‌مزده « تنظیمات » یوق ، شونڭ ایچون جوابنی‌ا داره‌دن اوتنه‌مز .

« شورا » : ـ جوابی کله چك نسخه ده درج اولنور .

## اشعار :

### کراب

شاولی دینگز . . .
جبل اوره در . . .
یلــکانن کیرگان کراب !
تون و کوندوز
اول یوره در :
یول بارا یات ایل قاراب . . .

§

چقدی جیللر ،
قوبدی طولقن —
ایل کرابن جیل سوره ! . .
قایسی یوللار ،
نینده‌ی اوبقن
طارتا بزنی جان صوراب ؟ !

دردمند.

# امثال :

(ش . سامی بکدن)

۱) انسان ایچون الڭ گوزل بوانچ مطالعه، الڭ یخشی ایبده ش کتابدر .

۲) بر گوزل ایش، مڭ گوزل سوزدن فائده لیره کدر .

۳) اویون کولکولرنڭ لذتی کوبلک وجمعیتده ، مطالعه نڭ لذتی یالڭزلقده طابلور .

۴) اوز قولڭدن کیلگان بر ایشده باشقه لردن هیچ یاردم ایستهمه .

۵) تعجب کوبسنجه نادانلقدن طوغادر .

۶) عقللی آدم اوزندن واوزینه متعلق نرسه لردن بحث ایتمز .

۷) ایشه بیلمه سه ڭ قایق غه (لودقه غه) اوطورمه .

۸) ایسروکللك کشینی اوزگارتمی ، یالڭز آنڭ طبیعتن میدانغه غنه چقارا .

۹) کتودن آیرلغان قوینی بوری آشی .

۱۰ دنیاده یمانلقلر کوبسنجه یا بیك آچلردن ، یاکه بیك طوقلردن بولا .

№ 563

## لطائف :

### ایرایله خاتون آراسنده :

ایر – (اوتوب باره طورغان ایشا گن کوستروب) ظن ایدرسه م بو، سزنڭ قارنداشڭزدر .

خاتون: درست قارنداشم، لکن ایرم طرفندن!

خاتون : ( ایرینه ) بو آسراومز حمیده پك یخشی، آش پشررگه اوستا ، نرسه نی تلف ایتمی، چیقوب یورمی، کوب سویلامی، قارشو سوز آیتمی !

ایر — کاشکی سنی آلغانغه قدر بیلگان بولسه مچی!

« دیوژه ن » اسملی بر حکیمدن :

« راحت یوقلار ایچون کشی نیچك یاتورغه کرك؟ » دیه صوراغانلر. دیوژه ن : « نیچك راحت بولسه ، شولای یاتورغه کرك » دیمش. اوته گی آدمنڭ : « بن هرتورلی یاتوب قاریم، اما هیچ بر تورلی راحت ایته آلمیمن » دیمه سینه قارشو دیوژه ن : « اویله ایسه قبرگه کرگانچه صبر ایدوب طور ...» دیه جواب ویرمشدر .

## اخطار :

اوشبو نومیرده « روس ادبیاتی » اسمیله کرکلی بر بحث یازلورغه باشلاندی . کله چك نومیرلرنڭ برندن باشلاب « عرب ادبیاتی تاریخی » و « ترکی ادبیاتی » حقنده فائده لی بندلر ومقاله لر درج ایدلنه چکدر .

اوشبو مناسبت ایله الڭ مشهور اولان عرب عالملری؛ ابن سینا ، زمخشری ، ماتریدی وامام بخاری کبی ایسکی ترکی عالملری ؛ کمال بك، ابوالضیا توفیق بك، احمد مدحت افندی کبی صوڭ ترك ادیبلری حقنده نادر معلوماتلر ویرلسه کرك .

ناشرلری : محمد شاکر ومحمد ذاکر رامییفلر .
محرری : رضاءالدین بن فخرالدین .

Тип. «Т-ва Каримовъ, Хусаиновъ и Ко.», Оренбургъ

« اورنبورغ » ده اونبش کوننك بر مرتبه چقا
طورغان ، علمی، ادبی ، سیاسی

## « شورا »

مجموعه‌سی ایچون آبونه دفتری آچیقدر .

بریللق ٤ صوم . . . . یاروم یللق ٢ صوم ٢٠ تین.
٣ آیللق ١ صوم ٢٠ تین. چیت مملکتلرگه سنه‌لکی ١٠ فرانق

**« وقت » ایله « شورا » هر ایکیسی بر لکده**

بریللق ٧ صوم . . . . یاروم یللق ٣ صوم ٨٠ تین.
٣ آیلق ٢ صوم

آدریس : Оренбургъ, редакція « ШУРО »

## « وقت »

« اورنبورغ » ده هفته ده ٣ مرتبه چقا طورغان ،
ادبی ، سیاسی ، غزته‌در .

بریللق ٤ صوم . . . یاروم یللق ٢ صوم.
٣ آیلق ١ صوم ٢٠ تین. بر آیلق ٤٠ تین.

آدریس : Оренбургъ, редакція « ВАКТЬ »

تفلیس شهرنك چقا طورغان گوزل رسملی، کولکولی

## « ملا نصرالدین »

ژورنالینه آبونه قبول ایتولنه در. حقی بریللق
٥ صوم؛ ٦ آیلق ٣ صوم؛ ٣ آیلق ١ صوم ٦٠ تین.

آدریس : г. Тифлисъ
ред. « Молла-насрет-динъ »

## « الاصلاح »

علم وتعلیمگه دائر هفته‌ده بر مرتبه
چقا طورغان غزته‌در .

بریللق ٣ صوم یارم ییللق ١ صوم
٥٠ تین. اوچ آیلق ١ صوم. شاکرد
لر ایچون ٣ آیلغی ٧٥ تین.

آدرس : Казань редакція
« Эль-ислахъ »

## شرق کتبخانه‌سی

هر تورلی درس ومطالعه کتابلری،
خریطه‌لر ومکتب اسبابلری بولنور .
هندستان ، مصر ، استانبول مطبعه
لرنده باصلوب چقمش نادر اثرلر
کوبدر .

آدریس : г. Орскъ, Оренб. губ.
Ахмеду Исхабову

## اداره دن :

●● اوشبو برنچی نومیر « شورا » هربر « وقت » آلوچیلرغه نمونه اوله‌رق کوندرلدی. ٢ نچی نومیردن باشلاب ایسه یالگز آبونه یازلوچیلر نسبتنده‌گنه باصیله‌چق و شونلرغه غنه یبارله‌چکدر .

●● فخری افندی‌گه « بیشك تیروسنك » اسملی مقاله‌کز کیله‌چك نومیرده باصیله‌چقدر .

●● مجله‌نی تبریك ایدوب یازوچیلرنك جمله سینه صمیم قلب ایله تشکر اولنور . بوندن صوك هم رعایتلرندن یراق طوتمازلقلری مرجودر. مجله ایسه بو کبی فضل وادب اهللرینك اعتبار ایده‌چکلرینه امید طوتوب میدانه چیقمشدر .

تصحیح : ــ مجموعه‌نك برنچی بیتنده باشنده سنهٔ هجریه ١٣٢٥ یرینه مرتب خطاسی اوله‌رق ١٣٢٤ باصلمشدر.

بونومر «شورا» نڭ

## مندرجه‌سی:


مقصد ومسلك.

قطعه.

جعفر بن سلمكی.

روس ادبیاتی.

حج حقنده معلومات

تیلسزلرنڭ سویلاشوارى.

احمد بای وقفی

روسیه مسلمانلرنده مكتب، معارف وادبیات.

یاپونیاده تعلیم.

متنوعه.

تقریظ وانتقاد.

اجمال سیاسی.

مراسله ومخابره.

اشعار.

لطائف.

امثال.

اخطار.



اورنبورغده «كريموف، حسینوف وشركاسی» نڭ پاراواى مطبعه‌سی.

۱۹۰۸